1°2019

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

*Журнал «2014 –2020 елларга Татарстан Республикасында*
*ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»*
*дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы*
*таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Кузьмина Х.Х.* Татар ономастика фәненең бер тармагы
буларак космонимика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Хәлиуллина Н.У.* Этимологик **aγ ~ *aw ~ *aŋ* тамырының
хәзерге татар телендә фоно-морфо-семантик үсеше . . . . . . . . . 13
*Сәгъдиева Ф.К., Хөсәинова А.Җ., Булатова Ә.К.* Мәдәни
концептларның ачкыч сүзләрен этимологик һәм семантик
яссылыкта өйрәнү мәсьәләсенә карата
(акча лексик берәмлеге үрнәгендә) . . . . . . . . . . . . . . . . 23
*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теле чат сөйләшенең вокализм
системасы *(2017 елда Новосибирск өлкәсе Колыван районында
үткәрелгән экспедиция нәтиҗәләре буенча)* . . . . . . . . . . . . 27

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Алиева Ә.Х., Зәйниева Г.Н.* Г. Ибраһимовның яңа басмасы . . . . . 33
*Хасавнех А.А.* Әбелмәних Каргалый хикәяләвендә
Фудайл ибне Ийәд тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
*Надыршина Л.Р.* Марсель Галиев шигърияте:
жанр үзенчәлекләре, тема һәм мотивлар . . . . . . . . . . . . . . 54
*Каюмова Г.И.* «Битлекләр» уенында – милләт фаҗигасе...
*(Р. Хәмиднең «Җанкай улы Җанкыяр» трагифарсы буенча)* . . . . . 60

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Ямалтдинов И.И.* XX гасыр уртасына кадәр татар халык иҗаты
жанрларын өйрәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының топонимик
риваятьләрендә һәм легендаларында әүлия һәм әүлия
каберләренә бәйле мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Хуҗин Ф.Ш.* Урта гасырлар Европа тарихында болгарлар . . . . . 82

## ГАЙНЕТДИН ӘХМӘРЕВКӘ – 155

*Сәлахова Э.К.* «Исеме тарих сәхифәләрендә алтын кара белән
язылып калырга тиешле мөхтәрәм бер зат»
*(Г. Әхмәревнең фәнни мирасы)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Мөхәммәтшина Л.Т.* Укучыларның фәнни тикшеренү
эшчәнлегендә белешмә әдәбиятны куллану
*(«Татарстан Республикасы торак пунктлары»
энциклопедиясе мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
*Фәттахова Р.Ф.* Белемнәрне системалаштыру һәм
гомумиләштерү дәресе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109

## СӘНГАТЬ

*Кривошеева Т.Н.* Казан сәнгать мәктәбендә скульптура укытуда Көнбатыш Европа һәм Шәрык мәктәпләре традицияләре . . . . . 115
*Рахманова Д.В.* «ТАСМА» Казан фототөркеме иҗатының милли аспекты: мәсьәләнең куелышына карата . . . . . . . . . . 119

## ЭПИГРАФИКА

*Усманов В.М.* Эстәрлебаш ташъязмалары . . . . . . . . . . . . . . 124

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Шәйхелова С.Ф., Фахруллина Г.Ф., Нигъмәтҗанова Л.Р., Фахруллин Р.Ф. Caenorhabditis elegans* суалчанының био-наноагулыкны өйрәнүдә алдынгы өлге булуы . . . . . . . . . . 128

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Ганиева А.Ф.* Милли җанлы әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче *(Флүн Мусинның тууына 80 ел)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
*Эрҗан Алкая.* Тел галиме – ил агасы *(Фәрит Йосыповка 80 яшь)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
*Гайнетдинов А.М.* Олуг татар галиме *(Марсель Әхмәтҗановның 80 яшьлек юбилее уңаеннан)* . . . . . 149

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Мәхбүбҗамал Акчурина. Савинка.* Зөһрә ханым тугрысыннан . . 154
«Аң» альбомы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Россия төбәкләрендә татар фольклоры *(И.К. Фазлетдиновның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» (Уфа: Китап, 2018, 344 б.) китабына мөнәсәбәттә)* . . . . . . . . 160
*Сабитова И.И.* «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» турында (төзүче Р.Т. Сәфәров) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Кузьмина Х.Х.* Космонимика как одно из направлений татарской ономастики . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Халиуллина Н.У.* Фоно-морфо-семантическое развитие этимологических корней **aγ ~ *aw ~ *aŋ* в современном татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

*Сагдеева Ф.К., Хусаинова А.Я., Булатова А.К.* Ключевое слово культурного концепта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23

*Бадртдинова А.А.* Система вокализма чатского говора татарского языка *(по материалам экспедиции в Колыванский район Новосибирской области в 2017 году)* . . . . . . . . . . . . 27


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Алеева А.Х., Зайниева Г.Н.* Новое издание Г. Ибрагимова . . . . . 33

*Хасавнех А.А.* Повествование А. Каргалый о Фудайле ибн Ийаде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

*Надыршина Л.Р.* Поэзия Марселя Галиева: жанровые особенности, темы и мотивы . . . . . . . . . . . . . . . 54

*Каюмова Г.И.* В игре «масок» – трагедия нации... *(на примере трагифарса «Сын Джанкая Джанкыяр» Р. Хамида)* . . 60


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Ямалтдинов И.И.* Изучение жанров татарского народного творчества до середины XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

*Фазлутдинов И.К.* Мотивы, связанные с образами провидцев и местами их захоронений, в топонимических преданиях и легендах татар Башкортостана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Хузин Ф.Ш.* Булгары в истории средневековой Европы . . . . . . 82


### ГАЙНЕТДИНУ АХМАРОВУ – 155


*Салахова Э.К.* Научное наследие Г. Ахмарова . . . . . . . . . . . 96


### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ


*Мухаметшина Л.Т.* Использование справочной литературы при написании научно-исследовательских работ учащихся (на материале иллюстрированной энциклопедии «Населённые пункты Республики Татарстан» . . . . . . . . . . . . 105

*Фаттахова Р.Ф.* Урок систематизации и обобщения знаний . . . 109


### ИСКУССТВО


*Кривошеева Т.Н.* Традиции западноевропейской и восточной школ в преподавании скульптуры в Казанской художественной школе . 115

*Рахманова Д.В.* Национальный аспект творчества казанской фотогруппы «Тасма»: к постановке проблемы . . . . . . . . . . . . 119

## ЭПИГРАФИКА

*Усманов В.М.* Эпиграфические памятники на территории Стерлибашевского района РБ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

## ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ

*Шайхулова С.Ф., Фахруллина Г.Ф., Нигаматзянова Л.Р., Фахруллин Р.Ф.* Нематоды Caenorhabditis elegans как ценный объект исследования в инженерии анализа токсичности наноматериалов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

## ПЕРСОНАЛИИ

*Ганиева А.Ф.* Учёный, преданный народу *(к 80-летию со дня рождения Ф. Мусина)* . . . . . . . . . . . . 137

*Эрджан Алкая.* На страже родного языка *(к 80-летнему юбилею Ф.Ю. Юсупова)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

*Гайнутдинов А.М.* Великий татарский учёный *(к 80-летнему юбилею М.И. Ахметзянова)*. . . . . . . . . . . . . 149

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Махбубжамал Акчурина. Савинка.* О Зухре-ханум Гаспринской . . 154

Об «Альбоме» журнала «Анг» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

## НОВЫЕ КНИГИ

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский фольклор в регионах России *(анализ книги И.К. Фазлутдинова «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» (Уфа: Китап, 2018, 344 б.))* . . . . . . . . . . . . 160

*Сабитова И.И.* О словаре «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» Р.Т. Сафарова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.157

***Х.Х. Кузьмина***

# ТАТАР ОНОМАСТИКА ФӘНЕНЕҢ БЕР ТАРМАГЫ БУЛАРАК КОСМОНИМИКА

В статье рассматриваются вопросы разграничения терминов «астроним» и «космоним» и история их исследования в ономастической науке. По мнению автора, термины «космоним» и «космонимика» наиболее полно отражают совокупность наименований объектов, расположенных в космическом пространстве. Как наука, космонимика начала развиваться с середины XX века в трудах ономастов и диалектологов. История исследования космонимики татарского языка тесно связана с развитием этого направления в русской и зарубежной ономастике. Значительный вклад в изучение тюркской космонимики внесли татарские ученые, но в целом татарская космонимика требует более детального изучения.

**Ключевые слова:** космонимы, космонимика, астронимы, ономастика, татарский язык, лексика.

The article deals with the questions of the distinction between the terms «astronym» and «cosmonym» and the history of research of these ones in onomatology. According to the author, the terms «cosmonim» and «cosmonimics» most fully reflect the set of names of objects located in outer space. As a science, cosmonimics began to develop from the mid-twentieth century in the writings of onomasts and dialectologists. The history of the cosmonimics study in the Tatar language is closely connected with the development of this sphere in Russian and foreign onomatology. Tatar researchers made a significant contribution to the Türkic cosmonimics, but on the whole Tatar cosmonimics requires more detailed study.

**Keywords:** cosmonim, cosmonimics, astronym, onomatolory, Tatar language, lexicon.

Ономастика фәнендә күк йөзе һәм андагы җисемнәрнең атамаларын өйрәнә торган юнәлешне билгеләү өчен *космонимика һәм астронимика* терминнары кулланыла. Әлеге ике термин кайбер хезмәтләрдә мәгънә ягыннан тәңгәл итеп күрсәтелсә дә, сүзлекләрдә аларның аерымлануы күзгә чалына [Бондалетов, 1983, с. 224]. Мәсәлән, Н.В. Подольскаяның «Словарь русской ономастической терминологии» хезмәтендә мондый билгеләмә бирелә (тәрҗ. – *К.Х.*): «Космоним – оним төре. Космик киңлек зонасын, галактиканы, йолдызлар системасын (йолдызлыкларны) атаган ялгызлык исеме. Мәсәлән, *Зур Магеллан Болыты* (Большое Магелланово Облако), *Җидегән йолдызлыгы* (Большая Медведица), *Бөркет йолдызлыгы* (Созвездие Орла), *Волопас йолдызлыгы* (Созвездие Волопаса), *Кыз йолдызлыгы* (Созвездие Девы), *Орион йолдызлыгы* (Созвездие Ориона) һ. б.»

Астроним – оним төре. Аерым торган күк җисеменең, шул исәптән йолдыз, планета, койрыклы йолдыз (комета), астероид

(планетоид) атамасын белдергән ялгызлык исеме. Мәсәлән, *Кояш, Ай, Җир, Меркурий, Тимер Казык йолдызы, Чулпан йолдыз (Венера), Марс, Вега, Эрос, Цецера; Энке, Фая, Галлея койрыклы йолдызлары* (кометалары) [Подольская, 1978, с. 199].

Шул рәвешле, астронимика (бор. грек. тел. ἀστήρ «*йолдыз*» + ὄνομα «*атама*») аерым күк җисемнәрен, ягъни йолдыз, планета һәм аларның иярченнәрен, комета, метеорит һәм метеорит агымнарын, астероидларны атау өчен кулланылган ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак, ә космонимика (бор. грек. тел. κόσμος «дөнья», «галәм» + ὄνομα «атама») кеше күзенә космик киңлек зонасында аерым төркем булып күренгән йолдызлыклар һәм аларның өлешләрен, галактикаларның атамаларын өйрәнә торган тармак буларак билгеләнә. А.В. Суперанская «космоним» сүзен гомумирәк, «үз эченә галактика, йолдызлар җыелмасы, томанлыклар, йолдызлыкларны җыйган термин» дип атый [Суперанская, 1973, 188]. Астронимга ул күк җисемнәре – аерым бер йолдыз, планета, астероид, комета атамаларын кертә.

Безнең карашка, астронимик терминнар космик киңлектәге җисем атамаларының бер өлешен тәшкил иткәнгә күрә, күк җисеме атамаларын өйрәнә торган тармакны, гомумиләштереп, *космонимика* дип атау дөресрәк булыр иде.

Шул ук вакытта космонимика кысаларында астротопонимика юнәлеше дә аерылып карала. *Астротопонимика* – планеталар, аларның иярченнәре һәм астероидлар өслегендәге объект атамаларын өйрәнә торган тармак. Бу атамаларның күбесе мемориаль сыйфатта булып, күренекле шәхес исемнәре белән аталган (мәсәлән, Меркурий өслегендәге эре кратерлар *Гомер, Гёте, Шекспир, Рафаэль, Достоевский, Толстой, Бетховен* исемнәрен алган). Бу атамалар халыкара астрономик оешма тарафыннан раслана һәм планеталар номенклатурасына кертелә. Астротопонимнар аерым планета, иярчен яки астероидка караса, шул җисем исеме белән бәйле рәвештә ачыклана (мәсәлән, селеноним – Җир иярчене Ай өслегендәге, марсионим – Марс өслегендәге, меркурионим – Меркурий планетасы өслегендәге объектларның атамасы).

Билгеле булганча, ономастик берәмлекләр төрле халыкларның иң беренчел яшәү урынын һәм күченү процессларын, үзара мәдәни һәм икътисади, сәяси элемтәләрен, иң борынгы тел халәтен һәм диалект үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итә. Шул исәптән, космонимик терминнар да, әлеге максатка бәйле рәвештә, борынгы кешеләрнең дөнья һәм галәм төзелеше турында иң беренчел күзаллауларын, көнкүрешен, фәлсәфәсен, мифологиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүдә әһәмиятле чыганакларның берсе булып тора. Космонимик берәмлекләрдә тел барлыкка килгән һәм яңа атамалар кулланышка кергән борынгы чорлардагы күк йөзенең төзелеше, планета һәм йолдызларның Җир планетасына мөнәсәбәтле урыны турында мәгълүматлар катып калган хәлдә сакланган. Мәсәлән, б. э. к. йөз мең

еллар элек борынгы халыклар күк йөзендә сурәте аюга охшаган йолдызлар җыелмасы күргән һәм шуңа күрә бу йолдызлыкны Аю йолдызлыгы дип атаган. Сиксән мең еллар элек, йолдызларның хәрәкәте нәтиҗәсендә, бу сурәт үзгәрә башлаган, әмма Аю йолдызлыгы атамасы бүгенге көнгә кадәр кайбер телләрдә сакланып калган. Димәк, б. э. к. йөз мең еллар элек нигез баба телдә (ностратик телдә) инде *аю* сүзе булган [Карпенко, 1981, с. 184)]. Бу мәгълүмат исә тел тарихын, телләрнең килеп чыгышының хронологик чикләрен шактый үзгәртә (С.А. Старостин, А.А. Зализняк телләрнең праностратик халәтен б. э. к. 20–23 мең еллар элек дип билгелиләр [Старостин, 2017, с. 779]). Төрки халыклар исә әлеге йолдызлыкны Җидегән йолдыз дип атаган.

Икенче яктан, космонимик терминнарда халыкларның үзара сәяси, мәдәни, икъдисади элемтәләре дә ачык чагыла. Еш кына беренчел атамалар югалып, алар урынына чит телләрдән килеп кергән алынма сүзләр кулланыла башлый. Бу күренеш аеруча Идел буенда ислам дине таралган (X гасыр) һәм Европа фәннәре тәэсир иткән чорда (XIX–XX гасырлар) күзгә ташлана. XX гасыр башына кадәр татар теле төрле формаларда яшәп килгән [Мирхаев, Гумеров, 2015, с. 49–53]. Гомумән, XIX–XX гасырлар татар иҗтимагый хәрәкәте һәм тел үсеше белән тыгыз бәйләнгән әдәби барыш ягыннан иң катлаулы һәм кызыклы чорларның берсе булып тора [Гомәров, Харрасова, 2015, б. 18–45]; [Мирхаев, Миннуллин, 2016, с. 118]. Татар теленә, гарәп теле яисә рус теле аша, латин теленнән алынган атамалар килеп керә, һәм дәреслекләрдә урын ала. Мәсәлән, Чулпан (гар. Зөһрә) йолдызны атаган *Венера* сүзе, Зөхәл (гар.) атамасын алыштырган *Сатурн* сүзе иҗтимагый процесслар нигезендә телдә барган күренешләрне ачык сурәтли.

Астрономия фән буларак б. э. к. II меңьеллыкларда яшәгән шумер-аккадлы Вавилон дәүләтендә үк барлыкка килгән. Борынгы Кытайда исә аннан да элегрәк – б. э. к. III меңьеллыкта ук император сараенда астроном вазифасы булган, легендалар б. э. к. 2137 елда кояш тотылуны алдан әйтеп бирә алмаган ике астрономның үтерелүе турында хәбәр итәләр (https://ru.wikipedia.org/wiki/История_астрономии). Борынгы Мисырда, Грециядә, Һиндстанда, инк һәм майя цивилизацияләрендә – күк җисемнәре турында тупланган белемнәр язу барлыкка килгәннән соң теркәлгән. Шул рәвешле, космонимик атамалар борынгы заманнардан бирле сөйләмә һәм язма формада үсеп-үзгәреп, камилләшеп, безнең чорга килеп җиткәннәр һәм дөньядагы төрле телләрнең функциональ стильләрендә актив кулланылалар. Һичшиксез, һәрбер астроном үзенә кадәр булган белемнәр белән танышкан, аларны үзенең эшчәнлегендә кулланган.

Лингвистик аспектта исә татар космонимикасы – ономастика фәнендә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Күк җисемнәре атамалары борынгы төрки язма истәлекләрдә үк (Орхон-Енисей язмаларында, «Котадгу белек», «Диване лөгать эт-төрк», «Кыйссаи Йосыф» һ. б.

әсәрләрдә) теркәлеп калган. Шул вакытлардан алып, бүгенге көнгә кадәр йолдызлы күк галим, шагыйрь һәм язучыларның, ягъни телне статик һәм динамик халәтендә кулланучыларның игътибарын үзенә җәлеп иткән. Татар тел белемендә бу атамаларны лингвистик яктан өйрәнү, төркемләү, башка төрки телләрдәге кебек үк, бары XX гасырның икенче яртысында гына башлана. Дөрес, аларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүдә татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның эшчәнлеге гаять зур әһәмияткә ия [Насыйри, 1975, б. 8]. XX гасырның икенче яртысында (60 нчы елларда) казах, татар, башкорт, чуваш телендәге космонимнарны өйрәнгән мәкаләләр бер үк вакытта диярлек дөнья күрә (Ю. Немет, Т.Дж. Джанузаков, В.А. Никонов, Н.Х. Максютова, Д.К. Нуржанова, М.Н. Юхма, Г.Х. Әхәтов һ. б. хезмәтләре). Биредә «Идел буе ономастикасы» дип аталган конференция материалларын атап үтү зарур: 1973 елда Уфа шәһәрендә басылып чыккан «III Идел буе ономастикасы» конференциясе материалларында В.А. Никоновның «Идел буе космонимиясе» һәм Н.Х. Максютованың «Башкорт космонимиясе» дип аталган шактый саллы мәкаләләре дөнья күрә [Ономастика, 1973, с. 373–382]. Бу – космонимиканы ономастика фәне кысаларында өйрәнүнең башлангычы гына була әле. 1974 елда, Татарстан Мәгариф министрлыгы карары белән, Мәхмүд Галеев һәм Адлер Тимергалин тарафыннан төзелгән русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге басыла [Галеев, 1971, б. 3]. Бу хезмәтнең ономастика фәне өчен дә әһәмияте бик зур, чөнки анда планета, йолдыз атамаларының борынгы исемнәре дә күрсәтелгән. Әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәттә авторлар: «Татарча астрономия терминнары да шактый эшләнгән, ләкин астрономия терминнары моңа кадәр эзлекле бер системага салынмаган, атама сүзләр чагыштырылмаган һәм бергә тупланмаган, ягъни таркау хәлдә иде. Шуның аркасында терминнарны дөрес кулланмау очраклары да бар, матбугатта аерым атамаларның төрле вариантлары һәм синонимнары йөри, кайбер очракларда исә тел хәзинәсендә электән булган сүз онытылып, бер дә кирәксезгә ясалма терминнар кулланыла. Хәлбуки, төрки телләрдә, гарәп теле йогынтысында, борынгыдан ук фәнни астрономик терминнар эшләнгән булган. Аларның байтагы, соңыннан интернациональ характер алып, барлык телләрнең терминологик байлыгына әверелгән (мәсәлән, *Альголь, Алькор, Альмукантарат, Бетельгейзе, зенит, надир* һ. б.). Шул ук вакытта җанлы телдә байтак кына йолдызларның һәм йолдызлыкларның үз исемнәре булган (*Көянтә – Орион, Иләк – Плеяда, Акбүзат һәм Күкбүзат йолдызлары, Әвернә – Лебедь* кебекләр). Төзүчеләр бу атамаларны сүзлеккә кертергә тырыштылар», – дип яза [Галеев, 1974, б. 4].

Татар телендәге космонимнарны өйрәнүгә диалектолог галимнәр дә билгеле бер өлеш кертә. Диалекталь лексиканы өйрәнгәндә, йолдызлы күк йөзен тасвирлаган кайбер атамалар Г.Х. Әхәтов, Р.Г. Әхмәтьянов, Р.С. Барсукова, Ф.С. Баязитова, Ф.Г. Гарипова, М.Р. Булатова, Л.Т. Мәхмүтова, И.С. Насипов, Д.Р. Рамазанова, З.Р. Садыйкова,

Д.Г. Тумашева, Т.Х. Хәйретдинова, Ф.Й. Йосыпов , Э.Х. Кадыйрова һ. б. хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Татар халкының антропонимик системасында космонимик күзаллаулар белән бәйле кеше исемнәренең кулланышы Г.Р. Галиуллина мәкаләсендә җентекле яктыртыла [Галиуллина, 2008, с. 197–204]. *Кояш, көн, ярук, таң, тәңре* һ. б. космонимик лексемаларның татар антропонимикасында гасырлар дәвамында сакланган үз урыны барлыгын искәртеп, галим бүгенге көндә дә әлеге лексемалардан *кояш* һәм *таң* компонентларының татар исемнәрендә кулланылуын билгели.

Күк йөзенә мөнәсәбәтле лексемаларның Урта гасырлар язма истәлекләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен исә Э.Х. Кадыйрова мәкаләсендә күрергә мөмкин [Кадирова, 2010, с. 334–336]. Галим бу лексемалар арасында кайберләренең төрки мифологиягә бәйле булуын искәртә (мәсәлән, «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында Мәррихнең (Марс) Мәликәнең дошманнарны тар-мар итүенә күктән шатлануы тасвирланган күренеш). Автор күзәтүендә *йолдызлык* мәгънәсендә килгән «бурҗ», «бурҗис» сүзенең кулланылышы да үзенчәлекле.

Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты тарафыннан чыгарылган «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Лексика» (2001), «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Баба төрки-нигез тел. Тел мәгълүматлары буенча баба төрки этносның дөнья картинасы» (2006) дип аталган академик хезмәтләрдә борынгы төрки халыкларның күк йөзе, күк җисемнәре һәм күренешләре турындагы күзаллауларына аерым бүлекчә багышланган [Сравнительно-историческая грамматика..., 2001, с. 50–67; Сравнительно-историческая..., 2006, с. 326–352]. Биредә төрки телләрдәге кайбер космонимик атамалар тарихи планда яктыртыла.

Күк йөзендәге кеше күзе күрә алган алты меңгә якын йолдыз арасыннан бары тик ике йөз җитмеш бише генә исем-атама йөртә. 1922 елда Халыкара Астрономия Берлегенең *(Международный астрономический союз (МАС))* I съезды уздырыла. Әлеге корылтайда күк йөзе сферасы, 88 йолдызлыкка бүленеп, фәнни әйләнешкә кертелә һәм яңа ачылган күк җисемнәренә исем яки номерлар бирү тәртипкә салына.

Шул рәвешле, космонимик лексиканы өйрәнү татар теленең сүзлек составын барлау максатыннан гына түгел, гомумән, татар халкының дөнья һәм галәм төзелеше турында иң беренчел күзаллауларын, көнкүрешен, фәлсәфәсен, мифологиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнү өчен дә әһәмиятле юнәлешләрнең берсе булып тора. Шул ук вакытта космонимик терминология – ономастика фәне өчен дә кыйммәтле чыганакларның берсе, чөнки күк йөзендәге җисем атамалары, ялгызлык исемнәре буларак, телдәге онимлаштыру күренешенең иң борынгы закончалыкларын ачарга ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Бондалетов В.Л.* Русская ономастика. М., 1983. 224 с.

*Галеев М.С., Тимергалин А.К.* Русча-татарча астрономик терминнар сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 64 б.

*Галиуллина Г.Р.* Космологические воззрения в татарской антропонимической картине мира / Г.Р. Галиуллина // Ученые записки Казанского государственного университета. Т. 150. Книга 2. Казань, 2008. С. 197–204.

*Кадирова Э.Х.* Космонимы в тюрко-татарских письменных памятниках // Материалы XII Международной научной конференции «Ономастика Поволжья», 2010. С. 334–336.

*Карпенко Ю.А.* Названия звёздного неба. М.: Наука, 1981. 184 с.

*Мирхаев Р.Ф., Гумеров И.Г.* Система форм существования татарского языка в конце XIX – начале XX вв. // Филология и культура. Philology and Culture, 2015. № 1 (39). С. 49–53.

*Мирхаев Р.Ф., Миннуллин Б.К.* Старотатарский литературный язык в конце XIX – начале XX века: функционально-стилистические особенности употребления деепричастия на -ып (-ур) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2016. № 11. Ч. 2. С. 118–121.

*Гомәров И.Г., Харрасова Р.Ф.* XIX йөзнең беренче яртысы. Иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт һәм әдәби барыш // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 3: XIX йөз. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 18–45.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 318 б.

Ономастика Поволжья: материалы XII Международной научной конференции «Ономастика Поволжья». Уфа, 1973. 432 с.

*Подольская Н.В.* Словарь русской ономастической терминологии. М.: Наука, 1978. 199 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика: 2-е изд., доп. М.: Наука, 2001. 822 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / под ред. Э.Р. Тенишева и А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 912 с.

*Старостин С.А.* Труды по языкознанию. М: Языки славянских культур, 2007. С. 779–793.

*Суперанская А.В.* Общая теория имени собственного. М.: Наука, 1973. 366 с.

*Публикация статьи осуществлена в рамках Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 годы»*

*Мәкалә «2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында әзерләнде*

***Кузьмина Халисә Хатыйп кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Н.У. Хәлиуллина***

# ЭТИМОЛОГИК **aγ ~ *aw ~ *aŋ* ТАМЫРЫНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ФОНО-МОРФО-СЕМАНТИК ҮСЕШЕ

В статье раскрывается метод реконструкции этимологических корней, который основывается на сравнительно-сопоставительный анализ гомогенных с точки зрения фонетической, семантической структуры лексических единиц современных родственных (тюркских, шире – алтайских) языков. Здесь подробно анализируется фоно-морфо-семантическое развитие этимологических корней **aγ ~ *aw ~ *aŋ* в татарском языке в рамках трех семантических полей.

**Ключевые слова:** этимологический корень, реконструкция, семантика, деривация, семантическое поле, тюркские языки, татарский язык.

The article reveals a method for the reconstruction of etymological roots, which is based on a comparative analysis of modern related homogeneous languages (Turkic, broader - Altai) from the point of view of phonetic, semantic structure of the lexical units of these languages. The phono-morpho-semantic development of the etymological roots **aγ ~ *aw ~ *aŋ* in the Tatar language within the framework of three semantic fields is analyzed in detail.

**Keywords:** etymological root, reconstruction, semantics, derivation, semantic field, Turkic languages, Tatar language.

Этимологик тамырларның төрки телләрнең бербөтен лексик берәмлек булып оешуы – төрки телләрнең морфологик структурасының озакка сузылган тарихи үсеше нәтиҗәсе. Семантик компонентларга таркату, структур-семантик тәңгәллек һәм бертөрле яки капма-каршы фактларны, категорияләрне каршы кую алымнарын файдаланып, хәзерге телдәге ике яки күбрәк иҗекле сүзләрдә авыр табылган тамыр-нигезләрне күрсәтергә мөмкин. Мондый эш төре безнең хезмәтләрдә «этимологик тамырларны реконструкцияләү» дип атала [Халиуллина, с. 130]. Төрки телләрнең агглютинатив төзелеше, тарихи үсеш процессының гадидән катлаулыга, бер иҗекледән күп иҗеклегә таба үсеше күпсанлы төрки (киңрәк алтай) чыганаклы нигезләрнең үле тамырга һәм тагын да ваграк морфемаларга бүленә алуын күз уңында тота.

Әлбәттә, мондый анализ ысуллары һәм реконструкцияләр барлык очракта да үз максатына ирешә алмый. А.Т. Кайдаров фикеренчә, бу алым төрки тамыр турында күзаллауны традицион метод ярдәмендә өйрәнүне җимерүгә һәм төрле каршылыкларга китерергә мөмкин [Кайдаров, с. 109]. Шуңа карамастан, тәкъдим ителгән структур анализ методы эффектив санала һәм күпсанлы мисаллар ярдәмендә дәлилләнә. Шушы ук принцип буенча тамыр нигезләрнең диахрон сүзлеге төзелә ала.

Хәзерге татар телендә ике иҗекле сүзләрдә (нигезләрдә) таркалучан морфологик структура күренмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, *имән*

«дуб», *муен* «шея», *яшер* «прятать, спрятать, скрывать», *утыр* «сидеть, сесть» һ. б. Бер үк форма кайчакта үзендә синкретизм күренеше дип аталган исем-фигыль омонимнарын да берләштерергә мөмкин: *тут* «плесень, ржавчина» тамырыннан *тутык* «окись, загар» исеме һәм *тутык-* «окисляться, ржаветь, покрываться ржавчиной, плесенью, загореть, потускнеть от загара» фигыльләре барлыкка килә. Бүгенге көндә конкрет тел өчен мөстәкыйль кулланыла торган һәм этимологик (үле) тамыр-нигезләрнең модельләре исемлеге эшләнмәгән.

Ясалма нигезләр составыннан тамыр һәм аффиксаль морфемаларны аерып алганда, аларның чикләрен билгеләү кыенлашырга мөмкин: нигез элементларының тарихи реаль булганнарын билгеләргә кирәк була [Кайдаров, с. 113].

Мисал өчен, татар телендәге ясалма сүз структурасында тамыр һәм аффиксаль морфемаларның чикләрен билгеләп карыйк.

Тарихи тамырны аерып алу, аның аваз комплексын үзгәртү, яңа формалар кертү төрки тамырга хас фономорфологик закончалыклар чигендә генә барлыкка килә. Ләкин бер иҗекле төрки тамырның тарихи чиге аның закончалыклы фонетик вариантларын исәпкә алган аваз комплексы белән билгеләнергә тиеш. Мәсәлән, татар телендәге этимологик **aw* «валиться; наваливаться» тамыры түбәндәге сүз ясалышы рәтләрен барлыкка китерә:

****Aw***

→ ***[Aw+a], [aw+ыʸw]*** «валиться; наваливаться; свалиться; опрокидываться; полегать; склоняться; соглашаться; наклониться» [ТРС, с. 16].

→ ***[Aw+ыш]*** «наклонный, с наклоном, покатый, покосившийся» [ТРС, с. 18].

→ ***[Aw+дару]*** «валить, повалить, опрокидывать, взвалить, переводить, переманить» һ. б. [ТРС, с. 41].

→ ***[Aw+макай]*** «непостоянный, шаткий; слабодушный, неустойчивый, беспринципный» [ТРС, с. 42].

Күренгәнчә, барлык грамматик формантлар алдыннан даими рәвештә кабатланып килгән **aw* аваз комплексы үзгәрешсез саклана. Шуңа күрә ул тамыр морфема ролен үтәүче булып кала. Аның морфологик статусы татар телендә мөстәкыйль кулланылуына карап билгеләнә ала.

Галимнәр, бер иҗекле тамырларны этимологик реконструкцияләү максаты белән, язма истәлекләрдә һәм хәзерге телләрдә урын алган фактларга мөрәҗәгать итәләр. Югарыдагы мисалда **aw* тамыры борынгы төрки телдә **aɣ* формасында «гнуть, сгибать» мәгънәсендә кулланыла [ДТС, с. 174].

Татар телендә, кайбер борынгы төрки истәлекләрдәге кебек, «зияние», «щель», открытое место», «ущелье» һ. б. мәгънәне аңлаткан **aŋ* тамыры очрамый. Мәгънәсен белми торып, этимологик **aŋ* тамыры турында ничек фикер йөртергә соң? Моның өчен сүзлек-

ләрдәге ясалма нигезләрендә гипотетик **аŋ* тамыры булган, семантикасында аның борынгы мәгънәсе белән уртаклык күзәтелгән берәмлекләр рәте белән эш итәргә кирәк.

Мисалга төрки телләрдән **аŋ* тамырының күрсәтелгән мәгънәсе белән бәйле түбәндәге үзаллы лексик берәмлекләрне китерик [Халиуллина, Шайхулов, II]:

***Аŋ***

- *-кау* [*kaw*] «нёбо» (татар)
- *-кай* «разинуть рот» (казах)
- *-шай* «ротозейничать, зевать» (башкорт)
- *-ыргай* «зиять, разверзаться» (казах)
- *-гыра* «глупый, бестолковый, тупой, слабодушный» (татар)
- *-гый* «глупый» (татар, диалект)
- *-кыт* «глупый, тупой» (татар, диалект)
- *-кый* «открываться настежь»
- -[*кыw*] «благоухать, издавать, испускать запах» (татар)

Этимологик анализ нәтиҗәсендә генә ачыклануына карамастан, конкрет ясалма нигезләр буенча уртак **аŋ* тамырының гомумиләштерелгән мәгънәсен чыгарырга мөмкин. Шуннан соң гына гомумтөрки **аŋ* тамырын эзләп табу мөмкинлекләре киңәя. Төрки телләрдә бу тамырдан ясалган унлап лексик берәмлек бар.

Этимологик **аү ~ *aw ~ *аŋ* тамырлары рәте төрки телләрнең тарихи үсешендәге фонетик закончалыкларны, морфологик, семантик үсеш юнәлешләрен ачык чагылдыралар.

Р.Г. Әхмәтьянов билгеләвенчә, гомумтөрки *ав ~ аг ~ аң* «ау, киек, ау коралы» берәмлеге – бик борынгы тамыр сүз [Әхмәтьянов, б. 23]. Киңрәк планда караганда, ул шулай ук алтай гаиләсенә караган монгол һәм тунгус-маньчжур телләрендә дә күзәтелә, һәм «ау, киртәләп, урталап тоту» мәгънәсендә кулланыла.

«Төрки телләрнең тарихи-чагыштырма грамматикасы»нда «охота, дичь» семантикасы белән бәйле СТ тибына караган **аŋ* тамыры реконструкцияләнә. Семантик яктан караганда, монда «эзәрлекләү, күзәтү, саклап тору → сагалау объекты → киек» мәгънәләренең үсеше күзәтелә. Фонетик вариантларга **аб ~ *av ~ *аү (аг) ~ *aw* тамырлары кертелә, алар, үз чиратында, алга таба үсеш-үзгәреш кичереп, семантик яктан төрле модификацияләргә дучар булалар, яңа лексик берәмлекләр өчен нигез хезмәтен үтиләр [СИГТЯ, с. 417–418].

Этимологик **аŋ* тамырының барлык вариантлары борынгы төрки телдә мөстәкыйль лексик берәмлек сыйфатында һәм күп иҗекле нигезләр составында кулланылган.

Борынгы **av* тамырының гомум мәгънәсе «җыелу, туплану» төшенчәсе белән бәйле. Мәсәлән, *külär jüz isig söz neŋ tavar boš azad kišilär bu üčkä avar.* – Дари приветливым взглядом, теплым словом, дарами: свободные и вольные люди привлекаются (буквально собираются) этими тремя вещами («Котадгу белек»). – Көләч йөз, җылы сүз, товар белән бүләкләр: азат кешеләр бу өчкә ауланыр (кызыгыр, җыелыр мәгънәсендә) [ДТС, с. 69].

Димәк, борынгы төрки телдәге **av* ~ **aγ* этимологик тамырының семантик үсешен түбәндәге схема ярдәмендә күрсәтергә мөмкин: «ау» → «аулау» → «тозак» → «каршылык» → «җыелу».

Борынгы төрки язма истәлекләрдә **av* тамырының өч мәгънәсен очратабыз. Беренчедән, **av* «охота» мәгънәсенә ия, һәм шушы формада уйгур, карахани-уйгур язмаларында еш очрый. Гадәттә, **av* сүзе хайван, кош, кош аулау, аларны тоту мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән, *böri tilkü arslan adïγ ja toŋuz seniŋdin qutulmaz ölür avda tüz.* – Волк, лиса, лев, медведь или кабан не спасутся от тебя, все равно погибнут на охоте («Котадгу белек»). – Бүре, төлке, арыслан, аю я дуңгыз синнән котылмас, үлер ауда [ДТС, с. 68].

Икенчедән, **av* тамыры «сети, невод» мәгънәсендә кулланыла. Бу очракта күрсәтелгән тамыр каршылык, нәрсәнеңдер туплануы мәгънәсен аңлатырга мөмкин. Мәсәлән, *bayïrsaq kišiniŋ sözi tut savï bu söz sav saŋa bolγa dävlät avï.* – Прислушивайся к словам людей добросердечных, эти слова послужат тебе сетями счастья («Котадгу белек»). – Бәгырьле (яхшы күңелле мәгънәсендә) кешенең сүзен тот, бу сүз сиңа булыр дәүләт (байлык, бәхет мәгънәсендә) авы.

Борынгы төрки телдә **av* тамырыннан түбәндәге лексик берәмлекләр ясалган: *avčï* «охотник», *avla* «охотиться, поймать» → *avay* → *avayla* «кокетничать»; *avala* «собираться, толпиться»; *avla* «собираться, толпиться»; *avïnč* 1. утешение, радость. 2. увлечение, занятие. 3. привычка, привязанность [ДТС, с. 70].

Өченчедән, **aγ* тамыры «силок, ловушка» мәгънәсен белдерә. Бу очракта ул хәзерге татар телендәге «тозак» сүзенең семантикасы белән тәңгәл килә. Мәсәлән, *bodun bašlar erkä bolur miŋ jayï jayï bolsa kimkä jadïγlïγ aγï.* – У мужа, возглавляющего народ, тысяча врагов, если есть враги, то на кого расставлена их сеть. – Халык башлыгы булган ирнең мең дошманы булыр, дошманы булса, кемгә ябар авын [ДТС, с. 16]. **Aγ* тамыры «каршылык» мәгънәсендә дә кулланылган.

Фигыль мәгънәсендә *av* тамыры куалау, куып чыгару, тоту, камап алу, аулау, әйләндереп урап алу семантиксына ия. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә теркәлгән *аг*, *aw* формалары *ав* ~ *авала* «собираться вместе» берәмлекләре арасында фоно-морфо-семантик бәйләнеш булырга тиеш [Севортян, с. 62].

Димәк, **аг* ~ **аб* ~ **ав* исем-фигыль тамыр нигезләре гомоген саналалар, ягъни бер үк этимологик тамырның тарихи вариантлары булып торалар. Г.Вамбери *av* «охота» һәм *аг* «сеть, силок» сүзләрен

тиңләштерә һәм аларны ясалма *ваг* «связка, пучок» нигезе белән чагыштыра. Монда сүз башында *в-* авазы төшеп калган дип күрсәтә. Ләкин бу караш соңрак нигезсез дип табыла. М. Рясянен үзенең этимологик сүзлегендә ясалма *авла* нигезенең төрле формаларын чагыштыра һәм **ав* элементын тамыр нигез буларак күрсәтә. Ф.Е. Корш, В. Банг, Г. Рамстедт төрки телләрдәге *ав* сүзен монгол телендәге сүзләр белән тиңләштереп карыйлар. Мәсәлән, Ф.Е. Корш фикеренчә, төрки телләрдәге *ав* сүзе монгол телендәге *аб-ху* «брать» фигыленнән алынган [Севортян, с. 63].

Борынгы һәм хәзерге *аңды~ аңта* «подкарауливать» ясалма нигезе **аŋ* тамыры белән бәйләнгән. Аның түбәндәге мәгънәләрен санап чыгарга мөмкин:

1. Төрtкмән, кыргыз, казакъ, татар, башкорт телләрендә – «качып көтеп тору, саклап тору», «эзләү», «эзәрлекләү», «яшеренеп тыңлап тору», «тоту, эләктерү», «тоту өчен хәйлә кору», «әйләндереп алу».

2. Хакас, үзбәк телләрендә – «текәлеп карау, күз йоммыйча карау», «күзәтү», «төзәү, билгеләү».

3. Кыргыз, казакъ телләрендә – «карану, сак булу», «күрү, карау».

4. Караим телендә – «тукмау, кыйнау, сугышу».

Димәк, югарыда саналган мәгънә төсмерләреннән күренгәнчә, хайван яки киек (~ аң) аулау процессы хәзерге төрки телләрдә төрле формалар ярдәмендә белдерелә.

Этимологик **ау ~ *aw ~ *аŋ* тамырының икенче гомуми мәгънәсе – «ачылу (открываться)». Семантик яктан *аŋ* фигыле мимеографик бирәмлекләр рәтенә керә: ул тере затларның кыяфәтен, торышын, ашыккан, аптыраган, гаҗәпләнгән кешенең рәвешен белдерә [Севортян, с. 155].

**Аŋ*: «быть широко открытым», «широко распахиваться» тамырыннан татар һәм башкорт телләрендә ***аңкау*** «нёбо» сүзе *-ка* фигыль ясагыч аффиксы һәм *-w* кушымчасы ялганып ясала. Хәзерге татар телендә *аңкау* – авыз куышлыгының өске стенасын аңлата [ТТАС, I, б. 101].

Татар телендә, гомумән, барлык кыпчак телләрендә, борынгы төрки **агыз* тамыры [*аwыз*] формасына үсеш алган. Э.В.Севортян күрсәтүенчә, **аг ~ *аj ~ *аŋ* тамырлары алтай гаиләсенә караган телләрдәге «раскрывать, открывать, разинуть» мәгънәләренә ия булган сүзләр белән тиңләштерелә [Севортян, с. 82].

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *авыз* сүзенең тугыз мәгънәсе бирелә. Беренче мәгънәсе (исем формасында килгәндә) – өске һәм аскы казналыклар арасыннан йоткылыкка кадәр куышланып киткән, сөйләү һәм ашау функциясен башкаруга ярдәм итә торган әгъза. Мәсәлән, *Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә.* (Мәкаль)

2. Күчерелмә мәгънәдә авыз сүзе гади сыйфат була һәм гаилә тәрбиясендәге кешене, ашаучыны белдерә. Мисал өчен: *Минә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.* (Г.Тукай)

3. Мич, шалаш, оя һ.б. шуның кебек эче куыш нәрсәләрнең алгы өлешендәге тишек. Мәсәлән, *Нургали тартып бетермәгән тәмәкесен сүндермичә мич авызына ыргытты.* (Ә. Еники)

4. Янар тау түбәсендә лава агып яки атылып чыга торган тар һәм тирән тишек: *Без янар тау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып һавага ыргылдык.* Шушында ук бомба яки снаряд шартлаудан барлыкка килгән чокырның өсте турында да әйтергә мөмкин.

5. Ваза, кувшин, шешә кебек савытларның тараеп килгән ачык башы. Шуңа якын икенче бер төшенчә дә бар: чиләк, стакан һәм башка шуның кебек эче тирән әйберләрнең өсте каплана, ябыла торган өске өлеше: *Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның авызын бәйләп куя.* (А. Алиш)

6. а) ату кораллары көпшәсенең снаряд, пуля атылып чыга торган тишеге; б) самовар торбасының төтен чыга торган тишеге. *Су китерелгән, күмер тутырылган, чыра яндырып салынган самавырның торбасы авызы белән мич юлына куелган.* (Ә. Фәйзи)

7. Капчык, пакет кебек нәрсәләрнең бәйләнә, ябыла торган өске ягы. *Күмәч салган капчыкның авызын чишәргә кирәштек.* (М. Гафури)

8. Урман, әрәмәлек кебек нәрсәләрнең чите, кырые, башланган яки беткән урыны. *Захаров аларны ашыктырып, әрәмәлек авызына алып чыгып китте.* (А. Шамов) Шулай ук фронтның, сугышның алгы позициясенә карата да әйтелә.

9. Елга, инеш коя торган урын, тамак. Елга авызы [ТТАС, т. 1, б. 7, 8, 9].

Татар телендә *ачык авыз* фразеологик берәмлеге *аңгыра* «глупый» лексемасының синонимы була һәм аның үсеше *аңкау* (*агыз < авызның бер өлеше) сүзе белән бәйле дип карарга мөмкин.

Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгать әт-төрк» сүзлегендә теркәлгән **аŋ-* фигыль-тамырыннан *аңкай* фигыле ясалган. Ул анда төрле фонетик вариантларда һәм мәгънәләрдә очрый: *anmag* «приходить в смущение, в затруднение», *eng* «опешить, быть в изумлении» [МК, с. 27]. **Аŋ* тамырыннан төрле төрки телләрдә семантик яктан тиңдәш булган лексик берәмлекләр ясалган. Мәсәлән, борынгы чыгтай телендә – *аңыр* «глупый», хакас телендә – *аңмах* «ротозей, невнимательный, рассеянный» һ.б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *аңгыра* сүзенең сөйләмә стильгә караган ике мәгънәсе күрсәтелә:

1. Аңсыз, миңгерәү, надан, ахмак булып бирелә. *Миңлебай яшь, аңгыра, бернәрсә белмидер.* (Ш. Мөхәммәдиев)

2. Акылга зәгыйфь, тулы акыллы түгел. *Биби – Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.* (Г. Камал) *Аңгыра* сүзе фразеологик әйтелмәләр составында кулланылганда яңа төсмерләр ала. Мәсәлән, *аңгыра бәрән* (бәрән, сарык, тавык, ябалак) – хурлап, кимсетеп әйтү. *Аңгыра катык* төзелмәсендә – оеткысыз яки оеткы салып та начар оеган катык дигәнне аңлата [ТТАС, т. 1, б. 101].

**Агдар* сүзенең төрле вариантлары арасында хакас һәм тува телләрендәге *аңдар* – (< *аңтар)* формасы иң борынгысы дип күрсәтелә. Э.В. Севортян билгеләвенчә, *агдар ~ авдар* фигыле *-тар, -дар* йөкләтү кушымчасы ярдәмендә *аг* тамырыннан ясалган. Хәзерге төрки телләрдә таралган мәгънәләрнең иң борынгылары түбәндәгеләр: төрек, төрекмән, кыргыз, казакъ, татар, үзбәк, хакас телләрендә – «егу», «әйләндереп салу»; төрек телендә – «җиргә сузып салу», «җиңү»; хакас телендә – «этеп җибәрү», «төшереп җибәрү»; кыргыз, нугай, үзбәк, уйгур, тува телләрендә – «бору»; уйгур телендә – «чоку»; төрек, уйгур телләрендә – «сөрү»; нугай, үзбәк, тува телләрендә – «эчен тышына әйләндерү»; төрек телендә – «күчереп утырту» һ.б. Соңрак төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш төркемнәрдә «эзләү» мәгънәсе үсеш ала [Севортян, с. 74]. Димәк, семантик яктан караганда, ачылу → эчен тышына ачып салу → әйләндереп салу юнәлешендәге үзгәреш күзәтелә.

Кыпчак телләрендә «сваливать» һәм «искать» мәгънәләре арасында формаль дифференциация дә күзәтелә: *аудар* [*awдар*] һәм *актар.*

***Аудару*** фигыле утыртып куелган яки үсеп утырган нәрсәне көч белән бер якка таба әйләндереп ташлау, егу дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Тракторчысын югалткан ялгыз трактор, өч төрәнле сабанын өстерәгән хәлдә, кибәннәрне аударып, читәннәрне, киртәләрне җимерә-җимерә авылга кереп килә иде.* (М. Әмир) Бу сүз шулай ук егуны гына түгел, ә бер якка кыегайту, янтайту дигәнне дә аңлата. Мәсәлән, *Тәртә сынды, арба авып китте, сыер үзе, читәнне аударып, арт якка чыгып китте.* (Г. Бәширов) Ул үсеп утырганны, яки багана്ны гына түгел, ә кешене егу мәгънәсендә дә кулланыла. Мәсәлән, *Ул, Шәмсинең җавабын да көтмичә, киң җилкәсе белән бер селкенеп, Даниловны төртеп аударды.* (Г. Бәширов)

*Аудару* сүзенең нәрсәне дә булса икенче урынга бушату, илтеп ташлау дигән мәгънәсе дә күрсәтелә. Мәсәлән, *Күпме бәрәңгесен казып алып, аны Хафизның келәтенә аудардылар.* (Ә. Фәйзи). Халык сөйләмендә аның күчерелмә мәгънәсе дә бик киң кулланыла: бу очракта кемгә дә булса кайгысын, борчуын, ачуын һ.б. сөйләү, күңелендәгесен бушату, чыгарып салу дип бирелә. Икенче күчерелмә мәгънәсе – күчерү, ыргыту. Мәсәлән, *Көчәеп бара торган җил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды да, күз ачып йомганчы аны ут камап алды.* (М. Гали)

Алдагы очракта *аудару* сүзенең күчерелмә мәгънәсе күрсәтелә: берәүнең фикерен үзгәртеп, икенче як файдасына юнәлтү, авыштыру. Мәсәлән, *Хуҗаның кодасы, бер чалма белән, сайлауда үз ягына аударыр өчен, кемгә нәрсә бирергә тиешле булачагын исәпләп чыгарды.* (Г. Ибраһимов)

*Аудару* сүзенең берәр гаепне икенче берәүгә сылтау, ягу дигән күчерелмә мәгънәсе дә бар. Мәсәлән, *Аңламаган халык гаепне Зәйнәп өстенә аудара иде.* (М. Гафури)

*Аудару* фигыленең сөйләмә стильдә түбәндәге мәгънәләрдә кулланылуы да мөмкин:

– тәрҗемә итү: *Ник балаларга театр язмый Мирхәйдәр, диләр, Бар икән русчаң язарлык, әйдә тик аудар, диләр.* (Ш. Бабич)

– эчеп кую: *Галәү белән Гайнетдинов, күк киемнәре тышыннан пальто кия-кия, тагын берәрне аудардылар.* (Г. Ибраһимов) [ТТАС, т. 1, б. 85, 86].

***Актару*** фигыленең мәгънәләре:

1. Төп мәгънәсендә килгәндә, бергә торган әйберләрнең астын өскә китереп бутау, элеккеге тәртибен бозу. Мисал өчен, *Кулына кисәү агачы тотып мич актара торган Гөлбаһар абыстай үзенең корымга буялган кулларын аларга күрсәтәсе килмичә, оялып, алъяпкыч аша гына сузды.* (М. Гали)

2. Әйберләр арасыннан нәрсә дә булса эзләү, нәрсә дә булса эзләп, әйбернең астын өскә китерү. Мәсәлән, *Бу вакыт Зыя, кәнәфисеннән торып, китаплар шкафы янында нидер актара иде.* (Г. Ибраһимов)

3. Җир, юл турында сүз барганда казып, сөреп бозу булса, төен, төргәк кебек әйберләрне чишеп, эчен тикшерүне аңлата. Мисалларны чагыштырыйк: *Газинур автомашиналарның тәгәрмәчләре һәм чылбырлы тракторлар актарып бетергән киң урамның аргы башына таба йөгереп китте.* (Г. Әпсәләмов) *Зиннәт, үз квартираларына төшкәч, төргәкне актарып карады.* (А. Шамов)

4. Нәрсәне дә булса тузгыту, сибү, тарату; туздыру, пыран-заран китерү; юк итү, юкка чыгару.

5. Аста, эчтә ятканнарны, җир асты байлыкларын казып чыгару; вату, казу; ишү. Мәсәлән, *Дуңгызлар үзләре актарган туфракка ятканнар да әкрен генә мыркылдыйлар.* (Г. Әпсәләмов)

6. Китап, дәфтәр кебек нәрсәләрне ачып-ачып карау, битләрен бер-бер артлы ачу; төрле язмалар, кәгазьләр, китаплар арасында эзләнү. Мисал өчен,

*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам.*

(Г. Тукай)

7. Узган гомердән кайбер вакыйгаларны искә төшерү, хәтерне барлау: *Иске хатирә дәфтәреннән актарган адәм кеби, артта калган күренешләрне актара башлыйм.* (Г. Ибраһимов)

8. Күздән кичерү, күзләр ярдәмендә тикшереп, айкап чыгу. *Күзләрем бөтен пароходны актардылар, ....пристаньга төшеләр һәм анда Хөршитне таптылар.* (Ф. Әмирхан)

9. Актару сүзенең диалекталь мәгънәсе коеп яңгыр яву дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Менә инде бер атнадан бирле халык иген сугарга аяз көннәр көтә, ә ул чиләкләп кенә актара.* (К. Нәҗми)

*Актару* сүзе тотрыклы сүзтезмәләр составында да килә: *Актарып чыгару* а) күмелеп аста калган, югалган яки онытылган нәрсәне эзләп табу, ә) үткән, элек булган вакыйганы, эшне казып чыгару, аның асылын чишү, б) әйбернең эчке ягын әйләндереп чыгару. *Акта-*

*рып ташлау* а) җыеп куелган әйберне тарату, таратып ташлау, сибү, ә) өемнең өстен алып ташлау, ишеп төшерү [ТТАС, т. 1, б. 36, 37].

Димәк, хәзерге татар телендә этимологик **аү ~ *aw ~ *аŋ* тамырының «ачылу» мәгънәсе белән бәйле семантик кыры *авыз, аңкау, аңгыра, аудару, актару* лексемаларында чагылыш таба. Аларда, бер яклап, тамырдагы *aw ~ аг ~ ak* фонетик вариантларының, икенче яклап, борынгы тамырдагы беренчел мәгънәнең саклануы күзәтелә.

Этимологик **аү ~ *aw ~ *аŋ* тамырының гомум мәгънәсе «әйләндереп, урап алу (окружать)» белән бәйле семантик кыр алдагы лексик-семантик төркемнәр белән тыгыз бәйләнештә тора.

*Ау* сүзе барлык төрки телләрдә һәм, гомумән алганда, алтай телләрендә очрый. Ләкин, вакытлар узу белән, аның мәгънәсе һәм яңгырашы нык тармакланган. Иң борынгы яңгыраш һәм мәгънәләр тунгус-маньчжур телләрендә сакланган: нанай телендә *анга* – «тозак», ульч телендә *анга* – «ятьмә, ау», эвенк телендә *анга* – «җәнлек, киек». Себер татарлары сөйләшләрендә *аң* «ау» һәм «болан» мәгънәләрендә йөри, алтай телендә *аң* – «ятьмә» һәм «киек». Татар әдәби телендә *ау* – «аулау шөгыле», «зур җылым», «ятьмә». Угыз телләрендә (төрек, төрекмән) *аг, ав*, монгол һәм казакъ телләрендә *аб, аба* – «киртәләп алып аулау» һ. б. [Халиуллина, Шайхулов, II].

Аучылык чорыннан күп кенә махсус атамалар, терминнар сакланып калган. Кайбер галимнәр төрки телләрдәге хайван исемнәрендәге -*ан* элементын (чагыштыр: *арыслан, каплан, сыртлан, кабан, колан, болан, елан, чаян, сазан, табан, йомран, тычкан, тавышкан, көзән, чытан* һ.б.) *аң, ау* –«киек» сүзеннән дип саныйлар [Әхмәтьянов, б. 56].

Гомумтөрки *агыл, авыл* [аwыл] «авыл» сүзенең борынгы *агыл* – «терлекләрне яисә аулап тотылган хайваннарны беркадәр вакыт асрар өчен ясалган ихата, катау» сүзеннән икәнлеге билгеле. Бу *агыл* исә, *аг, аң, ау* сүзе нигезендә ясалган дигән фикер бар [Севортян, с. 83–85]. Чынлап та, электән кыргый яки ярым кыргый хайван көтүләрен киртәләп алынган махсус урында асраганнар. Зур көтү күмәк мал булганлыктан, әлеге киртә тирәсенә бөтен ыру торак корып утырган – *авыл* барлыкка килгән.

Хәзерге татар телендә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче халык яши торган урын, торак пункт аңлатмалы сүзлектә *авыл* дип билгеләнә. Мәсәлән, *Авылны чыккач, Хәлим малайларга пилоткаларын салып бүрек кияргә кушты.* (Г. Гобәй)

Икенче очракта ул сүз авылда яшәүчеләр, авыл халкы мәгънәсен белдерә: *Авыл уянды. Өй түреннән, урам тутырып, көтү үтеп китте.* (Г. Гобәй) [ТТАС, т.1, б. 10].

Борынгы **аг* тамырыннан төрки телләрнең төрле төркемнәрендә кулланылган ***аулак*** *~ авлак ~ овлак ~ олак ~ авлах ~ аглах* лексик берәмлекләренең семантик төзелеше кызыклы. Мәсәлән, төрек, азәрбайҗан телләрендә – «ау урыны», «киек күп булган урын; кыргыз, каракалпак телләрендә – «ерак, кеше яшәгән урыннан ерак торган», «киң, иркен, иреклe»; татар телендә – «азсанлы», «кешесез», «иреклe»; казакъ,

кыргыз, татар, хакас, чуваш телләрендә «тыныч, кешесез урын», «утырма» һәм башка мәгънәләре күзәтелә [Севортян, с. 64].

*Аулак* лексемасының сыйфат, рәвеш, исем мәгънәләре, диалекталь вариантлары татар теленең аңлатмалы сүзлегендә ачык бирелгән:

1. *Аулак* сүзе әлеге очракта сыйфат булып килеп, тыныч, кеше йөрми торган, кешесез урын дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Тирә-юнь ничектер тын һәм аулак иде.* (К. Нәҗми) Ул рәвеш мәгънәсендә дә килергә мөмкин: *Шул усал сүзләрне уйлап, аулак калган чакларда үзем ислах өчен планнар корып маташам.* (М. Фәйзи)

2. Юнәлеш һәм урын-вакыт килешләрендә килгән *аулак* исеме кешесез, тыныч урын дигәнне белдерә. Мәсәлән, *Аулакка чакырып сөйләшү. – Сезнеңчә, шулай нәмәхрәм белән аулакта төнлә утырырга ярый?* (М. Гафури) Тезмә исем булып килгәндә – аулак өй. *Авыз күтәреп урам буйлап җырлап йөргәнем, аулакларда вакыт уткәргәнем бармы минем?* (А. Шамов)

Диалектларда, *аулак сүз* – сер, яшерен сүз; *аулак өй* – ата-ана, олылар берәр җиргә киткәч, ялгыз калган йорт; шундый йортта кич утыру яки егетләр-кызлар белән уен мәҗлесе дигәнне белдерә. Мәсәлән, *Сиңа аулак сүзем бар. Мин мәхәббәтемне аулак өй саен өләшеп йөрмәдем.* (Г. Бәширов) [ТТАС, т.1, б. 86].

Димәк, ясалма нигезләр тамырдан килгән семантиканы саклыйлар. Семантик үсеш уртак, гомумирәк тамырлардан конкрет, предметлы һәм фактик мәгънәләргә юнәлеш ала. Нәкъ шундый үзаллы сүзләр үле тамырларны торгызырга һәм аларның семантикасын реконструкцияләргә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 174 б.

ДТС – Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 677 с.

*Кайдаров А.Т.* Структура односложных корней и основ в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1986. 246 с.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на гласные. М. Восточная литература РАН, 1974. 768 с.

СИГТЯ – Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. М.: Наука, 2006. 912 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 475 б.

*Халиуллина Н.У., Шайхулов А.Г.* Тюркские языки Урало-Поволжья в контексте алтайского языкового сообщества (опыт лексико-семантического словаря): Словарь. Ч. I–II. Уфа: Восточный университет, 2004. 270 с.

*Халиуллина Н.У.* Семантическая реконструкция корневых основ в этимологическом гнезде (на материале языков алтайской семьи) // «Гуманитарные науки и образование». № 2 (26). Саранск, 2016. С. 130–135.

***Хәлиуллина Нурия Госман кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Ф.К. Сәгъдиева,***
***А.Җ. Хөсәинова,***
***Ә.К. Булатова***

# МӘДӘНИ КОНЦЕПТЛАРНЫҢ АЧКЫЧ СҮЗЛӘРЕН ЭТИМОЛОГИК ҺӘМ СЕМАНТИК ЯССЫЛЫКТА ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА
## (*акча* лексик берәмлеге үрнәгендә)

Ядро репрезентаций того или иного концепта формируют ключевые слова. В данной статье рассматривается этимология и семантическая структура многозначной лексической единицы *акча,* которая является ключевым словом культурного концепта *акча* (деньги).

**Ключевые слова:** ключевое слово, концепт, этимология, семантическая структура, акча (деньги).

The core of the representations of certain concept is formed by keywords. This article analyzes the etymology and semantic structure of the multi-valued lexical unit *aqcha*, which is the key word of the cultural concept of *aqcha* (money).

**Keywords:** key word, concept, etymology, semantic structure, aqcha (money).

Мәгълүм булганча, ачкыч сүз иң баштан тексттагы берәмлекләрнең санын билгеләгәндә кулланыла. А. Вежбицкаяның «Мәдәниятләрне ачкыч сүз ярдәмендә аңлау» («Понимание культур через посредство ключевых слов») китабы басылып чykканнан соң, әлеге төшенчә лингвистик пландагы хезмәтләрдә дә файдаланыла башлый. Монография авторы фикеренчә, ачкыч сүзләр принцибы телнең лексик составы һәм мәдәният арасындагы бәйләнешнең төп принципларыннан санала. А. Вежбицкая ачкыч сүзләрне аерым мәдәният өчен аеруча әһәмияткә ия сүзләр дип билгели [Вежбицкая, 2001].

Акча концептының ачкыч сүзе булып *акча* лексик берәмлеге санала. Әйтик, Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгында әлеге сүз һәм аның дериватлары кергән 750 дән артык мәкаль һәм әйтем теркәлгән [Сагдеева, 2012, с. 250].

*Акча* сүзенең этимологиясенә тукталып үтик. Ул борынгы төрки телдә тәңкә мәгънәсендә кулланыла. Хәзерге татар телендә *акча, сум,* (*сон, сом* – ‘көмеш, алтын, бронза коелмалары яисә санау берәмлеге’) кебек борынгы төрки нигезләре сакланып калган. М. Кашгариның «Диване лөгать әт-төрк» сүзлегендә *сом* лексемасы ‘коелма’ мәгънәсендә файдаланылган. Ә. Г. Мөхәммәдиев билгеләвенчә, XIV гасырда *сом* лексик берәмлеге коелма мәгънәсеннән тыш, аерым сандагы көмеш тәңкәләр (120 тәңкә) номеналына ия булган [Мухамадиев, 1990, с. 136–137].

В.В. Радлов *акча* сүзенең түбәндәге мәгънәләрен аерып чыгара: *акча* (ак + ча): ак, аксыл; тәңкә; санау берәмлеге; *акчӓ:* тәңкә; санау берәмлеге; *акша:* аксыл; санау берәмлеге.

*Акча* сүзенең килеп чыгышына нисбәтле төрле фикерләр яшәп килә. Бер төркем галимнәр лексема *ак, аксыл* сүзләреннән килеп чыккан дип фаразлый. Л.З. Будагов хезмәтләрендә акча اقچه сүзенең иркәләү-кечерәйтү варианты дип бирелә һәм аксыл, тәңкә, көмеш, санау берәмлеге мәгънәләрендә кулланыла. В.Э. Севортянның этимологик сүзлегендә *а:ķжҫа – акча* исемләшкән сыйфат буларак күрсәтелә: *а:ķ > аķ* «ак» > «көмеш» сыйфатында билгенең өлешчә булуын белдерүче *-жҫа/-ча* аффикслары белән, *а:кжҫа ~ акча* – «аксыл»: чагыштыр аз. *аг пул* «көмеш акча» [Мухамадиев, 1990, с. 136]. Ләкин Ә.Г. Мөхәммәдиев билгеләвенчә, аерым авторларга ияреп, Э.В. Севортян әлеге сүзне «көмеш тәңкә» дип ялгыш юлдан китә.

Л.К. Бәйрәмова *акча* термины, кайбер аерым телләрдән кала, бер генә төрки телдә дә көмеш тәңкә мәгънәсендә кулланылмаган, дип белдерә [Байрамова, 2007, с. 78].

Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә акча «деньга, деньги», тар. «единица счёта денег» ~ чув. *укҫа < окҫа,* мар. *окса*, удм. *уксё* ~ гом. төрки *акча* id., төп мәгънәсендә «ак нәрсә», ягъни «көмеш тәңкә», к. чыгт. *аķча* «ак кына», морд. м. *акша* (< нуг.) «ак, аклык, акмык» дип теркәлгән. Автор, кайбер галимнәр акчаны *агы* «кыйммәтле әйбер, иң кыйммәтле парча» сүзенә кайтарып калдыралар, дип яза. Шул ук вакытта бу фикернең тәгәллеге расланмавын искәртә.

Шулай ук *акча* сүзенең килеп чыгышына нисбәтле башка карашлар да яшәп килә. Мәсәлән, Г. Рамстедт *aqča* сүзен *агы (аγı)* «хәзинә» борынгы төрки сүзенең *-ča* кушымчасы ярдәмендә ясалган иркәләү-кечерәйтү вариантына бәйли [Рамстедт, 1957]. Төрек теленең этимологик сүзлегендә *ağı – ağ – akça* сүзенең килеп чыгышы шулай ук аңлатыла, һәм гарәпчә *hazine – хәзинә* сүзе белән бәйләнештә бирелә.

Ф.Ә. Ганиев *акча* (ак+ча) сүзен *ак* «кыйммәтле әйбер» һәм *-ча* суффиксы ярдәмендә ясалган ясалма сүз дип билгели. Шулай ук *-ча* кушымчасы этимологик яктан «кыйммәтле әйбергә якын, охшаш» мәгънәсен аңлатып килгәнен дәлилли [Ганиев, 1974: 85].

Югарыдагы күзәтүләрдән *акча* сүзенең этимологиясенә карата уртак фикернең әлегә кадәр юклыгы турында нәтиҗә ясарга мөмкин. Шулай да күп кенә галимнәр билгеләвенчә, *акча* лексик берәмлеге *ак* сүзеннән ясалган. Әмма шул ук вакытта башка карашлар да яши.

*Акча* ачкыч сүзенең семантик структурасы үзенчәлекләренә игътибар итик. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә (1977) *акча* сүзенең ике мәгънәсе бирелә: 1. Дәүләт тарафыннан чыгарылган, сату-алуда әйбер бәясенең үлчәве булып хезмәт итә торган металл һәм кәгазь билетлар. 2. *куч*. Капитал, байлык [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1977, б. 38].

Бу очракта концептның үсеше гадәттә беренчел мәгънәне билгеләүдә чагыла. Шулай итеп, моңа кадәр *акча* лексемасын аңлауда тәгәллек булмаса, бүгенге көндә әлеге тәгәлсезлек юкка чыга.

Татар теленең бертомлык аңлатмалы сүзлегендә *акча* сүзенең «кадерле нәрсә» дигән яңа лексик-семантик варианты китерелә [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 30]. Бу исә акча лексемасы мәгънә кырының киңәюе, үсүе хакында сөйли. Алты томлык татар теленең аңлатмалы сүзлегендә сүзнең инде 4 мәгънәсе ачыла: 1) Сату-алуда әйберләрнең кыйммәтен билгели торган һәм, түләү чарасы буларак, дәүләт тарафыннан чыгарылган кәгазь һәм металл билетлар. *Акча бетсә кесәдә, ефәк була мунчала.* (Мәкаль) *Бабай шап итеп пижама кесәсенә сукты: «Акча бар! Я, әйтегез, ни теләр идегез?»* (Ф. Яруллин) *Башта болгарларда Көнчыгыш акчалары йөрсә, инде X гасырдан үз акчаларын да суга башлыйлар.* (Г. Дәүләтшин) 2) Әйберләрне алмашканда гомуми эквивалент вазифасын башкара торган махсус товар. 3) Капитал, байлык, тупланган мал. *Вәли бай, атасыннан калгач, зур акчалар белән эш итте.* (К. Нәҗми) – *Бераз акча ясыйм да авылга кайтып китәм, – ди.* (Казан утлары) 4) көч. Кадерле нәрсә. *Вакыт – акча, гафил булма – кача.* (Мәкаль) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, I т., 2015, б. 112]. Алда күрсәтелгән сүзлекләрдә бирелгән мәгънәләрдән тыш тагын: «әйберләрне алмашканда гомуми эквивалент вазифасын башкара торган махсус товар» лексик-семантик варианты аерып чыгарыла. Биредә шуны искәртергә кирәк: акча – кеше тормышында аерым урын били торган махсус товар.

Акча төшенчәсенең эчтәлегенә шулай ук «хезмәт хакы» мәгънәсен дә кертеп карап була. Алга таба әлеге лексик-семантик вариант шулай ук аңлатмалы сүзлекләргә кертелер дип өметләнәбез.

Акча лексемасының анализы аның семантик нигезен ачыкларга мөмкинлек бирә. Сүзнең семантикасы «металл яисә кәгазь билгеләр» дигән категориаль + «сату-алуда әйбер бәясенең үлчәве булып хезмәт итә торган» төгәлләүче семаларыннан гыйбарәт. Әлеге төшенчә алга таба «махсус товар», «капитал», «байлык», «кыйммәтле әйбер» кебек икенчел мәгънәләр ярдәмендә конкретлаша.

Шулай итеп, *акча* ачкыч сүзе хәзерге татар телендә кәгазь һәм металл билгеләр буларак кына түгел, махсус товар, капитал, байлык, кыйммәтле әйбер буларак та карала.

## Әдәбият

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. Т. 1 (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Байрамова Л.К.* Ориентализмы в лексике и фразеологии болгарского языка: (в сопоставлении с тат. яз.). Казань: Алма-Лит., 2007. 328 с.

*Будагов Л.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Т. 1–2. СПб., 1869–1871.

*Вежбицкая А.* Сопоставление культур через посредство лексики и грамматики. М.: Яз. слав. культуры, 2001. 368 с.

*Ганиев Ф.А.* Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 231 с.

*Мухамадиев А.Г.* Древние монеты Поволжья. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 192 с.

*Рамстедт Г.И.* Введение в алтайское языкознание. М., 1957.

*Сагдеева Ф.К.* Ключевое слово как понятие лингвокультурологии // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы. Казань, 2012. С. 250–251.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: Общетюркские и межтюркские основы на гласные. М.: Наука, 1974. 768 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 475 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 2005. 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Т. 1: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145’282

***А.Ә. Бәдртдинова***

# ТАТАР ТЕЛЕ ЧАТ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ВОКАЛИЗМ СИСТЕМАСЫ
## (2017 елда Новосибирск өлкәсе Колыван районында үткәрелгән экспедиция нәтиҗәләре буенча)

В статье на основе материалов экспедиции, проведённой сотрудниками Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова в июне 2017 года в татарских сёлах Юрт-Оры и Юрт-Акбалык Колыванского района Новосибирской области, сделан фонетический анализ гласных звуков чатского говора в сравнении с системой вокализма среднего диалекта современного татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, диалект, восточный диалект, чатский говор томского диалекта, вокализм, гласные звуки, анлаут, инлаут, ауслаут, сингармонизм.

The article is based on the materials of the expedition, conducted by employees of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov in June 2017 in the Tatar villages of Yurt-Ora and Yurt-Akbalyk, Kolyvan district of the Novosibirsk region. A phonetic analysis of the vowels of the Chat sub-dialect in comparison with the vocalism system of the middle dialect of the modern Tatar language was made.

**Key words:** Tatar language, dialect, oriental dialect, Chat sub-dialect of Tomsk dialect, vocalism, vowels, unlaut, inlaut, auslaut, synharmonism.

Бүгенге көндә татар теле сөйләшләре буенча гаять бай материал тупланды. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты диалектологлары тарафыннан эшләнгән «Татар диалектларының атласы»н моның күркәм үрнәге итеп күрсәтергә мөмкин [Атлас татарских народных говоров, 2015]. Әмма «татар теленең диалект телен өйрәнү көчәйтелергә һәм бу юнәлеш даими өйрәнелеп торырга тиеш, җирле сөйләш һаман да хәрәкәттә, анда яңалыклар, тормыш-көнкүреш үзгәрә бару, иҗтимагый үсеш барышында синхрон рәвештә яки башка үзгәрешләр белән бергә, яңа үзенчәлекләр туа тора» [Рамазанова, 2016, б. 81]. Бүгенге көндә татар теле диалектларын ареаль планда өйрәнү аеруча әһәмиятле юнәлеш булып тора.

2017 елның июнь аенда Институт галимнәре тарафыннан Новосибирск өлкәсенең Колыван һәм Каргат районнарына экспедиция оештырылды. Моңарчы алар 2013 елда, Казан федераль университеты студентлары белән бергә, Новосибирск өлкәсенең Чан, Кыштым, Куйбышев, Венгер, Бараба районнарына экспедициягә чыкканнар иде инде [Хисамов, 2013, с. 336]. Монда яшәүче бараба татарларының формалашу, телләрен өйрәнү тарихы, сөйләшләренең фонетик үзенчәлекләре турында О.Р. Хисамов «Об итогах экспедиции

к барабинским татарам» дип исемләнгән мәкаләсендә язды [Хисамов, 2013, с. 337].

Бүгенге көндә Каргат районында – бараба татарлары, Колыван районында чат татарлары яши. Әлеге мәгълүматны шушы территорияләрнең тарихына, этник составына багышланган күп кенә хезмәтләрдә очратырга мөмкин. Мәсәлән, Л.П. Чернобай «Малые реки левобережья Оби» (2011) китабында болай яза: «Еще в первом веке II тысячелетия нашей эры начинается процесс слияния народов в новые этнические группы. Они и сегодня живут в этих местах. У реки Обь Новосибирска – чатские татары, в Барабинских степях – барабинские татары, на севере области – северные группы хантов и селькупы» [Байрамова, 2017]; «Юрт-Акбалык (Курбес аул) – Новосибирская область, Колыванский район, Новотроицкое сельское поселение... В деревне проживают представители обских чатов... Юрт-Оры (Умар аул) – Новосибирская область, Колыванский район, Скалинское сельское поселение... В деревне проживают представители обских чатов» [Хисамов, 2016, с. 48] һ. б.

Бу мәкаләнең максаты – Колыван районының Умар һәм Акбалык авылларында яшәүче чат татарлары сөйләшенең вокализм системасын анализлау, татар теленең урта диалекты белән чагыштырма аспектта тикшереп, уртак һәм аермалы якларны күрсәтү.

Шушы максаттан экспедиция вакытында яздырылган җирле халык сөйләме үрнәкләре тикшерелде. Барысы 15 информанттан яздырып алынган текст анализланды. Аларның яше: 45 тән алып 90 га кадәр, 10 хатын-кыз һәм 5 ир-ат, белемнәре – төрле (башлангычтан алып югары белемгә кадәр). Мәкаләдә без берничә текст үрнәгенә генә тукталдык, шулай ук фонетик сыйфатларга ия сүзләр авыл халкы телендәгечә транскрипциядә бирелде.

Чат сөйләше себер татарларының том диалектына керә. Билгеле булганча, татар теле өч диалектка бүленә: көнчыгыш, көнбатыш һәм урта [Рамазанова, 2010, б. 94]. Д.Г. Тумашева көнчыгыш диалектның түбәндәге классификациясен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде: тубыл-иртыш, том һәм бараба диалектлары. Тубыл-иртыш диалекты үзе биш сөйләшкә бүленә: түмән, тубыл, саз ягы, тәвриз һәм тара сөйләшләре; том диалекты ике сөйләшкә бүленә: явештә-чат һәм калмак сөйләшләре [Татар лексикологиясе, т. 2, 2016, б. 143]. Явештә һәм чат сөйләшләрен еш кына кушып карыйлар, чөнки алар «аеруча якын», охшаш, әмма без аерып карадык, чөнки Умар һәм Акбалык авылларында чат сөйләше вәкилләре яши. Ә явештә сөйләше вәкилләре Том шәһәренең Киров районына караган Явештә авылында гомер итә [Рамазанова, 2016, б. 81].

Чат сөйләше Умар авылында яхшы сакланган. Алар милли-мәдәни үзаңнарын саклап калганнар. 1994 елда Колыван районының Умар авылы, истәлекле урын буларак, Новосибирск өлкәсенең тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре исемлегенә кертелгән һәм дәүләт сагындагы объект итеп карала [Уникальный татарский музейный..., 2018].

Умар авылында чатлар яшәсә, Акбалык авылында чат татарлары белән бергә Идел буеннан килгән казан татарлары да яши. Шуңа күрә бу авылда катнаш сөйләш өстенлек алган. Бу шулай ук әдәби тел йогынтысы да, чөнки массакүләм мәгълүмат чараларының тәэсире зур.

Том диалектының чат сөйләшен Д.Г. Тумашева өйрәнгән. «Язык сибирских татар» хезмәтендә ул сөйләшнең төп лингвистик билгеләрен тасвирлый. «В 1964 г. один из отрядов экспедиции обследовал также деревни Юрт-Акбалык и Юрт-Оры (Умар) Колыванского района Новосибирской области, которые, по всей вероятности, принадлежат чатам. Материалы не использованы» [Тумашева, 1968, с. 5] дип язса да, ул санаган чат сөйләше сыйфатлары, өйрәнелгән Умар һәм Акбалык авыллары сөйләше үзенчәлекләренә туры килә.

Д.Б. Рамазанованың «Себер татарларының том диалекты» мәкаләсендә дә сөйләшнең үзенчәлекләре саналган.

«Татар халык сөйләшләре» (2008) җыентыгындагы географик белешмәдә без барган авыллар күрсәтелмәсә дә, сөйләш турында күп язылган. Татар халык сөйләшләре атласында изоглассалар күрсәтелгән.

Явештә-чат сөйләше белән тубыл-иртыш һәм урта диалектлар арасында күпмедер дәрәҗәдә уртаклыклар бар [Рамазанова, 2016, б. 84]. Тубыл-иртыш диалекты белән якынлыкның нигезендә озак еллар дәвамында бер географик территориядә яшәү тора, урта диалектка якынлыкны татар әдәби теленең йогынтысы (беренче чиратта, мәктәп һәм матбугат чараларының тәэсире) белән аңлатып була [шунда ук]. Явештә-чат сөйләше сузык авазлар составы ягыннан әдәби телдән нигездә аерылмый [Булатова, 2016, б. 180].

Соңгы тикшеренүләр урта диалектта [а] авазының дүрт вариантын барлыгын күрсәтә: [о$^{а}$] – көчле иренләшкән, [а$^{о}$] – уртача иренләшкән, [а] – ачык («көнбатыш диалектка характерлы»), [а$^{\wedge}$] – көчле ачык [Хабибуллина, 2002, с. 4]. Экспедиция материаллары нигезендә [а] авазының анлаутта өч вариантын ачыкладык: [о$^{а}$] – көчле иренләшкән: *[о$^{а}$тием] – әтием (Акбалык авылы – алда А.), [о$^{а}$ти] – әти (Умар авылы, алда – У.), [бо$^{а}$- бай] – бабай (А.);* [а$^{о}$] – уртача иренләшкән: *[ба$^{о}$сам] – басам (У.) (монда – камыр басу турында),* [а] – ачык: *[кастрүл] – каструля (У.)* һ. б.

[ә] авазының урта диалектта ике варианты бар: әдәби телдәге алгы рәт сузыгы һәм әдәби телдәгедән алдарак әйтелешле сузык. Өйрәнелгән территорияләрдә: 1) әдәби телдәгечә алгы рәт сузыгы; 2) анлаут һәм инлаутта [а] авазына охшаган бераз арттарак әйтелешле сузык: *[сә$^{а}$чәк] – чәчәк (У.), [$^{т}$чә$^{а}$к-$^{т}$чә$^{а}$к] – чәк-чәк (У.), [ә$^{а}$ни] – әни (А.), [Мә$^{а}$йсәрә] – Мәйсәрә (А.), [чә$^{а}$нечке] – чәнечке (А.), [ничә$^{а}$гә] (У.).*

[ы] авазы урта диалектта да, чат сөйләшендә дә әдәби телдәгечә. Кайбер очракларда ирен сузыклары тәэсирендә [ы$^{о}$] әйтелә. Шулай ук инлаут һәм бигрәк тә, ауслаутта [ы$^{а}$] варианты да еш очрый, кайвакыт ул [а] авазына да күчә: *[қараңқы$^{а}$] – караңгы (У.), [парама*

*(парамы)] – барамы (У.), [тотана идек] – тотына идек (У.)* һ. б. Бу тенденцияне М. Р. Булатова да ассызыклый: *[туйғынча] – туйганчы, [йаңы] – яңа]* [Булатова, 2016, б. 218]. Урта диалектта да [ы] һәм [а] авазлары тәңгәллекләре бар: *[сазамақ] – сазамык, [шушанда] – шушында*, һәм, киресенчә: *[барғынчы] – барганчы* [Татар халык сөйләшләре, кит. 1, 2008, б. 22].

Урта диалектта [о], [ө] авазлары әдәби телдәгечә әйтелә. Шулай да, искәрмәләр дә бар, дөбъяз сөйләшендә, авазлар [е], [ы] авазлары белән алышына: *[кету] – көтү, [былын] – болын* [Татар халык сөйләшләре, кит. 1, 2008, б. 21]. Чат сөйләшендә [о] авазының борынгы төрки тел эзләре сакланган: *[туқмач] – токмач (А.), [қонақ] – кунак (А.), [оғу] – уку, [омыртқа] – умыртка, [қошылышып] – кушылышып (У.), [урчық] – орчык, [ғумер] – гомер (У.), [қонақлар] – кунаклар (А.).*

Алгы рәт [ө] авазының арткы рәт [о] авазы белән алышынган очраклары бар: *[моселманча] – мөселманча (У.).*

Алгы рәт [ү] авазы күп чоракта арткы рәт [у] авазына охшаган: *[қукә$^{а}$й] – күкәй (У.).*

Сөйләштәге аваз тәңгәллекләре: [ә]//[е]: *[бәзнең] – безнең (А); [ә]//[и]: [әртән] – иртән (У.); [ы]//[и]: [зырат] – зират (У.), [Нурыйа] – Нурия (А.);[ы]//[е]: [чымын] – чебен (У.);[е]//[и]: [ет] – ит (У.), [сигез] – сегез (У.), ненди – нинди (А.), ден – дин (А.), зеңгер – зингер (У.)(синий); [ө]//[ү]: көк – күк (А.) (небо), көгәрчен – күгәрчен (У.), төгел – түгел (У.); [е]//[ө]: сет – сөт (У.).*

Рәт гармониясе, урта диалекттагы кебек, күп очракларда саклана: *[наурус] – нәүрүз (А.). [Наурус]* сүзендә алгы рәт сузыкларының арткы рәт сузыклары белән алышынганын күрәбез. Палаталь гармония бозылган очраклар да бар: *[сәксан] – сиксән, [баради] – бара* һ. б. [Татар халык сөйләшләре, кит. 2, 2008, б. 429], *[ничә$^{а}$гә пешерә$^{а}$сең] – ничәгә пешерәсең (У.).*

Көнчыгыш диалектларында ирен гармониясе «көчле» гармония санала: *[озон] – озын (А.),* аңа хәтта ирен гармониясе булмаган сүзләр дә буйсына: *[мончо] – мунча* [Сөнгатов, 2001, б. 12]. Бу күренешне Г.М. Сөнгатов болай аңлата: борынгы [о] сакланган вакытта, башка иҗекләрдә дә [о] авазы әйтелә: *[тоқто] – тукта (У.), [болодоғон] – була торган (У.)* [Сөнгатов, 2000, б. 15]. Шулай ук [а], [ә] авазлары да [о], [ө] авазлы иҗекләрдән соң ирен гармониясенә буйсына: *[болғон] – булган, [сөйлөшкөлө] – сөйләшергә* [Татар халык сөйләшләре, кит. 2, 2008, б. 429].

Башка фонетик закончалыклардан сандхи күренешләренең элизия очраклары бар: *[йөрәйдек] – йөри идек (У.), [әйбит] –әйе бит (әйеме) (У.), [тийағъында] – теге ягында (А.).* Аккомадация күренеше: *икән – игән (А.),* редукция очрагы: *крәшеннәр – керәшеннәр (А.) (кряшены);* эпитеза: *[навасибирскиға], [свиртловскиға].*

Рус теленнән кергән сүзләрдә, урта диалекттагы кебек, рус авазлары сөйләшнең үз авазлары белән алышына: *[сих] – цех (А.), [Илмирә] – Эльмира (А.), [пинсы] – пенсия (А.), [шкул] – мәктәп (А.),*

*[уптым] – күп, бөтен килеш (оптом) (У.).* Бу сүзләрдә эпинтеза күренеше дә чагыла.

Шулай итеп, том диалектының чат сөйләше һәм урта диалект вокализм системаларының түбәндәге дифференциаль һәм гомуми билгеләрен күрсәтергә мөмкин:

1) өйрәнелгән территорияләрдә сузык авазларның арттарак әйтелешле вариантлары бар һәм күп кенә сүзләрдә сузыклар арткы рәт парлары белән алышынып, рәт гармониясе бозыла, мәсәлән, анлаутта һәм инлаутта [ә[а]] авазы: *[сә[а]чәк] – чәчәк (У.), [ничә[а]гә пешерә[а]сең] (У.);*

2) ирен гармониясе «аеруча көчле», урта диалектта ирен гармониясенә буйсынмаган сүзләр дә иренләшә;

3) урта диалектта [ы] авазының әдәби телдәге варианты кулланыла, чат сөйләшендә инлаут һәм ауслаутта тагын ике варианты бар: [ы[о]] һәм [ы[а]];

4) чат сөйләшендә борынгы төрки тел эзләре сакланган, бу үзенчәлек [у], [ү], [о], [ө] авазлары әйтелешендә күренә;

5) эпитеза күренеше урта диалектта да, чат сөйләшендә дә бер үк: [навасибирскига] һ. б.

6) [и] һәм [е] тәңгәллеге.

Бу нәтиҗәләрне мәкалә азагында бирелгән текст үрнәкләрендә дә күзәтергә була.

## Текст үрнәкләре

№ 1

(Урама – чат татарларының традицион камыр ризыгы – пешерү процессын сөйли) *[ҡукә[а]й // ничагә пешерасең / ул ҡукәйгә әз генә соды саламын / әз генә шикәр әз генә тоз саламын да йомшаҡ баосамын / туҡмач формысында // туҡмач формысында җәйәм мондый итеп / и менә мондыйға кисәсең аны / майны ҡайнатасың да мондый тайаклар бар / тайакҡа менә мондый итеп урыйсың да теге кастрүлдәге майда нитеп торасың / әйләндереп торасың / моннан икенче ҡул белән алып торасың / кичка пешереп күрсәтермен алла бирса / арымасам бик ...* (Су анасын күрү турында сөйли) *[өйәандә күргән идем су анасын / кийәүгә чыкҡанчы / ә ул менәкә / баҡчада монда өйән иде / күпер // күпердә багана җе свайлар / аларга менеп утырды да менә мондый итеп чачен тарый / җиргә хәтле чаче / менә мондый итеп тарады тарады да суга менә мондый төшеп китте / су йарылып китте дажы / ҡап-ҡара чачле тәне ап-аҡ]*

(Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы,
1931 елгы, Колыван районы, Умар авылы)

№ 2

(Җырдан өзек) *[ағидел буйлары йәмле акҡошлар уйнағанға йәш ғумерләр бик тиз үтә гел уйлар уйлағанға йыр йырласаң акрен*

*йырла табышың йаңғрамасын сүнгән йөрәк сүнсен инде ул тағын йаңармасын]*

(Шиһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкәрнәй кызы,
1928 елгы, Колыван районы, Умар авылы)

**Әдәбият**


Атлас татарских народных говоров / отв. ред.: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. Изд. 2-е, доп. и перераб. Казань: ИЯЛИ, 2015. 632 с.

*Байрамова Ф.А.* Сибирская цивилизация (ч. 2) // Сайт «Московское татарское свободное слово» [Москва, 2017]. Режим доступа: URL: http://www.mtss.ru/?page=%2Ff_bajram%2Fcat (Дата обращения: 14.02.2019).

*Булатова М.Р.* Томск татарларының тел үзенчәлекләре һәм рухи мәдәнияте // Национально-культурное наследие: татары Томской области = Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары. Казан: ТӘҺСИ, 2016. 432 б.

*Рамазанова Д.Б.* Йөзләре якты, телләре татлы (Актаныш төбәге тел үзенчәлекләре) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. Казан, 2010. Б. 93–132.

*Рамазанова Д.Б.* Себер татарларының том диалекты // Национально-культурное наследие: татары Томской области = Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары. Казан: ТӘҺСИ, 2016. Б. 84–132.

*Сөнгатов Г.М.* Татар диалектларының фонетикасы. Казан: КДУ оператив полиграфия лабораториясе, 2000. 44 б.

*Сөнгатов Г.М.* Татар теленең фонетик закончалыклары. Казан: КДУ оператив полиграфия лабораториясе, 2000. 54 б.

Татар лексикологиясе: 3 томда. Т. 2 / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. 392 б.

Татар халык сөйләшләре. 2 китапта. 1 кит. / *Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова, Р.С. Барсукова* Казан: Мәгариф, 2008. 493 б.

Татар халык сөйләшләре. 2 китапта. 2 кит. / *Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова, Р.С. Барсукова* Казан: Мәгариф, 2008. 493 б.

*Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1968. 185 с.

Уникальный татарский музейный комплекс открыт под Новосибирском. // Сайт информационного агентства «Тайга.инфо» «Главные новости Сибири» [Новосибирск, 2018]. URL: https://tayga.info/141292 (Дата обращения: 18.02.2019).

*Хабибуллина М.Р.* Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвистическом пространстве: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань: 2002. 28 с.

*Хисамов О.Р.* Об итогах экспедиции к томским татарам // Филология и культура. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 201. № 4 (34). С. 336–337.

*Хисамов О.Р.* Тюрко-татарская топонимия Томской области // Национально-культурное наследие: татары Томской области = Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2016. 432 с.



***Бәдртдинова Алсу Әнис кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 82-821

***Ә.Х. Алиева,***
***Г.Н. Зәйниева***

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ЯҢА БАСМАСЫ

В статье освещаются вопросы, связанные с подготовкой к изданию первых пяти томов пятнадцатитомного академического собрания сочинений классика татарской литературы Галимджана Ибрагимова. Определяются новации нового издания, отличающие его от предыдущего восьмитомного собрания сочинений. Выделяются произведения писателя, ранее не включенные в собрание сочинений писателя, а также не опубликованные в восьмитомном собрании сочинений варианты отдельных произведений («Татар хатыны ниләр күрми», «Безнең көннәр»). Акцентируется внимание на принципах передачи языковых особенностей источников (орфографии, пунктуации).

Делается вывод о том, что новое академическое издание восполняет существующие в текстологии Г. Ибрагимова лакуны и открывает новые возможности для исследователей его творчества.

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, татарская литература, академическое издание, текстология произведений Г. Ибрагимова, вариант, редакция.

The article covers issues related to the preparation for publication of the first five volumes of the fifteenth academic collection of works by the classic of Tatar literature Galimdzhan Ibrahimov. The innovations of the new edition that distinguish it from the previous eight-part collection are determined. The works of the writer that were not previously included in the collected works of the writer, as well as the versions of certain works not published in the eight-volume collection of works («Tatar Hatyny nilər kүrmi» – «What just does not happen with Tatar woman», «Bezneng kenner» – «Our days») are highlighted. Attention is focused on the principles of the transfer of sources' linguistic features (spelling, punctuation).

It is concluded that the new academic publication fills the lacunae existing in G. Ibrahimov's textology and opens up new opportunities for researchers of his work.

**Keywords:** G. Ibrahimov, Tatar literature, academic publication, textual works of G. Ibrahimov, version, editorial.

Күренекле язучы, яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе, кабатланмас талант иясе Г. Ибраһимовның (1887–1938) иҗади һәм сәяси эшчәнлеге социаль һәм иҗтимагый алмашынулар, революцияләр чорына туры килә. Аның иҗаты тулаем алганда шул чорны чагылдыра. Бу – чын мәгънәсендә, тарихи-әдәби-мәдәни тормышның Г. Ибраһимов әсәрләрендә яктыртылышы. Аның иҗаты татар халкының иң күркәм традицияләрен гомумкешелек мәдәниятенең алдынгы казанышлары белән янәшә куя, баета.

Г. Ибраһимов – XX гасыр башы, 1920–1930 еллар иҗтимагый хәрәкәтендә һәм әдәби процессында күренекле урын тоткан шәхесләрнең берсе. Ул әдип һәм публицист буларак та, киңкырлы

галим, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе сыйфатында да татар җәмәгатьчелегендә танылу ала. Үзе исән вакытта ук татар әдәбияты классигына әйләнеп, иҗаты татар әдәбиятын үзгәртүгә, камилләштерүгә хезмәт итә. Тел белеменә һәм әдәбият белеменә (теориясенә һәм тарихына) караган, педагог һәм методист буларак тел һәм әдәбият укыту мәсьәләләрен яктырткан, XX гасыр башы татар иҗтимагый хәрәкәте тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләре, шул дәвернең әһәмиятле тарихи һәм мәдәни вакыйгаларын тирән анализлаган яисә күзәтү ясаган публицистик язмалары бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Шул сәбәпле, Г. Ибраһимовның бай гыйльми һәм иҗади мирасын текстологик яктан эшкәртеп, тулыландырылган басмаларын әзерләү – заман таләбе, бүген гуманитар фәннәр алдында торган мөһим мәсьәләләрнең берсе.

Әле XX гасырның 20–30 нчы елларында, рус классиклары әсәрләренең тулы басмаларын әзерләү үрнәгендә, татар классик әдипләренең дә күптомлыкларын китап итеп бастыру башлана. 1929–1931 елларда «Яңалиф» нәшриятында «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре» җыелмасы итеп чыгарырга уйланган җидетомлыкның 2 нче (1929), 5 нче (1931) һәм 6 нчы (1930) томнары нәшер ителә [Ибраһимов, 1929–1931]. 1933–1934 елларда әдипнең биш китаптан торган «Сайланма әсәрләр»е [Г. Ибраһимов, 1933–1934], 1936 елда дүрттомлык буларак күздә тотылган «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче һәм 3 нче томнары укучы кулына тапшырыла [Ибраһимов, 1936].

XX гасырның Сталин репрессияләре Г. Ибраһимовны да читләтеп узмый, бай әдәби мирасы китап киштәләреннән, мәктәп дәреслекләреннән алына. Нәтиҗәдә, язучының әдәби әсәрләре, фәнни хезмәтләре 20 елга якын әдәбият мәйданында онытылып торуга дучар ителә.

Сталин вафатыннан соң, бик күп шәхесләрнең исемнәре аклана, мираслары кайтарыла башлый. Шулар арасында Г. Ибраһимов та була. Тиз арада әзерләнеп, 1956–1957 елларда әдипнең өч томлы «Сайланма әсәрләр»е басылып чыга [Ибраһимов, 1956–1957]. 1974–1987 елларда сигез томлы тупланмасы дөнья күрә [Ибраһимов, 1974–1987]. 1990 елларда әдипнең тормыш юлын, аралашу даирәсен күзалларга ярдәм иткән шәхси хатларын һәм архив документларын эченә алган 9 нчы томы әзерләнә, ул 2000 елда, сигезтомлыкка өстәмә итеп бастырыла [Ибраһимов, 2000].

Югарыда телгә алган сәбәпнең Г. Ибраһимов томнарының басылып чыгуына, аларның төзелешенә дә тәэсире була, әлбәттә. Томнарга керергә тиешле күп кенә хезмәтләр читкә куела, болар инде күптомлык төзелешендә үзгәрешләр китереп чыгара. 1974–1987 елларда басылган томнарның структурасында һәм эшләнешендә шактый төгәлсезлекләр булу да аерым игътибар таләп итә. Әдәби әсәрләрнең кайберләре хронологик таләпләргә җавап биреп бетерми (моны сигезтомлыкны төзүчеләр үзләре дә искәртеп китә), тел яисә әдәбият һәм сәнгатькә караган кайбер мәкаләләре публицистик томга урнаштырылган, аерым очракларда шуның киресе дә күзәтелә. Әдәби

һәм тарихи хезмәтләргә караган бәяләмәләр шулай ук публицистик томнарда бирелгән [Ибраһимов, 2018, т. 1, б.7–8].

Совет чорындагы идеологиягә туры килмәгән әсәрләрне, бастырып, халыкка тәкъдим итү мөмкин булмаганга, Г. Ибраһимовның сигезтомлыгында шактый кыскартылмалар (квадрат җәяләр [..] белән күрсәтелгән) әдип иҗатының тулы булмавын раслый.

Кыскартылган өлешләр, нигездә, идеологик моментлар белән бәйле. Мәсәлән, 1912 елда (Йолдыз, 1912, № 780) басылып чыккан «Әдәбият» исемле зур мәкаләдә (тугызтомлыкның 8 нче томында урын алган) 1937 еллар репрессиясенә эләккән талантлы татар галимнәренең исемнәрен телгә алырга да ярамаганлыктан, Касыйм Бикколов, Фатих Кәрими, Зәки Вәлиди, Һади Атласов, Габделбари Батталларның милли тарихны яктырткан, әле бүгенге көндә дә әһәмиятләрен югалтмаган хезмәтләре төшереп калдырылган. Менә ул өзек: «Яз көне юбилей ядкәренә «Татар ханнары» (Бикколов Касыйм. Татар ханнары, 1911. 34 б.) чыккан иде. Бу ел көзге уку фасылына мәшһүр мөхәрриремез Фатыйх Кәримов җәнабләренең зур гына күләмдә «Мөхтәсәр тарих гомуми»се чыгып, мөһим бер ихтыяҗны каплады. Дәхи дә имам Хәлиди әфәнденең бик зур гына «Тәварих хәмсә»се чыкты. Бу шундый әсәр ки, теленең авырлыгына, тәртибенең кыенлыгына карамыйча баштан-аяк укып чыга алган адәмне «моталәга *(уку)* каһарманы» дип атарга, бу чыдамы өчен наград *(бүләк)* бирергә ярый. Шуның илә бәрабәр моңа кертелгән зур хезмәтне кызганмый үтеп булмый.

Мәкаләләре илә мәгълүм булган Һади әфәнде Атласов та бу ел үзенең «Себер тарихы»ннан беренчесен тәмам итеп басарга бирде. Зур мөстәшрикъларның *(Шәрыкны өйрәнүче галимнәрнең)* могтәбәр *(танылган)* әсәрләреннән алып язылып та, нашерләрнең игътибарсызлыгы сәбәпле, берничә еллар кулда йөрергә мәҗбүр булган дәхи бер «Татар вә төрек тарихы» атлы әсәр бу ел матбагага алынды (Зәки Вәлиди әсәре).

Дәхи берничә егетнең татар тарихына, «Чыңгызхан»га гаид язган әсәрләрен тәмам итдекләре мәгълүмдер.

Гомумән, бу ел һәр якта тарих, бигрәк тә милли тарих баш күтәрде. Басылып чыккан тарих китапларында «татарның әүвәлге шан вә шәрәфенә, борынгы каһарманнарының куәт вә кәмаленә» тиешле дәрәҗәдә игътибар тимәдеке өчен, газета галәмендә бераз тавышлар да булды. «Йолдыз»да Г. Баттал әфәнденең «Татар ханнары» китабы хакында язган ачы тәнкыйтен (Баттал Г. Татар ханнары. *Тәнкыйть*. Йолдыз, 1911, 3 декабрь, № 1700) укыгансыздыр. Бу заһырда *(өстән караганда)* артык зур нәрсәле күренмәсә дә, төбен уйлаганда, безем халыкта да үзенең үткәненә, каһарманнарына сөеп карау башлаганын – хәят галәмәтен белдерә. Буны каләм илә язылган бер мәкалә дип түгел, бәлки борынгы шәүкәтне *(көч-куәтне, бөеклекне)* каралаучыларга каршы милли хиснең беренче протесты, татарлыкның ачык кайнавы дип карарга кирәк».

Тагын бер нәрсәне әйтик, тугыз томлыкның 5–8 нче томнарында телгә алынган реаль шәхесләр, дини-мифологик исемнәр, җыентык, альманах һәм газета-журналларның алфавит тәртибендәге күрсәткечләре дә китерелә (аларны Р. Гайнанов, З. Рәмиев, С. Алишев, Ф. Фәсиев, Л. Гайнанова, Р. Даутовлар төзегән иде). Бу да әсәрләрнең тирәнрәк үзләштерелүенә юл ача, галимнәргә фактик материал җыярга ярдәм итә. Тагын шул ук нәрсә: бу күрсәткечләр совет заманында һәм сыйнфыйлык позициясеннән чыгып әзерләнгәнлектән, кайбер шәхесләргә бирелгән бәяләр хакыйкатькә туры килеп бетми (мәсәлән, «буржуаз тарихчы», «ак эмигрант», «дини-реакцион журнал», «буржуаз милләтче», «пантюркист» тамгаларын тагу).

Үз вакытында Г. Ибраһимовның тугыз томлы иҗатын кайтару юлында әдәбиятчы-текстологлар, тарихчылар, телчеләр зур эш башкарды.

Ләкин материалларның күплеге, элекке томнарның камил эшләнмәве, искәрмә һәм аңлатмаларның, әдипне шәхес буларак ачкан, шул заманның иҗтимагый хәрәкәте, шәхесләре хакында мәгълүматларның җитәрлек, ышанычлы, дәлилле булмавы һәм вазгыятьтәге үзгәрешләр Г. Ибраһимов әсәрләре текстологиясен дә югарырак баскычка күтәрүне таләп итә.

Институт җитәкчелеге текстологлар алдына Г. Ибраһимовның унбиш томлы академик басмасын әзерләү бурычын куйды.

Анда әдипнең бөтен табылган әсәрләре, әсәрләрнең вариантлары керергә, текст тарихлары җентекләп тикшерелергә, аңлатмалар һәм искәрмәләр тулы, объектив булырга тиеш.

Унбиш томлы академик басма эшләү максатка ярашлы дип табылды. Бу үзен аклый да. XX гасыр башы әдәби һәм фәнни, иҗтимагый хәрәкәтен күзәткәндә һәм җентекле өйрәнгәндә, Г. Ибраһимов кебек әдәби жанрларда, гуманитар фәннәрнең төрле тармакларында нәтиҗәле эшләгән, көчле публицистик мәкаләләре белән һәркемнең игътибарын җәлеп иткән башка шәхесне аерып күрсәтү кыен. Бу факт Г. Ибраһимовның мирасын үзгәртмичә, кыскартмыйча халыкка кайтаруны сорый. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләре шул максатны алга куеп эшкә керește.

Г. Ибраһимовның унбиш томлы академик басмасы сигез томлы «Әсәрләр» тупланмасыннан төзелеше белән нык кына аерыла. Хезмәтләр һәм язмаларны урнаштыру тәртибе академик басма төзү таләпләре буенча укучы өчен дә уңайлы итеп эшләнде.

Академик басманың фәнни төзелеше, иң беренче чиратта, Г. Ибраһимовның татар әдәбияты классигы булуын истә тотып билгеләнде. Әдәби әсәрләре – 1–5 нче томнарга, бөтен иҗат гомере гуманитар фәннәргә хезмәт итүгә багышлануын күздә тотып, әдәбият һәм сәнгать турындагы мәкалә һәм хезмәтләре – 6–8 нче томнарга, тел белеме һәм аны укыту методикасына кагылышлы гыйльми эшләре – 9–10 нчы томнарга, татар тарихын барлауга, тарихны тикшерү принципларына караган язмалары – 11–12 нче томнарга һәм XX гасыр

башының актуаль мәсьәләләрен, заман вакыйгаларын яктырткан публицистик мәкаләләре – 1–14 нче томнарга, тормыш юлы һәм иҗатына бәйле хатларны, архив чыганакларын исә 15 нче томга урнаштыру планлаштырылды.

Томнар ахырында текстологиянең фәнни принципларына һәм классик әдипләрнең академик басмасын әзерләү таләпләренә туры китереп кушымта, искәрмә һәм аңлатмалар, исемнәр күрсәткече, томнарның эчтәлеген бирергә тәкъдим ителде.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның унбиш томлы академик басмасы әдипнең рухи-мәдәни мирасын тулысынча укучыга кайтарырлык итеп уйланылды. Бу басма аны татар укучысына яңа яклардан ачар, әдип һәм галим, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм публицист буларак үзенә лаеклы югарылыкта бәяләргә ярдәм итәр дип ышанабыз. Ниһаять, 2018 елның ахырында Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 1–5 нче томнары Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

Шушы уңайдан быелның 11 мартында «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, журналистлар һәм Татарстан китап нәшрияты редакторлары катнашында матбугат очрашуы узды.

Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең унбиш томлы академик басмасының 1 нче томында [Ибраһимов, т. 1, 2018] бай иҗат мирасы калдырган олы язучыбызның беренче тәҗрибәсе дә, уңышының башы да булган 1907–1916 елларда иҗат иткән хикәяләре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Гыйшык корбаннары», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә», «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «...мәрхүмнең дәфтәреннән», «Габдрахман Салихов» һәм 1924 елда басылып чыккан «Казакъ кызы» романы урын алды. Язучының башлангыч чор хикәяләре («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Гыйшык корбаннары», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә») сигезтомлыкның «Кушымта» өлешендә бирелгән булсалар, хәзерге басмада алар, язылу елларына карап, төп өлешкә кертелде. Академик басманың 2 нче томында «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре, ике вариантын янәшә урнаштыру сәбәпле, «Казакъ кызы» романы, хронологик принциптан чигенеш ясап, 1 нче томга кертелде.

Филология фәннәре докторы Д.Ф. Заһидуллинаның томга кереш итеп язылган «Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗкырлы эшчәнлеге» исемле мәкаләсе Г. Ибраһимов иҗатын тулысы белән күзалларга ярдәм итә. Монда аңа язучы буларак та, галим, публицист, дәүләт эшлеклесе буларак та бәя бирелә.

Мәгълүм ки, Г. Ибраһимов кайбер әсәрләрен, басылып чыкканнан соң да, яңадан редакциялəп, кабат басмага әзерли. Бу язучының Октябрь революциясеннән соңгы иҗатында аеруча чагылыш тапкан. Шулай ук басмалар арасындагы аермалар нәшрият мөхәррирләренең дә роле белән бәйле.

Томнарны әзерләү этабында әдип үзе исән вакытта гарәп яки латин язуында дөнья күргән барлык басмалар да чагыштырылып, текстологик яктан җентекләп тикшерелде, фәнни-тәнкыйди анализ ясалды. Үз вакытында әсәрдән сәяси-идеологик вазгыятькә бәйле төшереп калдырылган урыннар торгызылды һәм төп текстлардагыча бирелде.

Бу яңа басманың 2 нче томына [Ибраһимов, т. 2, 2018] Октябрь революциясенә кадәр иҗат ителгән «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең беренче варианты (1910), соңрак шул әсәрнең автор тарафыннан үзгәртелеп язылган икенче варианты (1929) һәм «Яшь йөрәкләр» романы (1912) туплап урнаштырылды.

«Татар хатыны ниләр күрми» әсәре 1909 елда язылып, 1910 һәм 1911 елларда бернинди үзгәрешсез аның ике басмасы дөнья күрә. Биредә алар текстологик яктан чагыштырылды. Текстта телгә алынган атамаларга, реаль шәхесләргә һәм алар белән бәйле дини риваятьләргә шәрехләр бирелде. Әсәр әдипнең күптомлыкларына беренче мәртәбә кертелә.

Автор тарафыннан яңабаштан эшләнгән «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең икенче варианты исә беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 1929 елда чыккан 2 нче томында басыла. Соңрак әдипнең «Сайланма әсәрләр»енең 1934 елда чыккан 5 нче томына, 1956 елда басылган 3 нче томына һәм 1975–1986 елларда чыккан сигез томлы «Әсәрләр»енең 1 нче томына кергән.

Әсәрнең беренче варианты күләм ягыннан 80 бит чамасы булса, яңа варианты исә ике тапкыр артыграк. Автор тарафыннан әсәрнең композициясе яңача корылган, сюжет элементлары үзгәртелеп, әдәби алымнар белән баетылып үстерелгән.

Әсәрнең күрсәтелгән басмалары текстологик яктан 1929 елда чыккан текстка нисбәтле чагыштырылып эшләнде, тулыландырылды. Текстология фәненең бүгенге таләпләренә туры китереп, искәрмәләр язылды.

Авторның укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән һәм әдәби тәнкыйтьтә «татар әдәбиятында психологизм белән тасвирланган яңа тип роман» дип бәяләнгән «Яшь йөрәкләр» әсәре 1912 елда дөнья күрә. Шуннан соң ул, аерым өзекләре басылып чыгуын искә алмаганда, сигез томлы «Әсәрләр»нең 2 нче томына кертелә. Бу басмада текст яңадан чагыштырылды, комментарийлар тулыландырылды.

Унбиш томлы академик басманың 2 нче томы – үзенең фәнни эшләнеше, тулылыгы белән бөтенләй яңа басма. Язучының кульязмалары сакланмаганга, беренчел чыганаклар булып калган әсәрләрнең үзе исән чагында чыккан басмалары соңгыларындагы текстлар белән тулысынча чагыштырылып, текстологик яктан тикшерелеп, кыскартылган урыннары өстәлде. Томда искәрмә һәм аңлатмалар өлеше төзәтелде, өстәмә материаллар белән баетылды.

Шул рәвешле, бу томга авторның 1910–1929 еллар аралыгында язылган өч әдәби әсәре тәкъдим ителә. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең ике вариантын бер томда янәшә урнаштыру Г. Ибраһи-

мовның фикер үсешен, илдә хөкем сөргән яңа идеологиянең авторга тәэсирен һәм язучының иҗат лабораториясен ачыграк күзалларга ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен яңабаштан (ягъни икенче вариантын) эшли. Шул исемдәге әсәрнең сюжет элементлары, кайбер геройларның исемнәре, композициясе үзгәртелә.

Ике вариантта да вакыйгалар төп герой Гөлбану тирәсендә, аның язмышына бәйләп гәүдәләндерелә, сюжет шулай үстерелә, әмма композиция яңача корыла, сюжет сызыгы киңәйтелеп, яңа материаллар өстәлә. Автор һәр ике варантта да XX гасыр башында татар халкының төп яшәеше булган авыл тормыш-көнкүрешен, аның тарихын, менталитетын, сәяси-социаль ягын күрсәтеп, искиткеч оста каләм белән сәнгатьчә тасвирлый, татар милли гореф-гадәтләрен, этнографик байлыгын, социаль вакыйгаларны, татар хатын-кызларының авыр тормышын сурәтли. Әсәрдәге төп герой Гөлбануның шәхси язмышын, иҗтимагый тормыш чоңгыллары аша уздырып, күз алдына бастыра.

Нәтиҗәдә, автор, әдәби-эстетик гомумиләштерүләр нәтиҗәсендә, әсәрнең идеясен, социаль яңгырашын кардиналь рәвештә үзгәртә. Милләт язмышы проблемасын, татар халкының күркәм традицияләрен гомумкешелек фәлсәфәсе яссылыгында күтәрә.

Матбугатта чыкканына егерме еллап вакыт үткәч, Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» китабын яңадан эшләргә дигән карарга килә. Бу хакта аның хатыны Гөлсем Мөхәммәдова түбәндәгечә яза: «...үзенең әйтүе буенча, аның сәяси карашлары формалашуда, күп нәрсәгә күзе ачылуда роль уйнаган нәрсәләр – ...Февраль һәм Октябрь революцияләре. Шул вакыттагы көрәшнең эчендә кайнавы иде. Әлбәттә, бу фактлар аны үз иҗатын яңабаштан бәяләргә мәҗбүр иткәннәр. Бу – мәсьәләнең бер ягы булса, икенче ягы – еллар үткән саен, тәҗрибәсе арткан саен, язучының әдәби осталыгы үсә бара, ... чынбарлыкны киң, тирән, тулы, тормышчан, типик сурәттә күрсәтү ысулларын өйрәнә һәм язучы буларак үз-үзенә таләпләре дә арта бара. Шулар нәтиҗәсендә элек язылган кайбер әсәрләренең эчтәлеге аны канәгатьләндерми башлады. Тарихи хакыйкатьне социалистик реализм методы белән ачып бирергә дигән караште торып, бу әсәрләрне яңабаштан эшләп чыгарга кирәк тапты [Мөхәммәдова, б. 399].

Г. Ибраһимов үзе әсәрне кабат эшләвенең сәбәбен болай аңлата: «Әсәрнең төп каһарманы булган Гөлбануның авыр язмышы аркылы татар халкының революциягә кадәр тормышындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне тирән рәвештә ачып бирергә мөмкинлекләр бар. Бу мөмкинлекләр китапның беренче басмасында әрәм булып яталар. Биредәге Гөлбануның язмышы ул иске тормыш өчен типик түгел. Бу язмыш – гадәттән тыш бер вакыйга. Вакытында бу вакыйга Эстәрлетамакта булып үткән ... чын вакыйгага нигезләнеп язылган иде. Ул заманда бер яшь кызның, авыр тормыш законнарына каршы курыкмыйча көрәшкә чыгып, үз язмышын үз кулына ала белүе мине бик мавыктырган иде. Бу хәл ул вакыттагы иҗтимагый мөнәсәбәтләр

өчен табигый, типик бер вакыйгамы, юкмы – ул турыда уйланылмаган. Әмма язучы тормышны чынбарлыктагыча күрсәтергә теләсә, аның язган әсәрләрендәге вакыйгалар, персонажлар тормышның үзеннән мәҗбүри рәвештә туарга һәм тормышның иҗтимагый кануннарын ачып бирергә тиешләр. Ягъни бу вакыйгалар, бу персонажлар тасвирланган тормышның җимеше, үрнәге булырга тиешләр. Ә бу килеш Гөлбану патриархаль тормышның җимеше дә, үрнәге дә була алмый...» [Мөхәммәдова, б. 401–402].

Әсәрнең ике вариантында да язучы сәнгатьчә тасвир алымнарыннан гаять оста файдалана. Табигать күренешләрен тасвирлау аша кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтли, табигать белән кешенең рухи халәте арасында охшашлык, уртаклык таба һәм шуның җирлегендә аның эчке дөньясын тирән ача, кеше психологиясенең нечкәлекләрен, геройның эчке кичерешләрен оста тасвирлый.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестендә Г. Ибраһимов хатын-кыз азатлыгы проблемасының социаль һәм милли азатлык мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгәнлеген күрсәтә. Хатын-кыз заты тарыган бу авыр газаплардан бары тик иҗтимагый вазгыятьне үзгәртеп кенә котылырга мөмкин дигән фикер үткәрә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестенең романтик метод белән иҗат ителгән беренче вариантында кеше иреген буып торган җәмгыятькә каршы чыккан каһарман Гөлбануның, ягъни «шәхеснең югары күтәрелүе милләтнең, халыкның да югары күтәрелүен аңлата... Татар милләтенең уянып килүче милли үзаңын гәүдәләндерә» [Нигматуллина, с. 71]. Икенче вариант язучының кешеләр арасындагы социаль мөнәсәбәтләргә мөрәҗәгать итүе белән әһәмиятле. Бу аның яңалыгы да.

2 нче томга әдипнең 1913 елда дөнья күргән, роман жанрында беренче тәҗрибә булган «Яшь йөрәкләр» әсәре дә кертелде.

Роман Ибраһимовның үз иҗатында гына түгел, гомумән, татар әдәбиятында яңа бер этап булып тора. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина билгеләп үткәнчә, бу әсәр: «...ХХ йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характеры белән аерылып тора. Сюжет бирелеше белән дә ул ... үз чоры тормышын тергезә» [Заһидуллина, б. 8].

Бу әсәре белән Г. Ибраһимов татар әдәбиятында психологик роман жанрын башлап җибәрә. Әсәр романтик рухы, күтәрелгән проблемалары, автор үзәккә куеп сурәтләгән яңа тип геройлары белән укучыларда зур кызыксыну уята. Роман басылып таралу белән үк татар әдипләре, үз фикерләрен белдереп, вакытлы матбугатта күпсанлы рецензияләр язып чыгалар (Йолдыз, 1913, № 935; Аң, 1913, № 11; Вакыт, 1913, № 1141; Шура, 1913, № 10; Хокук вә хәят, 1913, № 3; Идел, 1913, № 530). Бу мәкаләләр 2 нче томга «Кушымта»да бирелде [Ибраһимов, 2018. т. 2, б. 515–546]. «Яшь йөрәкләр» романында татар милләте язмышы, аның киләчәге мәсьәләләре күтәрелгән. Әсәрнең үзәгендә милләтнең азатлыкка омтылу идеясе ята. Катлаулы иҗтима-

гый шартларда җәмгыятьтә яңа тип шәхесләр барлыкка килүе сурәтләнә. Бәяләмәләр төрле эчтәлектә булса да, фикер бер – Г. Ибраһимов татар әдәбиятында яңа тип роман тәкъдим итә [Алиева, б. 64–67].

3 нче томда әдипнең «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар», «Адәмнәр», «Тирән тамырлар» әсәрләре һәм «Яңа кешеләр» драмасы урын алды. Алар хронологик тәртиптә урнаштырылды. «Алмачуар» һәм «Адәмнәр» хикәяләренең текстлары язучы үзе исән чакта дөнья күргән иң соңгы басма вариант нөсхәләреннән алынды. «Кызыл чәчәкләр» һәм «Тирән тамырлар» әсәрләренең текстлары тулырак булганга, алданрак чыккан басмалар нигез булды.

«Кызыл чәчәкләр» хикәясенең 1936 елда басылган варианты (сигезтомлыкта шушы басма) шактый өзекләр кыскартылу сәбәпле, унбиштомлыкка текст 1931 елгы басмадан алынды. Язучы иҗатын тирәнтен өйрәнгән галим, академик М. Хәсәновның «Ибраһимов әсәрләренең икенче томы» исемле мәкаләсендә дә шул фикерне әйтә: «...бу томга әсәрләр сайлаган вакытта иң соң басмаларны күздә тотмыйча, аларны элегрәк чыккан басмалары белән дә чагыштырып карарга кирәк иде. Чөнки Галимҗан Ибраһимовның бер үк әсәренең дә төрле басмалары еш кына бер-берсеннән аерыла. Андый очракта әсәрләрнең тулырагын, идея-эстетик һәм художество эшләнеше ягыннан матуррагын сайлап алырга мөмкин булыр иде. Мәсәлән, безнең карашыбызча, «Кызыл чәчәкләр» хикәясе 1936 елгы басмадан түгел, бәлки 1931 елда чыкканыннан алынган булса, уңышлырак булыр иде. Чөнки 1936 елны чыккан китапта хикәянең 16, 17, 19 бүлекләре үзгәртелеп, шактый кыркылып бирелгән. Бу кыскартулар хәтта мәгънә үзгәрешенә дә китергән» [Совет Татарстаны, 1957].

3 нче томның зур яңалыгы шунда: биредә укучыга элеккеге басмаларның берсенә дә кертелмәгән «Адәмнәр» повесте тәкъдим ителә. Әлеге әсәрнең 1923 һәм 1931 елларда чыккан басма вариантлары билгеле. 1931 елгы басманы Г. Ибраһимов, әсәрнең ахыргы өлешен редакцияләп, яңача яза. Томга текст 1931 елгы басмадан алынса да, биредә укучы 1923 елгы басманың үзгәртелгән өлеше белән дә таныша ала. «Тирән тамырлар» хикәясе автор үзе исән чакта дүрт тапкыр басыла. Томга текст 1933 елгы басмадан алынды, чөнки, башкалары белән чагыштырганда (шул исәптән 1935 елгы басма белән дә), бу вариант иң тулы һәм камиле дип табылды. Башка басмаларга кертелмәгән, бары беренче басмада гына булган өзекләр искәрмә һәм аңлатмалар өлешендә бирелде.

«Яңа кешеләр» драмасының тексты 1931 елгы басмадан алынды. Әсәрнең беренче 1921 елгы басмасы белән чагыштырганда, Г. Ибраһимовның драманы яңадан редакцияләве күренә – күп урыннар төшереп калдырылган. Әлеге үзгәрешләр томның искәрмә һәм аңлатмалар бүлегендә урын алды. «Яңа кешеләр», «Кызыл чәчәкләр» һәм «Адәмнәр» әсәрләрендәге тарихи чынбарлык мәсьәләләренә кагылышлы фикерләр Г.Н. Зәйниева һәм Г.А. Хөснетдинова мәкаләсендә аерым әйтелә [Зайнеева, Хуснутдинова, 2018, с. 30–32].

Әдип иҗаты җәмәгатьчелектә һәрвакыт кызыксыну уяткан. Язучының әсәрләре басылганнан соң, шул чор матбугатында аларга карата үз фикерен белдергән мәкалә-бәяләмәләр пәйда була. «Эшче», «Вакыт», «Кызыл Татарстан», «Безнең юл», «Вестник научного общества Татароведения», «Художественная литература» кебек газета-журнал битләрендә дөнья күргән әлеге мәкаләләр аерым тупланып, «Кушымта» өлешендә тәкъдим ителде [Ибраһимов, 2018, т. 3, б. 462–502]. Бәяләмәләр арасында Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, З. Нуркин, Ш. Госманов, Г. Толымбайский, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Ходаяров һ. б. кебек билгеле әдәбиятчы-галимнәрнең язмалары да, имзасыз, төрле псевдоним-тәхәллүс астында язылганнары да бар.

Г. Ибраһимовның бу басмасының 4 нче һәм 5 нче томнарында әдипнең «Безнең көннәр» исемле күләмле романының ике варианты бирелә.

4 нче томда «Безнең көннәр» романының беренче басмасы [Ибраһимов, т. 4, 2018]. Ул революция дулкыннарының тарихи көчен күрсәтә торган киң колачлы әсәрләрдән санала. Сурәтләнгән вакыйгаларының киңлеге, хәрәкәтләренең кискенлеге, көрәш дулкыннарының куәтен ачыклавы, геройларының катлаулы язмышларда бирелүе белән роман XX гасыр башы татар милли иҗтимагый тормышын күз алдына ачык китереп бастыра. Игътибар үзәгендә – 1905 елгы революция йогынтысында татар мәдрәсәләренә, аеруча мәдрәсәи исламиягә үтеп кергән фикерләр яңарышы, шуның нәтиҗәсе буларак шәкертләр кузгалышы.

1912 елның көзендә Г. Ибраһимов Киевка китә һәм укытучылык белән шөгыльләнә, шул ук вакытта ирекле тыңлаучы сыйфатында университетта укып йөри. Яшь революционерлар белән аралашып, андагы мөселман студентларының яшерен сәяси оешмалары эшендә актив катнаша. Киев вакыйгалары әсәрдә татар җирлегенә бәйле сурәтләнә.

Мәдрәсә тормышы белән Г. Ибраһимов бала чагыннан ук таныш. Әүвәлдә ул кадимче Вәли мулла мәдрәсәсендә, аннары җәдитчелек үзәкләреннән «Галия»дә укуы, укыту программаларының һәм белем бирү системасының камил булмавына төшенүе, мәдрәсәне ташлап чыгуы әсәргә үз эзен сала.

«Безнең көннәр»нең беренче варианты татар милләтенең иҗтимагый-сәяси аңы уянуны, яшьләрнең мәктәп-мәдрәсәләрдә яңа фәннәр укытуны таләп итүен, җәдит мәдрәсәләр оешуны, яңарыш хәрәкәтенең төрле катлам кешеләрен үзенә иярткүен тасвирлый. Ул революциягә кадәрге татар дөньясын колачлавы һәм аны тормышчан итеп тасвирлавы белән зур игътибарга лаек.

«Безнең көннәр»нең беренче варианты моңа кадәр гамәлдәге татар графикасында тулысы белән һичкайчан басылмаган иде. Ул монда татар укучысына шушы рәвешендә беренче тапкыр тәкъдим ителә. Томның төп яңалыгы да әнә шунда.

* * *

Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романын ярты ел эчендә, 1914 елда яза башлап, шул ук елның июнь урталарында тәмамлаган, әсәрне, бастыру өчен, «Гасыр» нәшриятына тапшырган булып чыга. Нәшрият шул ук елның сентябрендә бастыруга керешсә дә, революцион хәрәкәтләргә багышлануы сәбәпле, типографиядә сиксән бите җыелып, ике табагы басылып та, алга таба бу эш патша цензурасы тарафыннан туктатыла. Шушы сәбәпле, «Безнең көннәр» романы бары тик 1919 елда гына дөнья күрә [Ибраһимов, 1919].

«Безнең көннәр» укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителә. Әсәрнең дөньяга чыгуы әдәбиятыбыз тарихында зур вакыйга буларак кабул ителә. Татар һәм рус телләрендә тәнкыйть мәкаләләре языла, Ф. Сәйфи-Казанлы, С. Атнагулов, П. Фалев бу әсәр турында уңай фикерләрен дә белдерәләр. Г. Нигъмәти әсәрнең идея-тематик эчтәлеген, образларын, андагы вакыйгаларны һәм сәнгати үзенчәлекләрен төрле яклап тикшерә, аңа югары бәя бирә [Ибраһимов, т. 4, 2018, б. 364–375]. Әмма тиздән Г. Ибраһимов үзе бу романын «әдәби балачак җимеше» буларак бәяли.

5 нче томда язучының «Безнең көннәр» исемле күләмле романының икенче варианты (1934) урнаштырылды. Автор бу әсәрнең беренче вариантын 1914 елда язып тәмамлый һәм ул 1919–1920 елларда басылып чыга. Романның шушы 5 нче томга кергән икенче вариантын исә ул 1930 елларда яңабаштан эшли. Язучы бу әсәрен трилогия рәвешендә язарга планлаштырган була. Ләкин 1934 елда трилогиянең биредә тәкъдим ителгән, үзгәртелеп язылган 1 нче томы гына дөнья күрә.

Бу вакытта илдә пролетар революция булган һәм яңарыш җилләре революцион көрәшнең үзәгендә кайнаган Г. Ибраһимовның күп нәрсәләргә карашын үзгәрткән. Шуңа да автор «Безнең көннәр»нең композициясен, әдәби-сәнгатьчә эшләнешен яңабаштан, үзгәртеп яза. Автор үзе әйткәнчә, бу вариант идея-эчтәлеге белән дә аерылып тора. Яшерен архив материалларын файдаланып, жандармнарны, охранка агентларын, пантюркизм, панисламизм кебек сәяси агымнарга ияргән типларны тагын да кискенрәк рәвештә тасвирлый. Нәтиҗәдә «Безнең көннәр» татар әдәбиятында беренче тарихи революцион роман буларак таныла.

Бу китапның яңабаштан эшләнергә тиешлеген Г. Ибраһимов болай аңлата: «Марксизм-ленинизм тәгълиматы иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны башкача аңларга өйрәтте. Икенче яктан, татарлар арасында инкыйлаб хәрәкәтләре тарихы өстендә эшләвем күп нәрсәгә яңача бәя бирергә, яңа күз белән карарга мәҗбүр итә. Дөньядагы катлаулы, тирән кузгалышлар, каршылыклар, аяусыз көрәшләр үзлегеннән килеп чыкмыйлар. Беренче редакциядә мәсьәләнең бу ягы тиешенчә күрсәтелмәгән» [Ибраһимов..., 2007, б. 407].

«Безнең көннәр» романының әлеге томга урнаштырылган текстына нигез итеп 1936 елда автор үзе карап, беркадәр төзәтүләр кертеп чыгарылган басма алынды. Текст 1934 елда дөнья күргән һәм

сигезтомлыкның 4 нче томында (1976) чыккан басмалар белән дә чагыштырылды. Соңгы басмада кыскартылган урыннар өстәлеп тулыландырылды, аерым сүзләр, җөмләләр, өзекләр текстка кире кайтарылды. Нindидер сәбәпләр белән төшереп калдырылган ике бүлек («Ораторлар» һәм «Без ник бетәбез?») яңадан торгызылды.

Сыйнфыйлык идеологиясенә туры китереп язылган элекке шәрех-комментарийлар кабат эшләнде. Искәрмәләрнең саны шактый артты, алар XX гасыр башы татар халкы иҗтимагый тормышында булган тарихи вакыйгаларга таянып башкарылды.

Романның икенче варианты басылып чыккач, нинди сәбәпләр аркасындадыр, аның турында матбугат битләрендә рецензияләр тиз генә күренми. Әмма соңыннан, беркадәр еллар узгач, әдәбият белгечләре бу әсәрне аерым алып та, шулай ук әдипнең әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйләп тә бик күп тикшерделәр, өйрәнделәр, аның идея эчтәлегенә һәм сәнгатьчә эшләнешенә югары бәя бирделәр. Г. Ибраһимовның әдәби-иҗтимагый һәм гыйльми эшчәнлеген аеруча җентекләп өйрәнгән академик М. Хәсәнов бу әдәби җәүһәр турында: «Безнең көннәр» татар әдәбиятында беренче тарихи революцион роман булды, – дип яза [Хәсәнов, 1964, б. 292].

* * *

Текстларны эшләгәндә түбәндәге төп принциплар кулланылды:

1. Гарәп графикасына нигезләнгән иске татар язуы традициясе буларак әдипнең әсәрләрендә даими очрый торган *барыб*, *башлаб*, *диб* кебек язылыштагы хәл фигыль төрләре һәм шулай ук *каб*, *саб*, *таб*, *куб, аб-ак, саб-сары, таб-таза, туб-тулы...* кебек сүзләр хәзерге язылыштагыча *барып, башлап, дип, кап, сап, тап, күп, ап-ак, сап-сары, тап-таза, туп-тулы...* рәвешендә бирелделәр.

2. Әдипнең һәм гомумән шул заманның язма телендә сирәк кенә очрый торган *улуб-булуб, дәйүб, кәлүб-килүб...* кебек иске татар язма әдәби теленнән калган формалар да, аерым очракларны санамаганда, хәзерге язылышта алындылар.

3. Хәзерге әдәби телдә ныклап үзләшкән, ягъни татар теленең үз сүзләреннән аерылгысыз диярлек булган алынмалар *(китап, мәктәп, әдип, җавап, сәбәп, хисап, таләп* һ. б.) шулай ук хәзерге орфографик норма буенча бирелде (гәрчә әдипнең үз текстында; *китаб, мәктәб, әдиб, җәваб...* булса да).

4. Хәзерге әдәби телдә үзләшеп (халыклашып) җитмәгән, бары тик югары китаби яки махсус-фәнни стильгә генә хас булган *мәктүб, җәнүб, газеб, гареб, гаҗиб, калеб, мөхиб, сахиб, инкыйлаб...* кебек сүзләр автор текстындагыча үзгәртелмичә алынды.

5. Сүзләрнең язылыш нормаларын, формаларын (мәсәлән; б//п, д//т һ. б.) билгеләгәндә, халык телендә ни дәрәҗәдә үзләшү (яки язма китап телендә генә калу, югары стильдә генә куллану) ягын искә алу белән бергә, бер-берсенә бик охшаш (яки якынча охшаш) сүзләрнең мәгънә аермасына – семантик дифференциацияләнүенә дә игъти-

бар ителде. Мәсәлән; *гариб* (читтә каңгырып йөрүче) ↔ *гарип*, физик кимчелеге булган кеше; *гаиб* (читтәге, ерактагы, әллә кайдагы) ↔ *гаеп* (гъәйеп) «хата, гөнаһ» һ. б. ш. *Гареб* (Көнбатыш) һәм *гарәп* (халык, тел) сүзләренең язылышын ныграк аерымлау да шул гомуми таләпкә җавап бирүне күздә тота.

6. Хәзерге әдәби телдә (сөйләм һәм язуда) нык үзләшкән, киң халыклашкан *азат, тәнкыйть иҗат, шәкерт, гадәт, максат, дәрт* кебек сүзләр хәзерге норма буенча бирелде (ягъни; *азад, иҗад...* түгел).

7. Нык үзләшмәгән китаби сүзләр, мәсәлән: *икътисад, мәкъсуд (максуд), касд, гаид, җилд, игътикад, вөҗүд* һ. б. ш. авторда язылганча калдырылды *(икътисат, максут...* дип үзгәртелмәде).

8. Саңгырау тартыклардан соң, элекке имля буенча, *халыкга, торакга* (юнәлеш к.), *кайтган, убган* (үткән заман), *кайтгач, убгач* (үткән заман хәл фигыль) һ. б. ш. кебек язылган сүз формалары хәзерге орфография буенча *халыкка, торакка, кайткан, упкан, кайткач, упкач* рәвешенчә бирелде[1].

9. Саңгырау тартыклардан соң, элекке имля буенча, *башда, гадәтдә, рәвешдә* (урын-вакыт килеше); *йортдан, тумышдан, читдән* (чыгыш килеш), *кайтды, әйтде, китде* һ. б. ш. кебек формалар хәзерге орфография буенча *башта, гадәттә, рәвештә; йорттан, тумыштан, читтән; кайтты, китте, әйтте...* дип бирелде.

10. Шул ук аналогия буенча (пункт 9): *хезмәтдәш, кәсебдәш, ибдәш* кебек сүзләр дә хәзерге нормага буйсындырылды: *хезмәттәш, кәсептәш, иптәш* һ. б.

11. Әдипнең әүвәлге язмаларында *артдыра, йөрешдерә, карашдыра, килешдерә...* дип язылган фигыль формалары (йөкләтү юнәлеше, сирәклек дәрәҗәсе), 8, 9, 10 пунктлардагы аналогия буенча, *арттыра, йөрештерә, караштыра, килештерә...* рәвешендә алынды.

12. Әдипнең әүвәлге текстларында 1930 елларга кадәр даими очрый торган *урмандан, ягындан, җәһәтендән, шивәләрендән, кемдән, андан, синдән* (-н+дан/-н+дән) кебек формалар, хәзерге орфографиягә буйсындырылды.

13. Әүвәлге әдәби телгә гомумән, Г. Ибраһимов имлясына хосусан хас булган *дөрест(лек), дуст(лык), аст, өст* кебек сүзләр автор текстындагыча бирелде, ягъни *дөрес(лек), дус(лык), ас, өс* дип үзгәртелмәде.

* * *

Г. Ибраһимов әсәрләренең басылып чыккан биш томын төзегәндә түбәндәге моментлар нигез итеп алынды:

1. Әсәрләр хронологик тәртип буенча урнаштырылды (бу принцип авторның иҗат эволюциясен, карашларын, чор белән бәйләнышын күзәтү өчен дә уңайлы).

[1] Югыйсә, мондый сүзләрне автор текстындагы имля белән калдырганда, аларны контекстта уку-әйтү гаять кыенлаша.

2. Әсәрләрнең ике варианты булганда, алар икесе дә тупланмага кертелде (мәсәлән, «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең 1910 һәм 1929, «Безнең көннәр» романының 1920 һәм 1934 елгы вариантлары тулысынча бирелде). Сюжет үзгәрешләре, проблемага автор позициясе, карашлары үзгәрү, аерым очракларда төп геройларның исемнәре алмаштырылу, шуңа бәйле рәвештә әсәрнең күләме үзгәрү, яңа бүлекләр өстәлү әсәрләрнең вариантлылыгы турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Автор иҗат иткән бер үк әсәрнең ике вариантын янәшә бирү Г. Ибраһимов текстологиясендә беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

3. Сигезтомлыгы күрсәтелгән квадрат җәяләр [...] белән текстологик кыскартулар торгызылды.

4. Хәзерге рус-европа текстология фәнендә кабул ителгән нормаларга туры китереп, авторның барлык әсәрләре тупланып бирелде, алар фәнни-объектив комментарийлар белән дә тәэмин ителде.

5. Текстта очраган гарәп-фарсы алынмаларына бит асты аңлатмалары (глоссалар) бирелде. Әсәрнең кайчан язылуы, кайда, кайчан, нинди имза белән нәшер ителүе, кабат басмалары турындагы искәрмә мәгълүматлар, текстларның эчтәлегенә, мотивларына, тарихи реалийларга, шәхесләргә караган шәрех-комментарийлар язылды.

Унбиштомлыкның бер үзенчәлеге: томнарга «Кушымта» рәвешендә Г. Ибраһимовның басылып чыккан әсәрләренә карата шул чорда дөнья күргән тәнкыйть мәкаләләре, бәяләмәләр туплап урнаштырылды. Бу мәкаләләр, бер яктан, шул заман әдәби тәнкыйтенең торышын күз алдына китерү өчен әһәмиятле булса, икенчедән, татар әдәбиятының үсешен, яңа жанрлар белән баюын һәм Г. Ибраһимовның әдәби стиленә кагылышлы фикерләрне күзәтү ягыннан да бик кызыклы.

XX йөз башында гарәп графикасында басылган газета-журналларның бүгенге көндә инде шактый таушалган булуларын да, һәркемнең бу язуны уку мөмкинлеге булмауны да истә тотып, әлеге материалларны бүгенге көн укучысына җиткерү җәһәтеннән томнарның әһәмиятләре бермә-бер арта.

**Әдәбият**

*Алиева Ә.Х.* Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы турында замандашлары // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья. Казан, 2012. Б. 64–69.

Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 544 б.

*Зайнеева Г.Н., Хуснутдинова Г.А.* Исторические реалии в произведениях Г. Ибрагимова (на примере произведений «Новые люди», «Красные цветы», «Люди») // Казанская наука. 2018. № 10. С. 30–32.

*Заһидуллина Д.* Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе // Мәгариф. 2012. № 2. Б. 6–9.

*Ибраһимов Г.* Безнең көннәр: роман. Казан: «Өмид» ширкәте матбагасы, 1919. 454 б.

*Ибраһимов Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1933. 1 китап; Казан: Татгосиздат, 1934. 2 китап; Казан: Татгосиздат, 1934. 3 һәм 4 китап; Казан: Татгосиздат, 1934. 5 китап.

*Ибраһимов Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1936.

*Ибраһимов Г.* Сайланма әсәрләр. Өч томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956–1957.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 1 / томны төзүче Г.К. Камалиев; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны Р.Р. Гайнанов хәзерләде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 2 / томны төзүчеләр: А.Ш. Шамов, Х.Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр: А.Ш. Шамов, Р.Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 3 / томны төзүчеләр: А.Ш. Шамов, Х.Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр: А.Ш. Шамов, Р.Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 4 / томны төзүче, искәрмә һәм аңлатмаларны язучы А.Ш. Шамов; текстларны хәзерләүчеләр: А.Ш. Шамов, Р.Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 5 / томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр: М.Х. Хәсәнов, Р.Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 6 / томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүче Р.Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 7 / томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүче С.Х. Алишев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 8 / томның материалларын туплаучы Лена Гайнанова; төзүчеләр, текстларны хәзерләүчеләр: Фазыл Фәсиев, Лена Гайнанова; искәрмә һәм аңлатмаларның авторы Фазыл Фәсиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Т. 9 / җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны хәзерләүче Ф.И. Ибраһимова. Казан: Фикер, 2000.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 1. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 462 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 2. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 547 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 3. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 503 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 4. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 376 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 5. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 423 б.

*Мөхәммәдова Г.* Зур тормыш // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлекләр-хатирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 346–412.

*Нигматуллина Ю.* Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970.

*Хәсәнов М.* Г. Ибраһимов әсәрләренең икенче томы // Совет Татарстаны. 1957. 18 гыйнвар.

*Хәсәнов М.* Галимҗан Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.

***Алиева Әнисә Хәниф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***А.А. Хасавнех***

# ӘБЕЛМӘНИХ КАРГАЛЫЙ ХИКӘЯЛӘВЕНДӘ ФУДАЙЛ ИБНЕ ИЙӘД ТАРИХЫ

В статье приводится сопоставительный анализ суфийского по содержанию рассказа А. Каргалый «О мюриде шейха Зу-Нуна ал-Мисри» с различными вариантами легенды о Фудайле ибн Ийаде. Повествование выделяется яркой авторской интерпретацией. Основное внимание в произведении акцентируется на этике послушания и подчинения мурида своему шейху. Большое значение в поэтическом рассказе А. Каргалый имеет концовка, в которой автор обращается к читателю с нравственно-этическими назиданиями.

**Ключевые слова и фразы:** суфизм, рассказы нравственно-этического содержания, авторская интерпретация, адаб, мотив покаяния, мотив послушания.

The article provides a comparative analysis of the Sufi story by A. Kargaliy «About Sheikh Zu-Nun al-Misri's murid» with various versions of the legend about Fudail ibn Iyad. The story is characterized by author's bright interpretation. The work is focused on the ethics of obedience and the subordination of the murid to the sheikh. The ending of A. Kargaly's poetic story is of great importance where the author addresses the reader with moral and ethical edification.

**Keywords:** Sufism, stories of moral and ethical content, author's interpretation, adab, motive of repentance, motive of obedience.

XIX йөз ахыры – XX йөз башында укымышлы татарлар арасында әхлакый-этик эчтәлектәге төрле дидактик хикәяләр киң тарала. Күләме белән артык зур булмаган мондый әсәрләрне халык аеруча яратып укый. Аларны кулъязма җыентыклар рәвешендә төпләп, кулдан кулга йөрткәннәр, үгет-нәсыйхәт бирү максаты белән балаларга укыганнар, мәдрәсәләрнең уку программаларына кертеп, шәкертләргә белем бирүдә һ.б. максатларда кулланганнар. Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендәге Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә мондый хикәяләр теркәлгән кулъязма җыентыкларның күпсанлы нөсхәләре саклану аларның кайчандыр чыннан да популярлык казанулары хакында сөйли.

XVIII йөз – XIX йөз башына караган мондый кулъязмаларда изгеләр (*әүлиялар*), суфи остазлар (*шуйух*) тормышы турында төрледән-төрле тарихларга, дини-мөселман риваятьләренә тап булабыз. Татарлар бигрәк тә пәйгамбәрләр турындагы хикәяләрне үз иткәннәр, шуңа да Нух, Давыд, Сөләйман, Гайсә, Мөхәммәд (с. г. в) пәйгамбәрләр, Зу Нун әл-Мисри, Раби‘а әл-‘Әдавийа, Хәсән әл-Басри, ‘Абд әл-Кадир әл-Гиляни, Әбү Йәзид әл-Бистами, Ибраһим

ибне Әдһәм кебек борынгы суфилар турында хикәяләр аеруча киң таралган була.

Әбелмәних Каргалыйның (1782–1833 тән соң) «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» [Каргалый, б. 3] җыентыгына кертелгән «Бишенче хикәя»се (Хикәйәт әл-хамис) дә – шушындый әхлакый-этик эчтәлекле тарихлар рәтенә керә торган истәлекләрнең берсе. Бу китап Җәләлетдин Руминың «Тәфсир-е кәбир» («Зур тәфсир»), «Мәснәви» һәм имам әл-Газалинең «Мишкател-әнвәр» («Источник лучей») әсәрләреннән алынган ун хикәянең шигъри тәрҗемәләрен үз эченә ала. Аларның барысында да мөселман изгеләренең тормышы тасвирлана. Китапта, шартлы рәвештә «Шәех Зу-Нуна әл-Мисриның мөриде» дип исемләргә мөмкин булган «Дүртенче хикәя»дә (Хикәйәт әр-раби‘) билгеләп үтелгәнчә, шәкертнең (*мөрид*) рухи остазына (*шәйх*) карата күндәмлеге, буйсынучанлыгы темасы яктыртыла. Шагыйрьнең моннан алдагы хикәясендә әлеге мотив хикәяләү ахырында ачыла, автор мәшһүр изгеләр яисә рухи остазлар турында суфичыл характерда нәсыйхәт бирә торган теге яки бу легенданы сөйләгәннән соң, шундый нәтиҗә чыгара. Әлеге хикәядә мөрид һәм шәех мөнәсәбәтләре, беренчесенең икенчесенә берсүзсез буйсынырга тиешлеге ассызыклана.

Ә. Каргалый хикәяләвендә бирелгән ядкярләрнең үзәгендә – мөселман дөньясында билгеле суфи Фудайл ибне Ийәд (тулы исеме: Әбү ‘Али әл-Фудайл ибне Ийәд ибне Мәсгуд ибне Бишр әт-Тамими, үлгән елы мәгълүм: 802/3 ел).

Фудайл ибне Ийәд – суфилар хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе. Билгеле булганча, яшь чагында ул Абивард һәм Сарахс шәһәрләре арасында юлбасарлык итү белән шөгыльләнә. Бервакыт ул, үз гамәлләренең гөнаһлы булуын аңлап, тәүбәгә килә, туры юлга баса. Бүгенге көндә бу кеше хакында төрле легендалар бар. Аларның эчтәлеге һәм чыганаклары Фудайл ибне Ийәднең тәүбә итү тарихын ача (чыганаклар Е.Э. Бертельсның «Суфичылык һәм суфичыл әдәбият» исемле китабында [Бертельс, с. 188–214] бирелгән). Галим Е.Э. Бертельс фикеренчә, Фудайл ибне Ийад хакындагы легендалар һиҗри белән якынча IV гасырда, Ибраһим ибне Әдһәм турындагылары туган мохиттә – хорасан суфилары арасында, барлыкка килгән. «Әмма, – дип дәвам итә үзенең фикерен галим, – Фудайл тарихының дөреслеккә ни дәрәҗәдә туры килүенең тарихи нигезләре бар» [Бертельс, с. 193]. Моннан тыш Е.Э. Бертельс, әлеге легенданың төрле вариантларын анализлап, Фудайлның «әверелү» тарихы үтә дә тәэсирле һәм нәкъ менә шуңа күрә ул әдәби әсәр булып киткән, дигән нәтиҗәгә килә [Бертельс, с. 193].

Фудайл тарихының ике төп варианты бар. Беренчесен түбәндәгечә характерларга мөмкин: бервакыт төнлә белән Фудайл ике кәрванчының үзара сөйләшкәнен тыңлап тора. Берсе әйтә: «Әйдә, борылыйк, алга таба барсак, юлбасар Фудайлга юлыгып, ул безне талар», – ди. Үзе турындагы бу сүзләр Фудайлга нык тәэсир

итә, ул үзгәрергә карар кыла һәм юлчыларга башка бу начар эш белән шөгыльләнмәячәген әйтә. Тәүбәгә килгәннән соң, Фудайл хак юлга баса.

Икенче вариант эчтәлеге белән беренчесенә охшаш, әмма анда бу тарихтан алдарак булган хәлләр турында да сөйләнә. Фудайл, төнлә белән ике юлчының сөйләшүен тыңлап торудан элек бер кызга гашыйк булган һәм аңа талап алган малыннан бүләкләр алып килә икән. Бервакыт, гыйшкы төшкән шушы кыз янына киртә аша гына кереп барганда, ул кемнеңдер кычкырып Коръән укыганын ишетә: «Аллаһыга инанган йөрәкләрегезгә Аллаһыны аңлап тынычланырга вакыт җитмәдеме әллә?» (57:15). Шуннан соң Фудайл хак юлга баса.

Бу борынгы легенданың әле тагын бик күп вариантлары бар, әмма алар Россия галимнәре хезмәтләрендә җентекләп тикшерелгән [Бертельс, с. 4].

Ә. Каргалыйның «Шәех Зу-Нуна әл-Мисри мөриде хакында» дигән әсәрендә күп балалы, балаларын ашату хәленнән килми торган, гаҗизлектән үзенең рухи остазы суфи Зу-Нуна әл-Мисри янына килгән бер мөрид турында сүз бара. Тегесе, ачуланып, моңа юлбасарлык итәргә боера. *«Бу харами, и мөриднең азгыны! / Ултырыб Дәрбәнд үзә раһи күзәт, Куб кашымдан тиз заман, ултырма кит!» (Бул харам, и мөриднең азгыны! / Тау куышына качып утырып, юлны күзәт, тиз кит каршымнан, күздән югал!*) [Каргалый, б. 26]. Мөрид, бөтен нәрсәсен сатып бетерә дә, тапкан акчасына ук һәм җәя сатып ала, шуннан «зур юлга» чыгып китә. Аңа күп еллар башкисәрлек белән шөгыльләнеп, шул рәвешле ашарына-яшәренә мал табып көн итүче башка юлбасарлар очрый, бу да шуларга кушыла. Нәкъ шул вакытта аларның каршысына сәүдәгәрләр килә икән, көтеп торган арада юлбасарлар яңа килеп кушылган мөридкә: «Менә синең нәрсәгә яраганлыгыңны сынар вакыт җитте», – диләр. Тиз арада сәүдәгәрләрне тотып алалар һәм бәйләп куялар. Юлбасарлар өере башлыгы яшь башкисәрнең кулына үткен кылыч тоттыра һәм сәүдәгәрләрнең берсен үтерергә боера: *«Берен үлтер сән дәхи, вирмә әман. / Бу һөнәрдә күрәен мигъйарыңый, Һәм әлеңдә нәчә кувәт варыный» (Кызганып тормый гына берсен үтер! / Бу һөнәрдә булдыклылыгыңны, кулыңнан нәрсә килгәнне күрсәт).* [Каргалый, б. 27]. Мөрид югалып кала, нишләргә дә белми. Уйлары белән ул үзенең рухи остазына ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Шулвакыт ул остазының түбәндәге сүзләрен ишетә: *«Ку аны, залим башыны кыл җода. / Вирмә мөһләт, кәс ләгыйньнең башыны, Куртар ул таҗир улан кардәшеңе!» (Калдыр аны, ә залимның башын өз, тукталып торма, кис ләгыйньнең башын, кардәшеңне коткар)* [Каргалый, б. 28]. Шуннан соң мөрид бер кизәнүдә өер җитәкчесенең башын кисеп төшерә, аннары тиз генә үтерелергә тиеш сәүдәгәрнең бәйләнгән кулларын ычкындыра, шуннан болар икесе бергә Аллаһыдан кычкырып-кычкырып ярдәм сорыйлар. Калган башкисәрләр бу вакытта читтәрәк сәүдәгәрләр төркемен тоткарлап тору белән мәшгуль икән, кычкырып Аллаһыга мөрәҗәгать иткән тавышка йөгереп

килсәләр, башлыкларының канга баткан үле гәүдәсен һәм арысланга тиң, коралланган куәтле ике ирне күреп, бик нык куркып калалар. *«Кылдылар зан: «Дотмак өчен бонлары, Кәлмеш улаку гаунән гаскәр ары». (Шиккә калдылар: боларга гаскәр килеп булышкандыр)* [Каргалый, б. 28]. Шуннан соң башкисәрләр качып китә. Сәүдәгәрләр исә, үзләрен коткаручы мөрид белән бергә, Аллаһыга рәхмәт әйтеп, гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: «Син Хозыр пәйгамбәр түгелме, әй, безнең коткаручыбыз? Безне юлбасарлардан араладың!» Мөрид боларга барын да сөйләп бирә. Сәүдәгәрләр, бичара мөриднең башыннан узган вакыйгаларны тыңлагач, аңа тагын да зуррак ихтирам һәм рәхмәт белән баш ияләр. Үз мөлкәтләрендәге иң затлы һәм кыйммәтле әйберләрне җыеп, мөридкә бирәләр, аннан кулын үбеп, үз юлларына китәләр, гомерләренең ахырынача коткаручылары өчен дога кылып яшиләр. Хикәяләү шушындый бәхетле нотада тәмам була.

Шигъри хикәяләүнең бетем өлешендә төрки әдәбиятларда барлыкка килгән традиция буенча, укучыга әхлакый-этик үгет-нәсыйхәт бирелә, уйланырга, сөйләгәннәрдән сабак (*гыйбрәт*) алырга чакырыла. Шагыйрь болай дип нәтиҗә чыгара: суфи остазның ихтыяры беренче катка никадәр әхлаксыз һәм дуамал тоелмасын, мөрид аңа буйсынырга һәм берсүзсез ул әйткәнне үтәргә тиеш, болай эшләүнең ахыры хәерле булачак.

Мәсьәләгә мондый юнәлеш бирү мөселманнарның Изге китабыннан ук килә. Бәндә үзенә нәрсә хәерле, нәрсә начар икәнен алдан белә алмый, дигән аңлатма Коръәндә бар. «Сезгә көрәшү язган, гәрчә бу сезнең өчен рәхәт әйбер булмаса да. Бәлки сезнең өчен хәерле булган әйбер сезгә начар булып күренер. Бәлки сез үзегез өчен хәерсез булган нәрсәне бик ярата торгансыздыр. Аллаһы белүче, ә сез белмисез» (2: 216).

Ә. Каргалый үз әсәрендә суфичыл доктринада әһәмияте зур булган мәсьәләне күтәрә. Мөриднең тышкы һәм эчке (яшерен) *әдәбенең* төп кагыйдәләреннән берсе – сырхауның табибны карусыз тыңлавы мисалында, шәехенең бөтен тыю-боеруларына ихлас тугрылыгы һәм аңа тулысынча буйсынуы. Хәдисләр һәм хокук белгече, мәгълүм мөселман Мөхәммәд ибне Хәмид Тәмризи (824–892) әйткән: «Шәехләр боерганга һәм алар тәрбиясенә канәгатьсезлек иткән кешене Коръән һәм Сөннәт кагыйдәләре тәрбияли алмас» [Адабы мюрида]. Әсәренең соңгы ике юлында Ә. Каргалый, бу фикерне тагын да ассызыклап, болай ди: *«Зи сәгадәт шәйхең әмриләә модам, Әйләйәнләр би тәхәллеф собх-у-шам. / Уламы хосран дәхи бондин зийад, Әмре шәйхә кылмайана инкыйад!»* Ягъни: бәхетле шул кеше, кем үзенең шәехенең әмерләрен көне-төне үти / Үз остазына тугрылык күрсәтмәгән кешене нинди зур үкенеч көтә [Каргалый, б. 29].

Шәкертнең үз шәехенә буйсынучанлыгын суфилар арасындагы мәхәббәт белән бәйләү дә бар: мөриднең остазын яратуы һәм аңа бәйләнгәнлеге аның тыңлаучанлыгы белән ныгытыла; шәехенә мәхәббәте никадәр зур булса, мөрид Аллаһыны танып-белү юлында да шулкадәр

алга китә дип санала. Шул ук вакытта татар суфи-шагыйренең «Шәех Зу-Нуна әл-Мисри мөриде хакында» әсәренең башында шәкертенең зарына каршы остазы аңа башкисәр булырга боера. Моны ул шактый тупас итеп әйтә һәм мөридне куып җибәрә. «Хәтта мөриднең рухи атасы булган шәех үз шәкертен тәрбияләгәндә тупас алымнар кулланган очракта та мөрид, тынычлык саклап, аны тыңларга тиеш, чөнки остаз моны мөриднең хаталарын төзәтү һәм аны рухи сафландыру максаты белән эшли. Алай гына да түгел, остазы кулланган алымнарның хаклы булуында мөрид аз гына да шикләнергә тиеш түгел. Шәехенә «Ни өчен?» дип ризасызлык белдергән мөрид беркайчан бәхетле булмас» [Адабы мюрида].

Ә. Каргалый хикәясендә мөрид канәгатьсезлек белдерми, ә остазы ихтыярына сүзсез буйсына, шуның өчен ахырда рәхмәткә ирешә. Автор, мөриднең шәехкә буйсынуына һәм аны тыңлавына, бу икәүнең үзара тыгыз һәм ихлас мөнәсәбенә аерым игътибар юнәлтеп, үз әсәрен суфичыл рухта төзегән.

Татар суфи-шагыйре Ә. Каргалыйның мөрид-юлбасар хакындагы әсәре, Фудайл ибне Ийәд турындагы моңа кадәр билгеле барлык тарихлардан аермалы буларак, бик нык трансформацияләнгән. Беренчедән, Ә. Каргалый әсәрендә Фудайл ибне Ийәднең прототибы булган мөрид бик борынгы мәгълүм суфи Зу-Нун әл-Мисриның шәкерте буларак тәкъдим ителгән, ә моның бернинди реаль нигезе була алмый, чөнки Фудайл ибне Ийәд вафат булганда (802/3 ел) Зу-Нун әл-Мисри (796–859) бары алты яшьтә генә булган. Икенчедән, мөрид тарихын Ә. Каргалый әсәрендә Фудайл ибне Ийәд турындагы мәгълүм легендалар белән бәйли торган төп нәрсә – геройның көтмәгәндә «әверелүе», әмма татар суфи-шагыйре хикәяләвендә сюжет көзгедәгечә чагылган: легендаларның төп версияләрендә Фудайл ибне Ийәд иң әүвәл башкисәр-юлбасар була, ә Ә. Каргалыйда исә төп герой соңрак, үз остазының боерыгын тыңлап, талаучыга әйләнә. Һәм, ниһаять, өченчедән, Фудайл ибне Ийәд турындагы традицион сюжетның төп канвасы аның тәүбә итүе һәм рухи әверелеш кичерүеннән гыйбарәт. Суфилар үтә торган, хак юлга кайтара торган тариканың башлангыч ноктасы – тәүбәгә килү. Кичерү сорап, гөнаһлардан тәүбә итү мотивы, һичшиксез, ул – «тәүбә»нең беренче баскычы. Гадәттә кеше күңелендәге тирән тетрәнүләр, дөньяга караштa бик тиз була торган үзгәреш-борылышлар рәвешендә сурәтләнә торган тәүбәгә килү мотивы мәшһүр суфиларның «табакать» жанрында язылган агиографик хезмәтләрендә еш яңгырый. Әш-Ша‘ранинең *«Табакать әл-кубра»,* Әбү ‘Әбд әр-Рахман ас-Суламиның *«Табакать әс-суфийа»,* Әл-Кушайриның *«Әр-Рисала фи ‘илм ат-тасаввуф»*, Гаттарның *«Тазкират әл-әулия»,* Мөхәммәд Морад Рәмзинең *«Нафа’ис әс-салихәт»*е һ.б. – әнә шундыйлардан.

Ә. Каргалый әсәрендә төп геройның тәүбә итү мотивы юк. Биредә төп мотив – югарыда әйтелгәнчә, мөриднең шәехенә, ягъни үзенең рухи остазына буйсынучанлыгы, күндәмлеге.

Шулай итеп, Ә. Каргалый иҗат иткән бу әсәр, үзенең структурасы һәм эчтәлеге белән төрле-төрле мотивларның, сюжет һәм тарихларның могҗизаи рәвештә үрелүеннән гыйбарәт калейдоскопны хәтерләтә. Мөрид Зу-Нун әл-Мисри турындагы тарих, шагыйрьнең башка бик күп әсәрләре кебек үк, гаять оригиналь. Әсәрдә авторның үзенчәлекле интерпретациясе бар һәм нәкъ менә шул сыйфат шагыйрь иҗатының әһәмиятен күтәрә дә.

**Әдәбият**


Адабы мюрида [Электронный ресурс]. URL: http://www.sufizm.ru/murshid&murid/adabi/2/ (дата обращения: 26.01.2014).

*Бертельс Е.Э.* Избранные труды. Суфизм и суфийская литература. М.: Наука, 1965. 528 с.

*Каргалый Ә.* Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. Казан: Казан ун-ның табгыханәсе, 1889. 34 б.

*Кныш А.Д.* Мусульманский мистицизм: краткая история / пер. с англ. М.Г. Романов. СПб.: Изд-во Диля, 2004. С. 29–31.



***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Л.Р. Надыршина*

# МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ ШИГЪРИЯТЕ: ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ, ТЕМА ҺӘМ МОТИВЛАР

В статье рассматриваются жанровые особенности поэзии М. Галиева, анализируются ключевые темы и мотивы. В ходе анализа выявляются основные тенденции развития творчества поэта. В начале творческой деятельности в лирике М. Галиева преобладает романтический дискурс, лирическому герою присущ бунтарский дух, ключевыми становятся мотивы поиска своего пути, единения, беспокойства о будущем, в интимной лирике раскрываются тема любви, судьбы родного дома, родного края, так же автор задумывается о таких философских понятиях, как время, судьба, память и др. В 1970-е годы в стихах поэта углубляется философское начало, усиливается их метафорический, ассоциативный характер. В конце XX века он обращается к социально-политическим мотивам, его произведения отражают думы о национальной истории и судьбе народа, родного языка, государственности, в творчестве доминирует мотив памяти, как один из лейтмотивов всего творчества поэта.

**Ключевые слова:** Марсель Галиев, татарская поэзия, жанр, тема, мотив.

The article discusses the genre features of M. Galiyev’s poetry, analyzes key themes and motives. The analysis identifies the main trends in the development of the poet’s creativity. At the beginning of his creative work, the romantic discourse dominates in Marsel Galiyev’s lyrics, the rebellious spirit is inherent in the character, the motives for finding one’s way, unity, concern for the future, the intimate lyrics reveal the theme of love, the fate of one’s home, native land, the author also thinks about such philosophical concepts as time, fate, memory, etc. In the 1970s, the philosophical principle deepened in the poet’s verses, their metaphorical, associative character intensified. At the end of the twentieth century, the author appeals to sociopolitical motives, his works reflect thoughts about national history and the fate of people, native language, statehood, the motive of memory dominates in poet’s entire creativity.

**Keywords:** Marsel Galiyev, Tatar poetry, genre, theme, motive.

Туган җир, нигез, тарихи тамырлар, хәтер, сәнгать төшенчәләрен үзәккә куйган лирик-фәлсәфи рухтагы әсәрләрендә үзенә генә хас язу стиле булдырган Марсель Галиев – ике гасыр чигендәге татар интеллектуаль әдәбиятының күренекле вәкиле. Әдип иҗат юлын лирикадан башлый. Аның 1970 елларда дөнья күргән шигырьләрендә яшьлек романтизмы, югары идеаллар өстенлек ала, лирик герой *тарих – заман – киләчәк* чылбырында үз урынын табу, үзеннән соң эз калдыру турындагы гамьнәргә бирелә. Шушы чорда иҗат ителеп, Такташ аһәңнәре ишетелеп киткән «Тик соңгылар булмыйк», «Дидем», «Яңа көрәшләргә», «Җыртабарлар», «Без дәшми калсак» һ. б. әсәрләрендә ашкынулы хисләр белән янучы, киләчәкне үз куллары белән төзүче романтик рухлы бунтарь яшь кеше образы тудырыла, лирик герой үзен аның белән бер сафта күрә:

*Без – бүгенге рух!*
*Чорга яраша бары кануннар.*
*Без дә дәшми калсак бүген,*
*Туры сүзен әйтер кай еллар?!* [Галиев, б. 24]

Гыйсъянчылык рухы белән сугарылган бу әсәрләрдә «киләчәк сорау алыр» дигән фикер лейтмотив булып уза, шул ук вакытта лирик геройны күңел шөбһәсе, шикләнү, төшенкелек тә биләп ала, мондый хиссият шигырьләрне ялгызлык, киләчәк өчен борчылу мотивлары белән баета. Мәсәлән, нәкъ менә шушы мотивлар яссылыгында анализланган «Ни илтәбез» шигырендә лирик герой «артык тынычланган», үткәндәге горурлык хисенә алданып яшәгән буынны уйланырга чакыра, ә «Без яшь идек ул чак» әсәрендә исә хыялый-максатчан яшьлек романтикасына каршы сурәтләнгән сүнеп барган учак һәм һәр геройның аерылгысыз юлдашы булган күләгә образлары гомер агышында идеалларның тоныклануы, яшьлек кайнарлыгының сүрелүе, ашкынулы көрәш тойгысының кимүе, бердәм дуслар сафының сирәгәюе хакында фәлсәфи уйлануларга алып килә.

М. Галиев шигъриятен аерып торган, аның иҗат стилен билгеләгән сыйфатларның берсе – фәлсәфилек. Әдип иҗатының башлангыч чорыннан ук тезмә әсәрләрдә кеше, шәхеснең үз-үзен һәм яшәешне танып-белү фәлсәфәсенә караган хасиятләр чагылыш таба, вакыт, язмыш, яшәү мәгънәсе турында уйланулар шигырьләрне иңләп уза («Еллар чалымы», «Үзең уйла» һ. б.). Еш кына шигырь юллары фәлсәфи мотивлаштырылган тыгыз эчтәлекле бер-ике сүздән оеша, һәм шагыйрьнең шул рәвешле аз сүз белән тирән мәгънә җиткерә алу сәләтен күрсәтә («Дидем», «Утыргычта ялгыз карт», «Хәтер», «Сальвадор Далича», «Мизгел», «Сыктау» һ. б.). Мәсәлән, фәлсәфи уйланулар төене булып формалашкан, нибары ун юлдан гыйбарәт «Утыргычта ялгыз карт» шигырендә сайлап кына бирелгән сүзләр тезмәсенә кешенең бөтен гомере, сызланулы күңел халәте сыйган:

*Хисләр тынган.*
*Уйлар арган.*
*Җан талган.*

*Күктә болытлар чистарткан*
*Көмеш чулпы – Ай калган.*
*Дулкындагы күбек сыман*
*Сүнәр-сүнмәс уй калган:*

*– Кемнәр куяр?..*
*Ташка айны*
*Кем уяр?..* [Галиев, б. 104]

М. Галиевнең үз-үзен һәм яшәешне танып-белү омтылышы белән янган лирик герое – җитлеккән, уйланучан шәхес, ул, үзенең уй-гамьнәре дәрьясында кайнап, яшәешнең экзистенциаль эчтәлекле төп хакыйкатенә төшенгән: гомернең үтүчәнлеген, вакыт агышын

туктатып булмавын аңлаган («Алда – өмет», «Бер көнлек гомер», «Иртә олыгайган уйлар» һ. б.). Бу үзенчәлек әсәрләрдә сызлану хисенең көчле позиция алуына китерә. Әлеге уйлануларны кешенең язмыш каршындагы көчсезлеге, шәхес һәм галәм каршылыгы турындагы фәлсәфи гамьнәр яссылыгына чыгарып, әдип адәм балаларының җир яшәешендә кеп-кечкенә бер кыйпылчык булуын аңлауга килә («Чын таулар эргәсендә», «Үз-үземә» һ. б.).

Гомумән, әдипнең шигъри иҗатында яшәеш турында уйланулар бик еш кына дөньяны экзистенциаль танып-белү кысаларына кертелә. Аерым алганда, лирик геройның күңел халәте белән бәйле ялгызлык мотивы күп кенә әсәрләрне бер бәйләмгә туплый, «ялгызлык белән җитәкләшеп», табигатькә ашкынган лирик герой образы күпмедер дәрәҗәдә маргиналь шәхес турындагы теория белән кисешә («Сүзсез шаһитлар»). Алданган, җәмгыятьтә аңлау таба алмаган, язмышы белән көрәшерлек көче калмаган лирик герой үзәккә куелган шигырьләрдә ялгызлык, язмыш, өметсезлек мотивлары бергә үрелеп китә («Шушымы язмыш?», «Хакыйкать», «Өметсез халәт» һ. б.). Экзистенциаль халәт, иң беренче чиратта, Хәтер һәм Хыялны югалту белән бәйле, менә шушы ике ачкыч сүз шәхес яшәешен гамьле һәм мәгънәле итә торган төп төшенчәләр буларак ачыла:

*Хыялның кулы бәйләүле,*
*Хәтер тора тез чүгеп.*
*Шәмнәргә ут кабызган да*
*Өмет киткән күченеп* [Галиев, б. 192].

Аерым бер шигырьләрдә инде лирик геройның күңел халәте бөтенләй капма-каршы якка үзгәрә: ул, сызланулы хиссияттән бушап, үзен бөтен җиһан каршында җаваплы көчле зат итеп тә тоя, яшәеш ямьсезлеге белән каршылыкка керә («Учларыма чумып», «Уяу бул, кешелек!», «Уяу сакта» һ. б.). Аның бу әсәрләрендәге глобаль уйланучы лирик герой кичерешләре үзенең шигъриятендә кеше һәм галәм фәлсәфәсен сәнгати үстергән Ә. Баянов иҗатына аваздаш яңгырый.

М. Галиевнең лирик героена яшәешне дуалистик кабул итү хас, «Зиратта яз», «Рояль», «Төн төсе», «Ике күк арасында», «Мизгел», «Кояш тотылганда» кебек шигырьләрдә Җирдәге һәр нәрсәнең каршылыклы асылы ачыла, яшәешнең ак-кара, яшәү-үлем, өмет-өметсезлек чикләрендә тирбәлүе табигый канун рәвешендә раслана:

*Без Җир, дибез.*
*Ә тамырларга – күк.*
*Безне чолгаган зәңгәрлек*
*Тамырларга – каберлек.*
*Кеше өчен икесе дә күк* [Галиев, б. 48].

А.Ф. Ганиева фикеренчә, 1960 еллар татар әдәбиятында йортнигез образы белән тыгыз бәйләнештәге әхлакый хәтер темасы үзәк темага әйләнә [Ганиева, с. 13]. М.Галиевнең күңел лирикасы

үрнәкләрендә дә хәтер мотивы туган як темасы һәм шуның яктылыгында ачылган туган җир, авыл, нигез, әти-әни образлары белән үрелеп бара («Мәдхия», «Иңнәрдә погон булса, күңелне сагыну баса», «Күңелдә бер бизәк» һ. б.). Әлеге шигырьләрдә җирсү, сагыш һәм үткәнне сагыну мотивлары әйдәп бара («Туган якның карашы», «Югалган блокноттан», «Һава өләшүче җарияләр», «Көтүче» һ. б.), туган җир турындагы хатирәләрнең күңелгә юаныч бирүе, әмма еллар шаукымының нигездән һаман да ерагайтуы турындагы сызланулысыктаулы кичерешләр шигырьләрдә лейтмотив булып үтә:

*Туган җирем тургай булып*
*Сыйган күңел читлегенә.*

*Әреме дә гөл генә шул,*
*Әреме дә гөл генә...*

*Нигез ташы чума бара*
*Караңгы җир күгенә...* [Галиев, б. 214]

«Сагынып кайту», «Бәхет», «Күреп кал», «Туган якка кайткач», «Ераклыклар җиле» кебек әсәрләрендә татар әдәбиятында традицион булган мәңгелек кайту мотивы яңартыла.

М. Галиев шигъриятендә зур урын алып торган тагын бер тема – мәхәббәт. «Көлә белеп көлдең», «Су хәтере», «Соклану. Гамь», «Яшьлек адымы» һ. б. шигырьләр татар әдәбиятында мәхәббәт лирикасына хас иң матур традицияләрне яңарта. Күп кенә әсәрләрдә яшьлек хатирәләре белән юанып яшәүче лирик герой образы үзәккә куела, сөюне ялгышып югалтудан туган үкенү хисе эчтәлек хасил итә («Юксыну», «Синең хакта...», «Шакыдым ишегеңне», «Синең бүлмәң», «Таныр идең микән» һ. б.).

Төш, сүнгән шәм кебек традицион романтик мотивларны яңарту («Төштән-төшкә», «Төш», «Шомлы бәхет» һ. б.), мифологизмнарга мөрәҗәгать итү («Адәм белән Һаува», «Яшәү – мизгел генә», «Мәңгелек әверелеш» һ. б.) кебек әдәби алымнар да М. Галиевнең мәхәббәт лирикасын сәнгати яктан баета, интертекстуаль бәйләнешләр барлыкка китерә.

М. Галиев иҗатына рәсем сәнгате йогынтысы бик көчле, бу – образлар бирелешендә дә, сурәтләү чаралары сайлаганда да, дөньяны рәссамнарча күзаллауда да күренә. Мәсәлән, әдипнең пейзаж лирикасы үрнәкләрендә табигатьнең талгын, самими сурәтләре төсләр балкышына нигезләнгән гүзәл этюдлар булып укыла, сизгер күңелле шагыйрь тотып ала белгән детальләр укучы хозурына җанлы-тере картина рәвешендә килеп баса («Күңел юанып ала», «Этюд», «Төсләрдән – шәраб» һ. б.), детальләрдә табылган фәлсәфилек аша гомернең үтүен, мәңгелек агышында бер мизгел булуын аңлау халәте тоемлана («Кая соң?»). Гомумән, пейзаж лирикасында да шагыйрь фәлсәфи гамьнәрне беренче планга чыгара, яшәеш кануннары турында уйлана («Канаты киселгән каз», «Әбиләр чуагы», «Пәйгамбәр тырнагы» һ. б.).

М. Галиевнең иҗтимагый лирикасы тема-мотивлар һәм проблемалар төрлелеге белән аерылып тора. Әйтик, татар әдәбиятында киң яктыртылган иҗат мотивы әдипнең башлангыч чор әсәрләрендә үк чагылыш таба, шагыйрьлекне илаһилаштыру идеясе үстерелә, Хак Шагыйрьне ярымкеше, ярымалла дәрәҗәсенә кую, фольклор традицияләре, мифологик күзаллаулар белән бәйләп, «кош каурые белән мәңгелеккә юл сызучы» рәвешендә күзаллау шуңа бәйле укыла («Һәр заманның үз алыбы», «Ышанам»), Н. Исәнбәт, С. Сәйдәшев, Р. Вәлиев, Х. Сарьян, М. Әгъләмов һ. б. зыялыларга багышланган шигырьләр бәйләме гүзәллеккә табынган, халыкның күңел кылларын тибрәткән иҗат әһелләренең горур портретын тудыра, иҗатның милләткә хезмәт белән бәйле булырга тиешлеген кабат-кабат ассызыклый. М. Галиев туры сүзлелек һәм вөҗданга хыянәт итмәүне иҗат кешесен бәяләү критерийлары итеп билгели, шагыйрь-көрәшче, иҗат-ирек бергәлеген раслый.

Шагыйрьнең иҗтимагый лирикасында тарих, милли үзаң, тел, мәдәният мәсьәләләре хәтер мотивы белән тыгыз бәйләнештә ачыла («Хәтер», «Хәтерсез калу хәтәр», «Исәнме, дип карыйм илләрне», «Ай», «Тузан булып», «Ташлар дәшми», «Туфрак булган» һ. б.). Әдипнең лирик герое өчен халкыңның тарихын белү милли горурлык хисе белән турыдан-туры бәйле, бөеклеккә, дәүләтчелеккә ирешкән татарның шанлы үткәнен зурлау идеясе Аттила, Бату, Чыңгызлар, Аксак Тимерләр дәверенә үк юнәлдерелгән тарихи сәхифәләрне шигырь тукымасына кертә, Болгар дәүләте чорын хәтердә яңарта («Атлы Болгар ядкәре», «Йола», «Болгарда» һ. б.). Бу шигырьләрдә сурәтләнгән тарихи вакыйгалар яктылыгында заман, чор проблемалары калкытыла. Тарихи хәтер мотивын үстергән шигырьләрдә еш кына, ирек, хөрлек, рухи бәйсезлек символы буларак, дала образы чыгыш ясый («Дала догасы», «Дала каны», 2006). «Борынгы бабаларыбыз табынган хәрби рухның чагылышы, бөек цивилизация символы» [Хәбетдинова, б. 101] рәвешендә кабул ителгән әлеге образ тарихның данлы сәхифәләрен ачардай хронотоп булып китә, бөеклек, горурлык идеясен чагылдыра. Шул ук вакытта тарихи сәхифәләргә кагылган бу шигырьләрне бер бәйләмгә туплаган үкенү хисе укучы күңеленә дә күчә. Бөек халыкның дәвамчы буыны вәкиле була алмавына ачынган лирик герой кичерешләре халык күңелендә туган хисләр кебек гомумиләшә («Табарлар безнең эзләрне», «Ташлар дәшми», «Ходайга да бик күңелсез булыр» (2007) һ. б.).

М. Галиев иҗатында иҗтимагый аһәңнәр XX йөз ахырында көчәя, тәнкыйди караш беренче планга чыга, тарих, тел, дәүләтчелек проблемалары күпсанлы шигырьләренең үзәгенә куела. Шушы вакыт аралыгында иҗат ителгән «Туган телем», «Чагыштыру килер бер көн» (2004), «Гасыр ызанын чыккач» (2003), «Эш атының тояклары...», «Аксиома», «Ярый әле» кебек шигырьләрдә бөек милләт варисларының үз дәүләтчелеге кыйпылчыкларын җыю омтылышы сурәтләнә, заманның кысыр вәгъдәләре кире кагыла. Әдип иҗатында

җәмгыятьтәге тәртипләрне, кешеләр яшәешен кискен тәнкыйтьләү пафосы үсә, куштанлык, ясалма дан-шөһрәт, ялган тарихка табыну кебек проблемалар заман чире буларак бәяләнә («Куштанлык», «Алдаучан бөеклек», «Мөтәгалимгә», «Җылыйсы килгән заман» һ. б.). Аерым бер әсәрләрдә тәнкыйтьләү сатирик эчтәлек ала («Кычкырды дөнья йөзенә...», «Алама чор», «Мәҗлес» һ. б.).

Шул рәвешле, М. Галиев шигърияте уй-кичерешләр тирәнлеге белән аерылып тора, әдипнең иҗат стилен билгеләгән үзенчәлекле сурәтләү чаралары, янәшәлекләр аның иҗади зәвыгын, таләпчәнлеген раслыйлар. Жанр ягыннан төрле булган шигырьләрне детальләрдә, эчтәлектә табылган фәлсәфилек берләштерә, тарих, заман, яшәеш, милләт турында уйланулар идеяне билгели.

## Әдәбият

*Галиев М.* Әсәрләр: 6 томда. Т. 1. Казан: Идел-Пресс, 2011. 408 б.

*Ганиева А.* Модификация образа дома в современной татарской прозе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2017. № 11(77): в 3-х ч. Ч. 1. С. 12–15.

*Хәбетдинова М.* «Без бу җиргә юкка килмәгән...» (Марсель Галиевкә 70 яшь) // Казан утлары. 2016. № 10. Б. 94–101.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Г.И. Каюмова*

# «БИТЛЕКЛӘР» УЕНЫНДА – МИЛЛӘТ ФАҖИГАСЕ... (Р. Хәмиднең «Җанкай улы Җанкыяр» трагифарсы буенча)

В статье дается анализ драматического произведения, в данном случае трагифарса «Сын Джанкая Джанкыяр», написанного Р. Хамидом, где автор с помощью художественных изобразительных средств раскрывает причины, угрожающие сохранению татарского народа как нации, также выявляются художественные находки драматурга, используемые для раскрытия данной проблемы.

**Ключевые слова:** Р. Хамид, трагифарс, образы-маски, игра, нация, татарский народ.

The article provides an analysis of the dramatic work, in this case it's the tragic farce «Dzhankay's Son Dzhankyyar», written by R. Hamid, where the author reveals the reasons that threaten the preservation of the Tatar people as a nation using artistic visual tools, which are used to uncover this problem.

**Keywords:** R. Hamid, tragic farce, mask images, game, nation, Tatar people.

Милләт язмышы, аның киләчәге мәсьәләсе һәр чор каләм ияләрен борчый, уйландыра. Заманында Г. Исхакый «Зөләйха» драмасында руслашу билгесе булган көчләп чукындыруга каршы чыга. «Ул әле өйләнмәгән иде» повестенда иске татар тормышыннан канәгать булмаган кешенең акрынлап үз милләтеннән ваз кичүен сурәтли. «Җан Баевич» комедиясендә «руслашуның милләтебезне нинди аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкинлегенә басым ясый» [Каюмова, 2018, б. 255]. Безнең көннәрдә көчләп чукындыру – кыргыйлык күренеше. Тик руслашу процессы да тукталмый. Кызу адымнар белән үсә генә. Милләтебезнең ассимиляциясен тизләтүче катнаш никахлар мәсьәләсе – җәмәгатьчелекне нык борчыган җитди мәсьәләләрнең берсе. Татар милләтен һәлакәткә китерүче бу хәлгә әдипләребез битараф кала алмыйлар, җәмгыятебезнең милли-рухи ярасына әверелгән әлеге проблеманы әсәрләрендә кыю күтәреп чыгалар һәм катнаш никахның милли рухка гаять зур зыян китерүен ачыктан-ачык язалар. Халкыбызның киләчәге өчен чын күңелдән борчылган, милләтнең акрынлап сыегая баруын руслар белән татарлар арасындагы катнаш никахларда күргән драматург Т. Миңнуллин «Илгизәр + Вера» (1992) драмасында әлеге проблеманы үзәккә алып яктырта, мондый никахларның аянычлы юнәлеш алу сәбәпләрен ачып сала.

Татарның «язылмаган законнар»га таянып эш итүенә: үз теләге белән теленнән, диненнән һәм, ниһаять, милләтеннән йөз чөерүенә җаны сыкраган Р. Хәмид тә трагедия, драмаларында туган телгә мөнәсәбәт һәм катнаш никах мәсьәләләрен һәрдаим кузгата. Комедияләрендә дә драматург бу мәсьәләләрне гомуммилләт фаҗигасе буларак яктырта һәм моңа үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Әдипнең

«Җанкай улы Җанкыяр» трагифарсы [Хәмид, 1998] – «татар милләтенә башка милләт вәкилләре белән, бигрәк тә урыслар белән катнаш гаилә коруның никадәр хәвефле икәнен масштаблы итеп, сәнгатьчә көчле итеп сурәтләүнең иң уңышлы мисалларыннан берсе» [Әхмәдуллин, 2002, б. 19]. Пьесада татар байларыннан Атилла сүзләренә игътибар итик: «Сезнең алдыгыздагы картада йөз ел чамасы элегрәк бүгенге чикләрдәге Рәсәйдә безнең халыкның ни дәрәҗәдә укмашып яшәве күрсәтелгән: ачык яшел төсләрдә барелде ул. Хәзерге республикалар, әлбәттә, юк анда, әмма сезгә җиңелрәк күзаллау өчен, Татарстан белән Башкортстан чикләре өзек сызыклар белән билгеләнде. Ачык күрәсез: безнең халык элек-электән читләргә сибелеп яшәгән. Инде хәзер ярты гасырга үзебезгә таба чигерик. Яшел төсләрнең уңуына игътибар итегез: татар халкының үз сафлыгын күпме дәрәҗәдә югалтып өлгергәнлеген аңлата бу. Кемнәрдер бөтенләй урыслашкан, кемнәрдер – катнаш гаиләләр төзеп, милли йөзләрен югалтып баралар, ягъни бүтән милләт балалары үстереп яталар. Төгәл генә мәгълүматлар юк, ләкин чамаларга мөмкин. Бер нәрсә бәхәссез: безнең халык югалу процессына кызу адымнар белән кереп киткән инде!». Атилла җиде кешедән торган «Җидегән» оешмасы оештыра. Әлеге оешманың әгъзалары да – катнаш гаилә корган татар милләте вәкилләре. Берсенең дә баласы ана телен белми. Шул сәбәпле аларның һәммәсе дә «халкыбыз алдында үзен гаепле саный». «Шуңа күрә без спонсорлыклар итәбез, мәчетләр төзешәбез, милли хәрәкәтләргә ярдәм кулы сузабыз, – ди Атилла. – Ләкин боларны без очраклы рәвештә генә эшлибез. Бер җайга салынмаган. Ата-бабаларыбызның рухын терелтүгә юнәлдерелгән максат куеп эшләнми. Безнең төп гаебебез нәрсәдә? Буыннар чылбырын өзүдә! Ата-бабаларыбыз татар булган, ә без, шуны юкка чыгарып, нәселләребезне бүтән милләтләргә кушып җибәрүчеләр», – дип бик әһәмиятле сүзләр сөйли. Әлеге оешманың төп максаты – «халкыбызга милли рухны кайтару, аның киләчәге өчен кулдан килгәнчә ярдәм итү».

Фарсның юморы үзенчәлекле. Персонажлар һәрвакыт карикатура хәлендә, аларның җитешсезлекләре соңгы чиккә җиткерелеп, күпертеп сурәтләнә [Әдәбият белеме.., 1990, б. 195]. Әлеге трагифарста да, Атилладан кала, оешма әгъзаларының барысы да – йөзләренә битлек кигән персонажлар. Аларны Атилланың улы Виктор «новая секта скороспелых миллионеров» дип атый. Болар – әдипнең төп фикерен җиткерүдә зур әһәмияткә ия схематик-абстракт образлар. Әсәрдә «беренче», «икенче», «өченче» һәм «башкалар» дип бирелгән әлеге «битлекләр»нең сүзләрендә драматург күтәргән мөһим проблемаларга төрле мөнәсәбәт күзәтелә.

Билгеле булганча, арттыру – комедиянең көчле коралы. Трагифарста битлек образы – гротеск күренеше. Гротеск – сатирик типиклаштыру чарасы, «халыкчан көлү сәнгатенең борынгыдан килгән яратып кулланыла торган формасы» [Пропп, 1976, б. 70], бирелә «образ үзенең реаль йөзен югалта, танымаслык хәлгә килә» [Хатипов, 2002, б. 118].

Пьесада йөзләренә битлек кигән мул тормышлы кәсәбәчеләрнең милләт язмышын кайгыртырга алынулары автор ирониясе булып аңлашыла. Гомер буе үз тормышларын яхшырту турындагы эгоистик максатларны гына күздә тотып яшәргә күнеккән яңа татар байларында кинәт милли аң уяну ышандырып җиткерми. Пьесада битлек образы – әлеге кешеләрнең чын йөзен яшерү алымы, шулай ук аларның үз йөзләре юклыгына да ишарәле. Трагифарс тулаем уенга корылган. Әсәрдә «карнавализация» күренеше, ягъни «дөнья-текстны уен аша танып белү» [Скоропанова, 2001, б. 40] күзәтелә. Уен күренеше әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең барлык төрләрендә дә очрый. Әмма «театраль уен сәнгате белән бәйле драматургиядә ул аеруча камил» [Данилова, 2002, б. 27]. Галимнәр фикеренчә, уен – постмодернизм әдәбиятына караган асыл күренешләрнең берсе [Халипов, 1994, б. 239; Вайнштейн, 1993, б. 5]. И. Скоропанова постмодернистик дөньяның гиперреальлек белән аңлатылучы «чынбарлыкта булуы мөмкин дөнья» икәнлегенә басым ясый. Ул реализм, модернизм, постмодернизм күренешләрен бер-берсенә каршы куймый, ә киресенчә, без яши һәм төрлечә кабул итә торган дөньяның төрле якларын ачуда аларның бер-берен тулыландырып торуларын билгеләп үтә [Скоропанова, 2001, б. 362]. Әлеге трагифарс та – шундый синтезның уңышлы мисалы, чөнки әсәрдә «абсурдлык театры», «явызлык театры» кебек модернизм күренешләренә дә юлыгабыз.

Шул рәвешчә пьесада «битлекләр» оешмасы татар милләтенә милли рухны кайтару уенын башлап җибәрә. Катнаш никахтан туган, татарча бер авыз сүз белмәгән, бары тик я эстонча, я таҗикча, я русча гына сөйләшүче балаларны Атилла мәктәптә әниләре белән бер парта артына утырта. «Үз телләрен бирә алмаганнар икән, тик тылмач булып утырсыннар газиз балакайларына!» – ди ул. Әлеге абсурд күренеш милләт язмышының никадәр аяныч булуын ассызыклый һәм драматургның кисәтүе кебек аңлашыла.

Трагифарста туган телен, гореф-гадәтләрне, милли күренешләрне, гомумән, татар мохитен күңеленә якын итә алмаучы Виктор – үзенчәлекле образ. Геройның чын исеме – Вәкил. Милли рухы сакланмаган әлеге татар егете образы әсәрдә, аның танышы – авыл кызы Зәлия сүзләре белән әйтсәк, чын мәгънәсендә манкорт буларак ачыла. Егет сүзләреннән аңлашылганча, аның татар теленә, газиз халкына тискәре мөнәсәбәте формалашуда чыгышы белән рус милләтеннән булган әнисенең йогынтысы зур була. Берара үзе дә әтисеннән бизә башлый. Димәк, туган телдән читләшү процессы малайда гаилә эчендә атага мөнәсәбәтле башлана. Викторның, әби-бабасы йортына кайткач, йортта кеше юклыгын абайлап, «Куда эт-та делась татарва» дигән сүзләре, әлеге милли рухлы йортны, туганнарын, әбисе белән бабасын чит күреп, чоланда ашавы, фаҗигагә юлыгып гомере өзелгән әтисенең каберен бутап, аның урынына икенче кешене күмеп куелганы ачыкланганнан соң, Викторның ачы тавыш белән: «За папой поехал… И не смейте меня уговаривать! Я сам его похороню! В городе!

Папа правильно делал, что всю жизнь избегал вас! И я надеюсь, что никогда не встречусь с вами – татарвой!» – дип кычкырып, йортны, якыннарын ташлап чыгып йөгерүе – «туганлык хислəренең абсурд девальвациясен билгелəүче кыргый какафония күренеше» [Громова, 2003, б. 103]. Əлеге абсурд күренешлəр татарның хəтта иң газиз кешелəрен дə ят итəр дəрəҗəдə башка миллəт тарафыннан йотылуы куркынычын, милли тəрбиянең чик дəрəҗəдə түбəн булуын ассызыклый. Шушы фаҗигане бирүдə бу – шулай ук драматургның сəнгатьчə табышы.

Миллəтара мөнəсəбəтлəрне, алар тəэсирендə бер миллəтнең икенчесе тарафыннан йотылуы күренешен драматург пьесада эзоп теле белəн ике чишмə – Баллы Чишмə һəм Приблудница чишмəлəре – аркылы бирə. Баллы Чишмə дигəндə татар миллəте күзаллана, Приблудница рус миллəте буларак аңлашыла. Əлеге чагыштыруның нигезендə тирəн иҗтимагый мəгънə ята. Бу уңайдан Виктор белəн Зəлия диалогы игътибарга лаек. Кыз егеткə Кыдаш елгасына коючы əлеге ике чишмə арасында кайсының исеме өстенлек итəргə тиешлеге хакында гасырлар буена бəхəс баруын төшендерə.

Зəлия. *У нас есть одна очень интересная поговорка: ике чишмə бергə кушылса, берсе үлə, имеш. Если соединяются две ручьи, одна из них высыхает, то есть теряет имя.*

Виктор (елмая). *Значит, Приблудница права! Она – гораздо полноводнее и длиннее Медоносицы – её название должно сохраниться!*

Зəлия. *А вот и нет: на местных картах приток обозначен как Баллы Чишмə! Приблудница считается его притоком.*

Виктор. *Но ведь это несправедливо!* (Көлə.) *Я бы на месте Приблудницы на картографов в суд подал! Большое всегда проглатывает меньших: так заведено самой природой-матушкой. Тут уж ничего не поделаешь, бабушка Изергиль!*

А. Əхмəдуллин: «Катнаш гаилə, нык һəм тату булган очракта да, ул объектив төстə бер миллəт файдасына гына булып чыга. Бигрəк тə сан ягыннан зур булмаган миллəт белəн саны азрак миллəт арасындагы мондый мөнəсəбəтлəр соңгысына зыян сала, – ул аны үз файдасына суыра бара. Татар миллəте белəн дə шул ук хəл» [Əхмəдуллин, 2002, б. 75], – дип хак яза. Егет белəн кыз диалогында да шул хакыйкатькə юлыгабыз. Кызның бу уңайдан егеткə əйткəн җавап сүзлəре иҗтимагый-сəяси əһəмияткə ия:

Зəлия (кинəт җитдилəнə). *Вон оказывается, почему грозит исчезновение татарам! По-твоему выходит, что есть на свете народы-живоглоты и народы-жертвы. А кто их так распределил? Бог? Аллах? А если я не захочу быть проглоченной и начну драться как Чечня?! Пошлёшь на меня танки восстанавливать свою «справедливость»?!*

«Битлеклəр» татар телен саклау һəм үстерүдə халыкның битарафлыгына басым ясыйлар, татар халкының «тышаулы халык» булуы,

аның «үз-үзенә сихерле тышау салып куюы», шулай яшәүне хуп күрүе турында әйтешеп зарланышалар. «Мәктәптә элек тә бар предметларны урысча укыталарие, әле дә урысча...» – ди берсе. Атилла сүзләре белән драматург ана телебезнең «формаль яктан гына дәүләт теле» булуын кисәтә.

Әсәрнең исеме символик мәгънәгә ия. Атилланың кушаматы кайчандыр «җанкай җанаш» булган. «Җанкай» – бик якын иткән кешеләреңә яратып әйтә торган сүз. Ләкин шундый яхшы күңелле атаның улы җан кыяр, ягъни үз халкына үзе «аяк чалучы» мәрхәмәтсез зат булып үскән. Улының үз телен, динен, халкын хөрмәт итмәвендә, алай гына да түгел, аннан йөз чөерүендә матди байлыкны гына кайгыртып дөнья куган атаның гаебе чиксез зур. Әлеге хәл халкының милләт буларак юкка чыга баруын үз күзләре белән күргән Атилланың рухи фаҗигасен тагын да көчәйтә. Ул улының телсез, динсез булып үсүендә үз гаебен таный. Пьесада атаның хатаны төзәтү эшен – улыннан, ә «битлекләр»нең гаиләләреннән башламыйча, башкалардан таләп итүләре – шулай ук абсурд һәм көлке күренеш. Бу исә милли фаҗиганең никадәр тирән булуын күрсәтә.

Татарның язмышын уңай якка үзгәртергә алынган «битлекләр»нең эшләре барып чыкмый. Бу эшкә җитәкчелек иткән Атилланың үлеме дә шуңа ишарәли. Ул оештырган «битлекләр» җәмгыяте дә таркала, юкка чыга. М. Эпштейн фикеренчә, «уңышлы башкарылган үлем поэтикасы һәм үлемгә хөкем ителгән битлекләр уены (некропоэтика) постмодернизм күренеше булып тора» [Эпштейн, 2001, б. 297].

Фольклор алымына хас булганча, әсәр азагында «битлекләр» уены яңадан кабатлана, «кабатлану – уенның иң асыл үзенчәлекләреннән берсе» [Хейзинга, 2001, б. 20]. Бу юлы «битлекләр» башлыгы Виктор була. Виктор үз мәгарәсендә «рус битлекләре»ннән тупланган җәмгыять белән «фан-клуб Интим» оештыра һәм бөтен нәрсәгә дә уенга караган кебек карарга тәкъдим итә. Виктор җәмгыяте һәм ул оештырган уен этисе Атилланың вөҗданлы уенына капма-каршы куеп бирелә. Ул «рус битлекләре» белән әхлакый түбәнлекне ассызыклаучы күңел ачу уены, ягъни битлекләр маскарады оештыра. Эротик сәхнә – шулай ук фарска хас күренеш.

Әсәр азагында шәһәр егете Виктор белән авыл кызы Зәлия кабат очраша. Алар сөйләшеп торган вакытта каршы бүлмәдән Виктор оештырган интим уен нәтиҗәсендә күлмәкләре ерткаланып беткән дус кызы Надяның ачыргаланып кычкырып килеп чыгуыннан һәм егеткә рәнҗеп әйткән сүзләреннән Зәлия Викторның аңга килмәвен, киресенчә, әхлакый деградация кичерүен аңлый. Шул рәвешчә битлекләр маскарады аркылы драматург фахишәлек, битарафлык, оятсызлык чәчәк аткан дөнья моделен бирә. Башкача әйтсәк, Виктор уены хәзерге әхлаксыз реаль тормышны гәүдәләндерә.

Пьесада шулай ук «битлекләр» уены аша «архетипик тәҗрибә чынбарлыгына» [Скоропанова, 2001, б. 151] омтылыш күзәтелә, «милли характер тирәнлегенә төшенү, шуңа бәйле рәвештә үз-үзеңне

танып белү» [шунда ук] процессы бара. Викторның рухи халəте моны раслый. Егет Зəлиянең кайчандыр аңа булган ышанычын акламавын, үзенең дөрес булмаган яшəү рəвеше алып баруын аңлап күңелсезлəнə, төшенкелеккə бирелə, «битлеклəр»гə нəфрəте көчəйгəннəн көчəя бара.

Динен, денен саткан Викторның язмышы фаҗигале тəмамлана: «рус битлеклəре» аны чолгап алалар һəм гомерен өзəлəр. Ул – трагик шəхес. Трагизмның төп сəбəбе – кешенең, дөрес яшəү кыйбласын югалтып, телен, динен, миллəтен «танымый»ча, башка бер миллəт тарафыннан «йотылып» яшəргə мəҗбүр булуында. Əсəр азагында кабатланган үлем күренеше яңа иҗтимагый мəгънə ала. Татар егетен «рус битлеклəре»нең чолгап алуы һəм юк итүе татар миллəтен, битараф яшəү рəвеше алып барган очракта, шуңа охшаш язмыш көтүенə ишарəли кебек.

Викторга алмашка яңа кеше туа. Ул – инде дөрес юлга баса башлаган Атилланың икенче улы. Баланың əнисе – Атилла игезəге Саматның хатыны Нəдимə. Яңа туган бала образы – миллəтне коткару символы кебек аңлашыла. Бəлки, ул килəчəктə əтисе башлаган эшне тормышка ашырыр. Күрəбез: драматург тормышның икеяклы (бинар) законнарын – яшəү һəм үлем, яхшылык һəм явызлык күренешлəрен – янəшə бирə. Бу кешелек яшəешен билгелəүче инь-ян принцибы күренеше булып тора.

Атилла белəн игезəге Самат образлары пьесада иҗтимагый əһəмияткə ия. Əлеге геройларның тышкы охшашлыклары эчке дөньяларына контраст рəвешендə бирелгəн. Матди мөмкинлеклəре бердəй җитеш булган хəлдə Атилла бөтен бер миллəт кайгысын кайгыртса, милли рухны кайтару өчен тырышса; Самат, киресенчə, əлеге рухны саклап торкан авыл урынына зур бер санаторий салдырып, авылны юкка чыгарырга ниятли һəм безнең күз алдыбызга үз максатына ирешү өчен бернидəн дə чирканмый торган рəхимсез, явыз, эгоист зат булып килеп баса. Аның характер үзенчəлеклəре шофёры Данил, хатыны Нəдимə сүзлəрендə дə ачыла.

*«Самат җизнəңне бер дə белмисең, дип əйттем ич менə!.. Викторы түгел, игезəге үзе дə сукыр бер тиенгə кирəкми аңа! Самат җизнəңə Җанкай Җанашның тирəн янчыгы белəн кайбер əшнəлеклəре генə кирəк. Район башында утырган нəчəлник кəмəшлəре белəн əшнəлеге!»* – ди Данил Зəлиягə.

*«...Тыңлап тордыгыз бит: дөньяның кендеге, диярсең! Атилланың кисеп ташлаган тырнагына да тормый Саматыгыз... Яшь чагында сукыр буласың икəн шул...»,* – ди Нəдимə кайнанасы Гаҗибəгə.

Шəхси мəнфəгатьлəре көчле булган, туган авылын юк итеп, анда зур санаторий ачып, яхшы коттедж салып, бай, мул тормышта яшəргə омтылган, килəчəктə депутат булу максатын күздə тотып, яшерен рəвештə Атилланың оешмасы белəн дə элемтəдə торган Самат үзенə «аяк чалырга» җыенучы игезəге Атилланың гомерен өзүгə кадəр барып җитə. Депутатлыкка үз кандидатурасын уздыру өчен, игезəгенə

авария оештырып, аны харап итә. Моның белән драматург шәхси мәнфәгатьләр туганлык хисләрен дә җимерергә сәләтле куркыныч, әхлак таркау болгавыр бер заманда яшәгәнлеккә басым ясый кебек. Иҗтимагый максатларның төрле юнәлеш алуы аркасында, җәмгыять һәм шәхес арасында туган гаять көчле киеренкелек рәвешендә, «явызлык театры»на хас булганча, ике бертуганның шәхси мөнәсәбәтләре фаҗигале тәмамлана. Әдәбият белемендә мондый геройларның берсен «культуралы герой» һәм аңа капма-каршы булганын «трикстер» дип атыйлар. «Трикстер – культуралы геройның аңа каршы куелган игезәге... Трикстер, культуралы геройдан аермалы буларак, билгеле бер дәрәҗәдә асоциаль, шуңа күрә аеруча «персональ»» [Литературные архетипы.., 2001, б. 113].

Виктор образы пьесада куш асыл (двуединая сущность) буларак бирелүе белән үзенчәлекле. Геройның ике төрле (двойственный) табигате ике хронотоп чигендә ачыла: берсе – рус телле шәһәр тормышы, икенчесе – әби-бабасы, туганнары яши торган авыл мохите. Бары рус телен генә якын иткән, татар телен телгә санамаган шәһәр егете Вәкилдә, авыл җиренә кайтып, татар кызы Зәлия белән танышу, аралашу аркасында, гомумән, татар мохите йогынтысында туган теленә кызыксыну уяна. Бу егет күңелендә якты якның өстенлек ала башлавын күрсәтә, ләкин этисе үлеп, кабат шәһәр тормышына кайткач һәм рус телле мохиткә килеп эләккәч, егет күңелендә яңадан караңгы як өскә чыга. Әлеге мохит трагифарста характерны җимерүче көч буларак күзаллана. Инсан табигатенең ике төрле булуы кеше күңелендә уңай һәм тискәре башлангычларның урын алуын, алар арасындагы көрәшне күрсәтә. Әлеге көрәш инь-ян принцибы белән аңлатыла. Кеше психикасындагы уңай һәм тискәре яклар кешене «икегә бүленергә» мәҗбүр итә. Кайчандыр усал, үзен генә яратучы Саматны һәм хәзер аннан күпкә аерылып торган игезәге Атилланы сөюче Нәдимә дә күңелендә һәм якты, һәм караңгы яклар каршылыгы булган куш (двуединый) кеше буларак күзаллана.

Күрәбез: Р. Хәмид «Җанкай улы Җанкыяр» трагифарсында татар халкының милләт буларак юкка чыга бару сәбәпләрен күрсәтә һәм милли фаҗига проблемасын халыкка җиткерүдә яңа сәнгатьчә алымнар куллана. Драматург тарафыннан тәкъдим ителгән чынбарлыкның абсурд концепциясе, яшәеш шул рәвешле дәвам иткән очракта, милләт фаҗигасенең котылгысыз булуын раслый. Автор татар халкы үз теленә, диненә, борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә, милли традицияләргә һәм, ниһаять, газиз халкына тугрылык саклаган мәлдә генә милли-рухи йөзен югалтмый, ихтыяр көчен җуймый; милләт җанлы халык кына аягында нык басып тора, токкан кыйбласыннан тайпылмый, киләчәккә ышаныч белән карый ала дип әйтергә тели кебек.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме сүзлеге / төз., ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 239 б.

*Əхмəдуллин А.* Офыклар киңəйгəндə. Əдəби тəнкыйть мəкалəлəре. Казан: Татар. кит. нəшр., 2002. 239 б.

*Вайнштейн О.Б.* Постмодернизм: история или язык // Постмодернизм и культура: Материалы «круглого стола» // Вопросы философии. 1993. № 3. С. 3–7.

*Громова М.И.* Русская современная драматургия: учеб. пособие для студ.-филол. уч-ся ср. учеб. завед. гуманит. профиля. 3-е изд., стереотип. М.: Флинта: Наука, 2003. 160 с.

*Данилова И.Л.* Стилевые процессы развития современной русской драматургии: автореф. дис. … д-ра филол. наук; Казанск. гос. ун-т. Казань, 2002. 44 с.

*Закирҗанов Ə.* Заман белəн бергə: Əдəби тəнкыйть мəкалəлəре. Казан: Татар. кит. нəшр., 2004. 175 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һəм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нəшр., 2003. 255 б.

*Каюмова Г.И.* «Җан Баевич» комедиясендə миллəт язмышы проблемасының үзенчəлекле гəүдəлəнеше (Г. Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан) // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: сб. статей итог. науч. конф. сотрудников Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ / под ред. И.А. Гилязова, М.З. Хабибуллина. Казань: Академия наук РТ, 2018. Вып. 10. С. 254–263.

Литературные архетипы и универсалии / под ред. Е.М. Мелетинского. М.: Рос. гос. гуманит. ун-т, 2001. 433 с.

*Пропп В.Я.* Проблемы комизма и смеха. М.: Искусство, 1976. 183 с.

*Сахновский-Панкеев В.* О комедии. Л.–М.: Искусство, 1964. 224 с.

*Скоропанова И.С.* Русская постмодернистская литература: новая философия, новый язык. СПб.: Невский Простор, 2001. 416 с.

*Халипов В.* Постмодернизм в системе мировой культуры // Иностранная литература. 1994. № 1. С. 235–240.

*Хатипов Ф.М.* Əдəбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Раннур, 2002. 352 б.

*Хейзинга Й.* Homo ludens. Опыт исследования игрового элемента в культуре / пер. с нидерланд. и примеч. В. Оленса. М.: ЭКСМО-пресс, 2001. 351 с.

*Хəмид Р.* Җанкай улы Җанкыяр: ике бүлекле трагифарс. Казан, 1998. 64 б. (Əсəр кулъязма варианттан анализланды). Цитаталар шушы чыганактан алынды.

*Эпштейн М.* Постмодерн в России: Литература и теория. М.: Издание Р. Элинина, 2001. 368 с.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фəннəре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе һəм төбəкне өйрəнү институты Энциклопедистика үзəгенең өлкəн фəнни хезмəткəре*

УДК 398

*И.И. Ямалтдинов*

# XX ГАСЫР УРТАСЫНА КАДӘР ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ ЖАНРЛАРЫН ӨЙРӘНҮ

Изучение жанров татарского народного творчества приходится на начало прошлого века. С начала XX века на страницах журналов печатаются статьи Г. Юлдашева, Г. Рахима, М. Акчурина, Г. Тулумбайского и других авторов о татарских народных песнях, обрядовом фольклоре, эпических произведениях. Определённую лепту в развитие татарской фольклористики внесли классики татарской литературы: поэт Г. Тукай и писатель Г. Ибрагимов, учёные Г. Баттал, Г. Сагди, Х. Ярми, Н. Исанбет и др.

В данной статье автор анализирует труды исследователей фольклора по изучению жанров татарского народного творчества до середины XX века. Он приходит к выводу, что до середины XX века изучение жанров татарского фольклора находилось в центре внимания. В своих трудах, напечатанных в виде предисловий к различным сборникам, отдельных статей исследователи излагали свои взгляды на роды и виды народного творчества, создали научную классификацию отдельных жанров, выделили их специфические особенности.

**Ключевые слова:** фольклор, татарское народное творчество, жанры, изучение.

The study of the genres of Tatar folk art falls on the beginning of the last century. Since the beginning of the 20th century articles by G. Yuldashev, G. Rakhim, M. Akchurin, G. Tulumbaysky and other authors about Tatar folk songs, ritual folklore, and epic works have been printed on the pages of magazines. A certain contribution to the development of Tatar folklore was made by the classics of Tatar literature: the poet G. Tukay and the writer G. Ibrahimov, the scholar G. Battal, G. Sagdi, H. Yarmi, N. Isanbet and others.

In this article, the author analyzes the works of folklore researchers studying the genres of Tatar folk art until the mid-20th century. He concludes that until the middle of the 20th century, the study of Tatar folklore genres was in the center of attention. In their works, printed in the form of prefaces to various collections, individual articles, the researchers expounded their views on the types of folk art, created a scientific classification of certain genres, and identified their specific features.

**Key words:** folklore, Tatar folk art, genres, study.

Татар фольклористикасында татар халык иҗаты жанрларын өйрәнү XX йөз башына туры килә. Шагыйрь Г. Тукай һәм язучы Г. Ибраһимов та бу эшкә билгеле бер өлеш кертә.

Г. Тукай «Халык әдәбияты» (1910) лекциясендә ышануларга, мифологик легендаларга, бәетләргә, лирик җырларга туктала. Соңгыларының структурасын һәм поэтикасын, шулай ук фольклор һәм язма әдәбиятның үзара файдалы бәйләнештә булуын җентекле анализлый. Фольклорга билгеләмә бирү, халык иҗаты әсәрләренең социаль функцияләре һәм сыйнфыйлыгы, авторлык проблемалары, эстетик кыйммәтләрне өйрәнү, татар халык җырларының төзелеше

һәм идея юнәлеше турындагы мәсьәләләр беренче мәртәбә Г. Тукай тарафыннан куела [Ярмухаметов, 1957]. Шагыйрьне туган халкының авыз иҗаты, теленең чисталыгы, образларының чынлыгы һәм ышандырырлык булулары, поэтик байлыгы белән җәлеп итә, ул аңарда иң яхшы рухи сыйфатлар хәзинәсен күрә.

Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» хезмәтендә «Халык мөсәннәфәте» бүлеге [Ибраһимов, 1978, б. 23–30] махсус фольклорга багышлана. Г. Ибраһимов та халык авыз иҗатына билгеләмә бирә. Шуның белән бергә ул биш фольклор жанрын бүлеп чыгара: бәетләр, җырлар, әкиятләр, мәкальләр һәм табышмаклар. Әкиятләр жанрына ул шартлы рәвештә риваять-легендаларны, архаик һәм әкияти-мифологик дастаннарны да кертә.

Г. Ибраһимов 1918 елда басылган «Әдәбият кануннары» дигән хезмәтендә (1916 елда «Әдәбият дәресләре» исеме астында нәшер ителә) югарыда әйтелгән мәсьәләләргә туктала. Фольклор әсәрләрен музыкаль, шигъри, прозаик төрләргә бүлә. Кызганыч ки, ул әле дастаннар, йола һәм ышанулар турында язмый. Аның жанрларга бүлү схемасы формасы буенча да, эчтәлеге ягыннан да әлегә бөтен фольклорны колачламый.

Әмма соңрак Г. Ибраһимовның фольклор өлкәсендәге фикерләре шактый үсеш-үзгәреш кичерә һәм 1926 елда ул «Безнең юл» журналында халык әдәбиятына ышану һәм өшкерүләрнең (әфсен-төфсеннәр) дә керүе турында яза [Ибраһимов, 1926].

Г. Батталның 1913 елда басылып чыккан «Нәзарияте әдәбия» хезмәте татар фольклористикасы үсешендә зур роль уйный [Баттал, 1913]. Ул, татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып, фольклор жанрларын эпик, лирик төрләр системасында карый. Аерым алганда, халык җырларын – лирик, тарихи җырларны, риваятьләрне, әкиятләрне һәм героик дастаннарны эпик төр буларак өйрәнә.

«Шура», «Аң» журналларында Г. Юлдашев, Г. Рәхим, М. Акчурин һ. б. авторларның татар халык җырлары, йола фольклоры, эпик әсәрләр турында мәкаләләре басыла. Мәсәлән, Г. Рәхимнең «Халык әдәбиятымызга бер караш» дип исемләнгән мәкаләләрендә [Рәхим, 1914] халык җырларының үзенчәлекләре, аерым алганда структурасы һәм образлар системасы, аларны башкару характеры тәфсилләп бәян ителә.

1930 еллар башында Г. Толымбай фольклорның күләменә һәм күпкырлы характерда булуына игътибар итә, аны өлешләргә бүлеп карый. Башта ул ышанулы өлеш (мифлар, магик ышанулар, йолалар һәм гореф-гадәтләр) турында яза һәм бу өлкәгә караган материалларның күплеген һәм аларны өйрәнү зарурлыгын ассызыклый [Тулумбайский, 1930]. Моның белән килешергә кирәк, чөнки бу төрдәге материаллар белән танышу өчен К. Насыйриның «Казан татарларының ышанулары» («Поверья и приметы казанских татар») хезмәтенә генә дә күз салу җитә.

Г. Толымбай 1933 елда «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән мәкаләсендә татар фольклоры әсәрләренең классификациясен

тәкъдим итә һәм аларны эпик, лирик, драматик төрләргә бүлеп карый [Толымбай, 1933].

Шулай итеп, автор, культура-тарих мәктәбе вәкиле буларак, үз халкының рухи һәм иҗтимагый тормышын исәпкә алып, фольклорны өйрәнүгә системалы рәвештә якын килә.

1934 елда Әминә Халит та бәетләрне тикшерү тәҗрибәсе белән уртаклаша. Шул турыдагы мәкаләсендә ул әкиятләрнең үзенчәлекләренә дә туктала. Аның фикеренчә, фольклорның җыр, әкият, мәкаль, такмак, табышмак кебек жанрлары белән чагыштырганда, бәет үзенең эчтәлеге белән кыйммәтле, чөнки фактик материалга нигезләнеп языла, социаль, сыйнфый көрәш буенча бай материал бирә. Монда без объектка сыйнфый якын килү белән очрашабыз. Бәетләрдә фантазия һәм көчле лирик мотивлар булу аларның чынбарлыктагы вакыйгаларга таянып язылган җыр кебегрәк яңгыраулары, элгәре телдән әйтелүләре ассызыклана, русларның былиналары белән чагыштырыла [Халит, 1934]. Соңрак, бәетләрне тикшерүенең дәвамы булып, Ә. Халитованың «Суга баткан ялчылар» бәете турындагы мәкаләсе языла [Халитова, 1935]. Анда бәеткә тарихи-типологик анализ ясала һәм ахырда әсәрнең тексты да урнаштырыла.

Шулай итеп, автор, татар фольклористикасында беренчеләрдән булып, бәетләргә фәнни характеристика бирергә тырыша, чагыштырма планда милли үзенчәлекләрен күрсәтә, татар фольклорындагы урынын билгели.

Г. Толымбайның 1935 елда басылган «Бәетләр» китабында бәет сүзенең этимологиясе турында сөйләнә, аның борынгыдан кулланылып килүе, ике строфалы шигырь мәгънәсендә йөреп, соңрак халык иҗаты жанры дип атала башлавы турында әйтелә [Урманчеев, 1974, б. 3].

1939 елда Г. Сәгъдинең «Әдәбият теориясе» китабы нәшер ителә. Аның бер өлеше татар фольклоры жанрларына багышлана. Китапның 1941 елда чыккан тулыландырылган басмасында җиденче бүлек тулаем фольклор турында. Анда фольклорга билгеләмә бирелә, жанрлар һәм аларның үзенчәлекләре билгеләнә [Сәгъди, 1939, б. 142].

Шул ук елда Н. Исәнбәтнең «Татар табышмаклары һәм аларны тикшерү» исемле күләмле мәкаләсе басыла [Исәнбәт, 1939]. Әлеге мәкаләдә табышмакларга билгеләмә бирелә, функцияләре, язма әдәбият белән үзара йогынты ясашуы, фольклорның башка жанрлары белән бәйләнеше, халыклар арасында күчүчәнлеге, үзенчәлекләре, җыю һәм өйрәнү тарихы, яңа заман табышмакларының барлыкка килү юллары кебек мәсьәләләр тикшерелә. Әлеге фәнни мәкалә татар табышмакларын өйрәнү-тикшерү юлында алга таба зур адым була.

1940 елда Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты галимнәре «Идегәй» дастанын өйрәнә башлыйлар. Март аенда институтта галимнәр һәм язучылар катнашында «Идегәй» дастанын өйрәнү буенча махсус киңәшмә оештырылып, эпик фондны тулыландыру максат итеп куела һәм, эпосның 500 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан,

инициатив комиссия алдына ТАССР хөкүмәтенә рәсми мөрәҗәгать әзерләү бурычы куела [Хроника..., 1940].

Ф. Урманчеев үзенең «Идегәй» дастанына багышланган монографиясендә аны җыю һәм бастыру тарихына тукталып, 1930 еллар ахыры – 1940 еллар башында төрле татар вариантларын язып алу эшенең интенсив төс алуын, бу өлкәдә Н. Исәнбәт, Х. Ярми һ. б. ның күп эш башкаруларын ассызыклый [Урманчеев, 1999, с. 3–14]. Бу урында фольклорчы Х. Рәхмәтуллинның да хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк [Әхмәтҗанов, 2005].

1940 елларда «Идегәй» эпосына багышланган мәкаләләр басыла [Ярми, 1940; Исәнбәт, 1940], дастанның төрле вариантларына характеристика бирелә һәм ул популярлаштырыла.

Н. Исәнбәтнең «Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы» [Исәнбәт, 1940] мәкаләсе аерым әһәмияткә ия. Анда эпосны фәнни өйрәнү буенча түбәндәге мәсьәләләр куела: эпосның тарихи нигезләре; милли версияләрнең сюжет, мотив һәм сәнгати үзенчәлекләренә чагыштырма-типологик анализ; татар версиясенең җыйнама вариантын төзү принциплары һ. б. [Урманчеев, 1999, с. 9]. Н. Исәнбәт шулай ук «Идегәй» дастанының җыйнама вариантын да эшли һәм 1940 ел ахырында аны «Совет әдәбияты» журналында бастыра [Татар халык дастаны..., 1940]. Ләкин Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшерену институты әлеге вариантка тискәре бәя бирә. Эпосның яңартылган җыйнама китаби вариантын әзерләү өчен, танылган галим һәм язучылардан махсус төркем (Н. Исәнбәт, Х. Ярми, Ш. Маннур) төзелә. Еллар узгач, Ф. Урманчеев әлеге төркем әзерләгән кульязманың дөнья күрүе шул заманның зур казанышы була алыр иде, дип яза [Урманчеев, 1999, с. 10]. «Идегәй» дастанының җыйнама варианты 50 елга якын вакыт узганнан соң гына – 1988 елда басыла [Идегәй, 1988].

«Идегәй» дастаны турында берничә уңай мәкалә дөнья күргәннән соң, 1944 елның 9 августында Үзәк Комитетының әлеге эпосны турыдан-туры гаепләгән карары чыга. Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы уңаеннан «Совет әдәбияты» журналында басылган Н. Исәнбәт мәкаләсе фәнни нигезе булмаган, ялгыш теориягә нигезләнгән хезмәт буларак бәяләнә [Тарихи чынлык..., 1944].

Х. Ярми баштарак эпоска югары бәя бирсә, соңрак татар халык иҗатын өйрәнүдә методологик һәм идеологик хаталар ясалу турында фикер йөртә башлый. Әлбәттә бу Үзәк Комитетның алда телгә алынган, «хаталарны төзәтү юллары» күрсәтелгән карары белән бәйле. Х. Ярми фольклористиканың, «дөрес» юлга басып, зур уңышларга ирешүен билгеләсә дә, репрессиядән котыла алмый. 1944 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры вазифасыннан алына, эпосны өйрәнү берничә дистә елга туктатыла.

Шул ук 1940 елларда эчтәлекле кереш мәкаләләр белән төрле җыентыклар басыла [Мамин, 1940; Исанбет, 1941]. Аларда татар фольклорының төрле жанрларын теоретик яктан өйрәнү юнәлешендә тәүге адымнар ясала.

Арада Н. Исәнбәтнең «Татар халкының балалар фольклоры» җыентыгын ачып җибәргән «Балалар фольклорын өйрәнү һәм аңа классификация» мәкаләсе [Татар халкының..., 1941, б. 3–36] аерым игътибарга лаек. Әлеге мәкалә алты бүлектән тора. Анда нәрсә ул балалар фольклоры, балалар тормышында ул нинди урын алып тора, аны өйрәнүнең әһәмияте нинди кебек сорауларга җавап табарга мөмкин, шулай ук рус һәм татар балалар фольклорларын җыю һәм өйрәнү мәсьәләләре, аның сәнгати үзенчәлекләре, классификациясе карала. Әлеге җыентык, аерым алганда, кереш мәкалә бу өлкәдәге беренче хезмәт булып тора.

1942 елда А. Шамовның халык җырлары турындагы мәкаләсе чыга. Анда халык җырларының сәнгатьчә үзенчәлекләре, композициясе мәсьәләләре күтәрелә һәм күпмедер күләмдә чишелә дә. Һәм алга таба татар халык җырларының бөтен төрләрен фәнни өйрәнү бурычы куела [Шамов, 1942].

Шуннан соң, җырлары һәм көйләре белән беррәттән, халык арасында киң таралган автор җырларын системалаштыру, өйрәнү эше башлана. 1948 елда З. Хәйруллина төзегән «Җырлыйк, иптәшләр» җыентыгы басыла. Анда киң таралган автор җырлары да урын ала. Ләкин халык җырларына урын бик аз бирелә.

Профессор Л. Җәләйнең Х. Ярми һәм А. Шамов тарафыннан төзелгән җыентыкка рецензия рәвешендә язылган мәкаләсе яңа фәнни хезмәт булып тора. Ул халык җырларының эчтәлек һәм форма ягыннан үсеш-үзгәреш кичерүен, структура ягыннан күпстрофалы яңа җырлар барлыкка килүен билгели [Җәләй, 1948].

1949 елда 8 нче сыйныф өчен «Татар әдәбияты» дәреслеге языла. Х. Ярми тарафыннан әзерләнгән «Татар халык иҗаты» бүлегендә халык иҗаты әсәрләре әкият, җыр, бәет кебек жанрларга бүлеп урнаштырыла.

1951 елда «Татар халык иҗаты» антологиясе басылу халык иҗатын фәнни өйрәнүдә тагын бер җитди адым булып тора. Халык иҗаты әсәрләре – жанрларга, алар үз чиратында төрләргә бүленә. Лирик жанрларга автор йола фольклорын, шулай ук җырларның (тарихи җырлардан башка) бөтен төрләрен кертә. Әкиятләр, бәетләр, мифлар, легендалар, тарихи җырлар һәм дастаннар эпик төргә карый. Аерым жанрлар төркемчәләргә бүленә (мәсәлән, фантастик, реалистик, хайваннар турындагы әкиятләр, әкият-мәзәкләр).

Н. Фәттах билгеләгәнчә, автор халык иҗатының аерым жанрлары поэтикасына өлешчә генә кагыла. Халык иҗаты әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше, аларның тел һәм поэтик үзенчәлекләре анализланса, мәкалә тулырак булыр иде, дип саный рецензент. Моңарчы чыккан җыр җыентыклары белән чагыштырганда, төзүчеләрнең совет чоры җырларының дөрес фәнни классификациясен булдыруларын да ассызыклый [Фәттахов, 1951]. «Татар халык иҗаты» җыентыгына Н. Фәттах язган күләмле рецензиядә милли фольклористиканың соңгы казанышлары анализлана, шуның белән бергә бу өлкәдәге җитешсезлекләр дә күрсәтелә.

Шулай итеп, XX гасыр уртасына кадәр татар халык иҗаты жанрларын өйрәнү игътибар үзәгендә була. Тикшеренүчеләр, төрле җыентыкларның керешләрендә, аерым мәкаләләрдә, халык иҗатының жанрлары, аларның төрләре буенча фикер-карашларын белдерәләр, үзенчәлекләрен атыйлар, тематик төркемнәргә бүләләр, аерым жанрларның классификациясен булдыралар.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.* Фольклорчы Хафиз Рәхмәтуллин // Татар иле. 2005. № 23–24.

*Баттал Габделбари.* Нәзарияте әдәбия. Казан. 1913.

*Җәләй Л.* Халык җырлары // Совет әдәбияты. 1948. № 11. Б. 97.

*Ибраһимов Г.* Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы // Безнең юл. 1926. № 5/6. Б. 1–3.

*Ибраһимов Г.* Халык мөсаннәфате // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 23–30.

Идегәй: Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 254 б.

*Исанбет Н.* О детском фольклоре. Казань, 1941.

*Исәнбәт Н.* Татар табышмаклары һәм аларны тикшерү // Совет әдәбияты. 1939. № 10/11. Б. 162–176.

*Исәнбәт Н.* Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 72–92.

*Мамин М.* Пословицы и поговорки. Казань, 1940.

*Рәхим Г.* Халык әдәбиятымызга бер караш // Аң. 1914. № 14. Б. 263–265; № 16–17. Б. 310–313; № 19. Б. 347–351; № 20. Б. 368–371; № 22. Б. 398–401.

*Сәгъди Г.* Әдәбият теориясе. Казан: Татгосиздат, 1939.

Тарихи чынлык өчен // Совет әдәбияты. 1944. № 10. Б. 3–8.

Татар халкының балалар фольклоры / җыючы, төзүче, кереш мәкалә авторы Нәкый Исәнбәт. Казан: Татгосиздат, 1941.

Татар халык дастаны «Идегәй» // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 39–76; № 12. Б. 34–82.

*Толымбай Г.* Татар фольклоры фронтында // Совет әдәбияты. 1933. № 4/5. Б. 112.

*Тулумбайский Г.* Татар фольклоры // Татарстан. 1930. № 6/7.

*Урманчеев Ф.* Халык авазы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Урманчеев Ф.И.* Народный эпос «Идегәй». Казань, 1999.

*Фәттахов Н.* Татар халык иҗаты җыентыгы // Совет әдәбияты. 1951. № 10. Б. 119.

*Халит Әминә.* Бәетләр тикшерү тәҗрибәсеннән // Совет әдәбияты. 1934. № 6. Б. 56–59.

*Халитова Әминә.* «Суга баткан ялчылар» бәете турында // Совет әдәбияты. 1935. № 4/5. Б. 116–119.

Хроника. «Идегәй» дастанын өйрәнү // Совет әдәбияты. 1940. № 3. Б. 97.

*Шамов А.* Халык җырлары турында // Совет әдәбияты. 1942. № 6. Б. 76–78.

*Ярми Х.* «Идегәй» дастаны // Совет әдәбияты. 1940. № 5/6. Б. 163–178.

*Ярмухаметов Х.* Татарская советская фольклористика за 40 лет // Известия Казанского филиала АН СССР. 1957. Юбилейный сборник. С. 174.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

УДК 398

***И.К. Фазлетдинов***

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТОПОНИМИК РИВАЯТЬЛӘРЕНДӘ ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАРЫНДА ӘҮЛИЯ ҺӘМ ӘҮЛИЯ КАБЕРЛӘРЕНӘ БӘЙЛЕ МОТИВЛАР

В данной статье автор, основываясь на обширном материале преданий и легенд татарского населения Республики Башкортостан, анализирует отражение в них мифологических мотивов, в частности, отражения в фольклоре антропоморфических, тотемистических, анимистических, фетишистических взглядов древнего населения региона, связанных с образами носителей дара провидения, предсказателей и местами их захоронений. Исследователь проводит сравнительно-исторический анализ таких мотивов в татарском и башкирском фольклоре, выделяя национальное своеобразие в образном мышлении каждого из народов, что обуславливается особенностями их исторического и культурного развития.

По мнению автора, индикатором «святости» провидца в топонимических преданиях татар Башкортостана выступает его ранняя и трагическая смерть, связанная с нахождением его на религиозном пути или на пути получения образования. В результате этого на могиле провидца пробивается родник, также обладающий провидческими качествами; прекращаются беды, преследовавшие до сих пор местное население, и народ заживает счастливо.

Как указывает исследователь, в данных преданиях прослеживается тесный синтез исламских воззрений народа с языческими верованиями, что может служить свидетельством возникновения данных мотивов в эпоху перехода от тенгриянства к мусульманству.

**Ключевые слова:** провидцы, святость, предание, легенда, этиологический мотив, родник, язычество, ислам, фольклор.

This article is based on the extensive material of the legends of the Tatar population of the Republic of Bashkortostan. The author analyzes reflection in legends of mythological motives, in particular, reflections in folklore of anthropomorphic, totemistic, animistic, fetishistic views of the ancient population of the region associated with the images of the bearers of the gift of providence, predictors and their burial sites. The researcher conducts a comparative historical analysis of such motives in Tatar and Bashkir folklore, highlighting the national originality in the figurative thinking of each nation, which is caused by the peculiarities of their historical and cultural development.

According to the author, an indicator of the «holiness» of the seer in the toponymic legends of the Tatars of Bashkortostan is his early and tragic death associated with finding him on a religious path or on the path of education. As a result of this, a spring breaks through the grave of the seer, also having visionary qualities; the misfortunes that still persecuted the local population cease, and the people live happily.

As the researcher points out, in these legends there is a close synthesis of the Islamic views of the people with pagan beliefs, which may serve as evidence of the emergence of these motives in the era of the transition from Tengryanism to Islam.

**Keywords:** seers, holiness, tradition, legend, etiological motive, spring, paganism, Islam, folklore.

Башкортстан татарларының әкият жанрына карамаган халык прозасы әсәрләре арасында топонимик риваятьләр һәм легендалар зур урын алып торалар. Җыелган материаллардан күренүенчә, сан ягыннан алар күнкүреш һәм тарихи риваятьләрдән күпкә артык. Чөнки һәр авылның аксакаллары якындагы җир-су, урман-тау атамаларының барлыкка килүе турында сөйләгәндә, аларны табигатьтәге, җәмгыятьтәге төрле хәл-вакыйгаларга, аерым фактларга бәйләп аңлатырга, димәк, халык аңында мәңгеләштерергә тырышалар.

Фольклорчы-галим Ф.А. Нәдершина билгеләвенчә, «күпчелек очракта риваятьләр, локаль характерда булып, теге яки бу урынга, җир-су атамаларына бәйле яшиләр, я аерым төбәкләргә бәйле хәл-вакыйгаларны, күренешләрне чагылдырып, шул төбәктә аеруча билгеле булып китәләр» [Башҡорт, 1980, б.14]. Ягъни топонимик риваятьнең таралу географиясе артык зур түгел, ул шушы табигать объекты – елга, тау, чокыр һ. б. янына урнашкан халыкта гына урын атамасының аңлатмасы буларак яшәвен дәвам итә. С.М. Гыйләҗетдинов та шушы фикерне раслап, «халык аларда (топонимик риваятьләрдә. – *И.Ф.*) авыл, урман, кыр, тау, елга, чишмә һ. б. географик объект исемнәренең килеп чыгышын аңлатырга тырыша», дип яза [Гилязутдинов, 2000, с. 13]. Ягъни барлык топонимик легендаларга һәм риваятьләргә дә этиология сыйфаты хас.

Күренекле фольклорчы Ә.М. Сөләйманов, башкорт легендаларын һәм риваятьләрен анализлап, Архангель, Зилаер районнарындагы алпамша каберләрен икенче төрле Әүлия кабере, Әүлия ташы дип йөртүләре турында яза [Сөләйманов, 1975, б. 111]. Башкортстанда татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә дә Әүлия кабере, Әүлия чишмәсе, Әүлия зираты, Изгеләр чишмәсе дип аталган урыннар шактый. Аларның һәммәсенең барлыкка килү тарихы бар. Ләкин берсендә дә атаманың килеп чыгышын алпамшалар кабере белән бәйләү күренми. Бу үз чиратында татарларның монда соңрак, алыпларга бәйле күзаллаулар халык аңыннан югалгач килеп төпләнүенә бер дәлил булып тора.

«Әүлия» дип татар һәм башкорт халыкларында укымышлы, халыкка төрле изгелекләр кылган, киләчәк турында күрәзәлек итү сәләтенә ия булган кешеләрне атаганнар. Башкортстанның төньяк-көнбатышында табылган легенда һәм риваятьләрнең берсендә дә алар ислам динен таратучы, пропагандалаучы сыйфатында тасвирланмый, киресенчә бу әсәрләрдә мәҗүсилек калдыклары да искә алынырга мөмкин. Шуңа күрә, Ә.М. Сөләймановның «Әүлия зиратына ышану нигезендә туган легендалар ислам дине башкортлар арасында таралгач кына барлыкка килгән» [Сөләйманов, 1975, б. 111], дигән фикере белән килешеп бетмәскә дә була, чөнки әүлия образы халык авыз иҗатында, беренче чиратта, гайре табигый, гади акыл белән аңлатып булмаслык сәләтләргә ия изге кешене гәүдәләндерә. Ул ислам динен тотучы, таратучы буларак чыгыш ясамый. Бу образның генетик тамырларын тирәннәнрәк эзләргә кирәк. Шул ук вакытта, Ә.М. Сөләйманов

бик хаклы билгеләгәнчә, «алар [әүлияләр. – *И.Ф.*], үлгәч тә, төрле могҗизалар эшләү кодрәтен югалтмыйлар» [Сөләйманов, 1975, б. 111].

Әүлия кабере турындагы легенда һәм риваятьләрнең күбесендә бу урында бик изге кешенең күмелүе күрсәтелә. Аның изгелеген, әүлияны күмгәннән соң, аның баш очыннан бәреп чыккан чишмә, яисә гади таяктан үсеп киткән агач исбатлый. Ул гына да түгел, күмелгән кеше, аның тормышы, холык-фигыле бу урында яшәүчеләргә бөтенләй таныш булмаса да, шушы могҗизалы вакыйгалар аны әүлияләр дәрәҗәсенә күтәрә. Мәсәлән, Бакалы районы Бакалы авылында язып алынган «Әүлия чишмәсе» риваятендә «кышкы салкын буранда... адашып, туңып үлгән» «нибары 17 яшьлек» егетне «яз көне эзләп табып, тау башына» күмү һәм «күп тә үтми, кабердән салкын чишмә» бәреп чыгу вакыйгасы тасвирлана. «Егет изге булгандыр», дип уйлап, халык тауга да, чишмәгә дә Әүлия исемен биргән», – дип аңлатыла риваятьтә атаманың барлыкка килүе [Башкортстан, 2018, б. 233]. Күренүенчә, үрнәктә егетнең үз тормышында кылган изгелекләре, хәтта исеме турында бер мәгълүмат та китерелми. Аның изгелеген бары тик егетнең каберennән бәреп чыккан чишмә генә күрсәтә, ягъни ул халык аңында могҗиза буларак кабул ителә. Борынгылар «егетнең гомере чишмәдә дәвам итә», – дип уйлыйлар. Кешеләр бу табигать күренешенең чын сәбәпләрен эзләп тормыйча, аны егетнең изге булуы белән генә аңлаталар. Шуны раслаучы тагын бер дәлил – риваятьтә егетнең гыйлем юлында яшьли һәлак булуы. Белүебезчә, татарлар һәм башкортлар гыйлемле кешеләрне борын-борыннан изгеләштереп караганнар. Ә инде егетнең күрше «Кизгән авылына» укырга барганда һәлак булуы бу карашның тагын да көчәюенә, халык аңында аның изге зат, шәһит буларак яшәвенә китергән. Димәк, риваятьтә без, бер яктан, мәҗүси карашлар тәэсирен, егет гомеренең дәвамы чишмәдә дип исәпләүне, шул рәвешле халык аңында җансыз әйберне җанландырып кабул итү функциясен күрәбез. Икенче яктан, риваятьтә ислам дине белән кергән карашларны да, гыйлем юлында, дин юлында һәлак булучыны изгеләштереп, шәһит дип санауны да тоемларга мөмкин. Шулай итеп, бу риваять ислам дине халык аңындагы мәҗүси карашларны акрынлап кысрыклап чыгарган чорда иҗат ителгәндер дип фаразларга тулы нигез бар, чөнки биредә ислам кыйммәтләре мәҗүси фикер йөртү рәвеше аша аңлатыла. Бу парадоксаль күренеш мәҗүсилектән исламга күчү дәверендә гадәти булгандыр дип уйларга мөмкин, чөнки әлеге процесс халык аңында гасырлар буена барган. Ислам кануннары буенча яшәсәләр дә, борынгы бабаларыбыз күңелендә мәҗүсилек калдыклары әле бик озак яшәгән. Югарыда китерелгән үрнәкне нәкъ шуның чагылышы дип исәпләргә кирәк.

Шушы ук мотив Кыйгы районы Майски авылында язып алынган «Муел зират» исемле риваятьтә дә кабатлана. Биредә «Троицк каласыннан укудан кайтып барган» бер шәкертнең Түбән Кыйгы авылында үлеп калуы һәм «чит кеше булганлыктан, аны бер як читкә» күмүләре тасвирлана. «Кабер казучыларның берсе: «Әгәр изге кеше

булса, үсеп китәр», – дип, кабер өстенә муел таягын казый. Бу таяктан, чынлап та, муел үсеп китә. Кабер «Муел зираты» исемен ала», дип аңлатыла риваятьтә атаманың килеп чыгышы [Башкортстан, 2018, б. 234–235]. Күренүенчә, әлеге үрнәк тә тулысынча диярлек югарыда анализланган «Әүлия тавы, Әүлия зираты» риваятен кабатлый. Аерма тик шунда, биредә мәрхүмнең кабере өстендә шомырт куагы үсеп чыгу вакыйгасы аның изгелеген раслаучы дәлил булып хезмәт итә. Димәк, кабер өстеннән чишмә бәреп чыгу, коры таяктан агач үсеп китү халык аңында могҗиза сыйфатында кабул ителә һәм күмелгән кешенең изгелеген раслаучы үзенә күрә бер индикатор булып тора. Мәсәлән, Тәтешле районы Акбулат авылында язып алынган «Фәттах чишмәсе» исемле риваятьтә бу хакта турыдан-туры әйтелә. Биредә чишмәнең авылда икенче атама белән «Изгеләр чишмәсе» дип тә йөртелүе күрсәтелә һәм шунда ук моның сәбәпләре дә ачып салына. «Фәттах бабай изге булмаса, ул җирләнгән урыннан чишмә күзе бәреп чыкмас иде», – ди халык [Башкортстан, 2018, б. 235]. Ягъни кабер өстеннән чишмә бәреп чыгу халык аңында әлеге картның изгелеген тагын бер тапкыр дәлилләүче төп күрсәткеч – индикатор вазифасын башкара һәм халык шушы аңлатманы турыдан-туры риваять тукымасына алып керә.

Югарыда китерелгән риваятьләрдә борынгы су, агач культы чагылышын да сиземләргә мөмкин. Һәлак булган изге затның гомере шушы чишмәдә, куакта дәвам итә һәм алар яннарында күмелгән кеше кебек үк илаһи сыйфатларга ия дип ышаныла. Шулай итеп, биредә кешеләргә хас сыйфатлар җансыз табигать күренешләренә күчерелә һәм, шул рәвешле, антропоморфик карашлар чагылыш таба.

Кабер өстеннән чишмә бәреп чыгу «Әүлия чишмәсе», «Фәттах чишмәсе» исемле үрнәкләрдә халык ихтыяҗы белән бәйләнмәгән, күмелгән кешенең изгелеген дәлилләүче бер материаль күрсәткеч сыйфатында чыгыш ясаса, Чишмә районы Яңавыл авылында язып алынган «Изгеләр чишмәсе» риваятендә бу мотив кешеләрнең дистәләрчә еллар буена килгән хыялының тормышка ашуы булып транформацияләшә. Биредә беркем белмәгән, үткенче бер изге кешенең халык бәхете өчен үзен корбан итү мотивы ачык чагыла. Әлеге үрнәктә авыл халкының сусызлыктан интегүе тасвирлана. «Көннәрдән бер көнне авылга мосафир килеп чыга. Халык бу кешенең тамагын туйдыра, хәтта өс киемен дә бирә. Бабай хушлашканда:

– Ярар, сезнең теләгегез тормышка ашар, – дип чыгып китә. Икенче көнне авыл читендәге таучык өстендә мосафир бабайны үле килеш табалар. Бабай яткан урыннан чак кына астарак, кечкенә бер чишмә бәреп чыккан була. Бабайны халык кадерләп күмә һәм чишмәне «Изге чишмә» дип атый башлый» [Башкортстан, 2018, б. 234].

Күренүенчә, биредә изге зат үлгән урыннан чишмә бәреп чыгу кешеләрнең иң зур хыялының тормышка ашуы буларак аңлашыла. Мосафир, вәгъдәсендә торып, үз гомерен халык бәхете – аларны сулы итү өчен корбанга китерә һәм аның җаны чишмәдә яшәвен дәвам

итә. Ягъни биредә янә мәҗүсилек чорларына хас антропоморфик карашлар дини мотивлар белән үреп бирелә. Мосафир бабай да гади персонаж түгел. Риваятьтә ул югары көчләр тарафыннан әлеге авылга җибәрелгән илче сыйфатында тасвирлана. Җирле халыкның нинди булуын, аларның чишмәгә лаекмы-түгелме икәнлеген аңлар өчен, ул бу кешеләрне сынап карый. Ә инде борынгы бабаларыбызның, саф күңелле икәнлекләрен аңлагач, ул изгелеккә-изгелек белән җавап кайтара – аларны чишмәле итә. Шулай итеп, биредә халкыбызның кунакчыллыкны, кеше хәленә керә белүне иң югары әхлак категорияләре дәрәҗәсенә күтәрүе ачык чагыла.

Изге кешеләрнең, әүлияларның гомере кабер өстеннән бәреп чыккан чишмәләрдә дәвам итү мотивы күп легендаларда һәм риваятьләрдә очрый. Бу чишмәләр алар астында күмелгән әүлиялар кебек үк төрле могҗизалар эшләү сәләтенә ия – алар күрәзәлек кыла, шифалы сулары белән кешеләрне дәвалый, төрле табигать стихияләрен булдырмый калырга ярдәм итә. Мәсәлән, «Әүлия чишмәсе» риваятьләренең Туймазы районы Карамалы-Гобәй һәм Борай районы Кәшкәләү авылында язып алынган вариантларында чишмәнең алдагы елның нинди булачагын прогнозлау сәләтенә ия булганлыгы турында хәбәр ителә [Башкортстан, 2018, б. 233–234]. Язын чишмәдән су күп чыкса – ел уңдырышлы килә, саркып кына торса – уңышсыз була. Аеруча зур корылык көтелсә, чишмә бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Күренүенчә, биредә ниндидер дини, яисә мифологик күзаллаулар түгел, ә тормыш зарурияте алгы планга чыга. Чишмәнең мондый «алдан күрү» сәләтен бүген, табигать законнарына таянып, җиңел аңлатып була. Ләкин элек халык мондый мәгълүматларга ия булмаган һәм чишмәнең һава торышын прогнозлавын могҗиза сыйфатында кабул иткән һәм, аны изгеләштереп, суга хәер-акча салган.

Әүлия кабере, Изгеләр чишмәләренең халыкны төрле табигать стихияләреннән саклап калу мотивы шулай ук күп кенә легенда һәм риваятьләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, Илеш районы Иске Күктау авылында язып алынган «Әүлия кабере» исемле риваятьтә авылда элек бик еш янгын чыгып, бик күп кешеләр үлү, шуларның берсендә тылсым сәләтенә ия әүлия кызның да һәлак булуы хәбәр ителә. «Аның гәүдәсен, хөрмәтләп, авыл читендәге яр башында торган тау битенә күмәләр. Шуннан соң авылда янгын чыгулар туктый. Хәзер авылны ут-күздән Әүлия кабере саклый»,– дип әйтелә риваятьтә [Башкортстан, 2018, б. 232]. Шулай итеп, якташлары аңында әүлия халык бәхете, халык иминлеге өчен гомерен корбан иткән идеаль герой дәрәҗәсенә күтәрелә. Риваятьтә профилактик магия чагылышын да күрергә мөмкин. Язучы һәм мифология белгече Г. Гыйльманов билгеләвенчә, борынгы бабаларыбыз утны җанлы зат итеп караганнар, аны Күк оныгы, Кояш улы, Яшен туганы дип белгәннәр, аңардан курыкканнар. Казан татарлары, керәшеннәр, чувашлар, ут алиһәсенә атап, корбан чалганнар, корбан бирсәң, мәрхәмәтле булыр дип уйлаганнар [Татар мифлары, 1996, б. 72–75]. Югарыда китерелгән рива-

ятьтә дә без шушы карашларның чагылышын күрә алабыз. Риваятьтә ислам диненнән бигрәк мәҗүсилек калдыклары – ут иясенә табыну, аңа корбан китерү кебек йолаларның чагылышы ныграк сизелә. Бу исә үзе үк әүлияларга бәйле мотивларны бары тик ислам дине йогынтысына гына кайтарып калдыруның дөреслеккә туры килеп бетмәвен күрсәтә.

Шунысы кызык, әүлия каберләре турындагы башка үрнәкләрдән аермалы буларак, әлеге риваятьтә кыз күмелгән җирдән чишмә бәреп чыгу, коры таяктан агач үсеп китү кебек «могҗиза»лар тасвирланмый, ягъни әүлиялылыкның материаль күрсәткечләре юк дәрәҗәсендә. Халык аңында авылда кызның үлеменнән соң янгын чыгуларның туктавы үзе үк зур могҗиза, кызның әүлия булганлыгына иң төп дәлил сыйфатында чыгыш ясый.

Ә инде Балтач районы Әхмәт авылында язып алынган «Изгеләр чишмәсе» исемле риваятьтә «бик изге кеше» кабереннән бәреп чыккан чишмәнең Кояшны «җеннәр»дән коткаруы тасвирлана. «1882 елда безнең якта Кояш тотыла. Халык: «Кояшны җеннәр каплап алды», – дип, урак уруларын ташлап, мәчеткә җыелалар: намаз укып, теләкләр телиләр, җеннәрне куркытыр өчен тимергә-тимер сугалар. Ә аннан соң, Изгеләр чишмәсенә җыелып, хәер салалар. Аларның теләкләре кабул була. Җеннәр Кояшны «азат» итәләр», – дип хәбәр ителә әлеге үрнәктә [Башкортстан, 2018, б. 234].

Күренүенчә, биредә чишмәне изгеләштереп, әүлияга хас сыйфатларны аңа күчереп карау мотивы, ягъни халыкның борынгы антропоморфик карашлары ачык чагылыш таба. Кояш тотылу күренешенә фәнни аңлатма бирә алмаган халык аны «җеннәр каплап алды», дип, ярдәмне әүлия гомеренең дәвамчысы, изге дип саналган чишмәдән эзли, аңа хәер-сәдака бирә. Кояш тотылу вакытының тәмамлануы исә чишмәнең «изге»леген борынгы бабаларыбыз аңында тагын да арттыруга хезмәт итә. Риваятьтә мәҗүси су, тимер культын да ачык сиземләргә була.

Әүлия каберләрен халык бик кадерләп, хөрмәтләп тота. Алар янына бүтән беркем дә күмелми. Биредә сызгырып, кычкырып йөрергә ярамый, юкса әүлия үч алырга мөмкин. Бу тыюлар Краснокама районы Яңа Бөртек авылында язып алынган «Әүлия зираты» исемле риваятьтә аеруча ачык итеп тасвирлана. Биредә әүлия күмелгән наратлыктан агач кисеп алуның катгый тыелуы, бу тыюны бозган кешенең «төрле газапларга дучар булган»лыгы турында хәбәр ителә. «Шуңа да кайберәүләр: «Миңа түгел, фәлән кешегә дип атап кискәннәр», – дип әйтелә әлеге үрнәктә.

«Берчак кемдер муллага атап кискән. Шул ук көнне Әбелкарам исемле мулла сакау булып калган. Ә аның кызы гариплләнгән. Бу хәл турында ишеткәч, кешеләр ул наратлыкка бөтенләй тими башлаганнар. Шулай итеп, наратлык әлегә кадәр сакланган һәм «Әүлия зираты» исемен йөртә» [Башкортстан, 2018, б. 232]. Әлеге риваятьтә тасвирланган табу-тыюлар үзләренең генетик тамырлары белән ерак тәү

тормыш чорларына килеп тоташа. Билгеле булуынча, кешелек яңа барлыкка килгән вакытта төрле мәҗүси йолалар махсус билгеләнгән урыннарда – куе караңгы урман эчендәге аланда, биек тау башында һ. б. күздән ерак җирләрдә үткәрелгән. Йола башкарылган урын изге саналган һәм аңа гади кешеләргә аяк басарга ярамаган. Бу тыю бозылса, ияләрнең ачуы килеп, ыру-кабиләне коточкыч җәзалар көтә дип ышанганнар [Криничная, 1987, б. 168]. Әлеге риваятьтә Әүлия зираты да нәкъ шушы изге, табу урын сыйфатында чыгыш ясый һәм аның тынычлыгын бозу шулай ук төрле казаларга китерә. Шуны да әйтик, риваятьләрдән күренгәнчә, әүлия зиратлары элек-электән, мәрхәмәт сорап, югары көчләргә – Кояш, Яңгыр тәңреләренә корбан китерү өчен файдаланыла. Ягъни борынгы йола урыннарының һәм әүлия зиратларының функцияләре бер үк булып чыга. Шуңа күрә борынгы мәҗүси йола урыннарына бәйле ышанулар соңгырак дәвердә барлыкка килгән әүлия зиратларына, әүлия каберләренә күчереләһәм бу легенда-риваятьләрдә дә чагылыш таба.

Шулай итеп, әүлия каберләре турындагы легендалар һәм риваятьләр үзләрендә ике башлангычны – ислам диненә бәйле карашларны һәм мәҗүси ышануларны берләштерә. Беренче карашка парадокс булып тоелган әлеге күренешне Башкортстан татарларының халык авыз иҗатын җыюга һәм өйрәнүгә зур өлеш керткән фольклорчы галим Р.М. Мөхәмм әтҗанов бик дөрес аңлата: «Кама-Идел буе болгарларына ислам дине кергән вакытта (X–XII йөзләр) мәҗүсилек аларның төп дини идеологияләре була. Ислам дине баштагы мәлдә мәҗүсилек гадәтләренә каршы көрәшә әле. Элекке йолалар үтәлә торган «изге» җирләр урынына, әйтик, мәчетләр салына; мәҗүси аллалар урынын – әүлиялар, пәйгамбәрләр ала; йолаларны үтәгәндә башкарыла торган иҗатны – дини догалар, аятьләр, хәдисләр, сүрәләр һәм башка шуның кебек нәрсәләр алыштыра. Ләкин халыкның канына сеңгән гадәтләр югалмый. Дин әһелләре бу көрәшнең мәгънәсезлегенә төшенә башлый. Инде хәзер ислам дине төрле мифларны һәм мәҗүсилек вакытыннан калган ышануларны «үзләштерә», ягъни аларга дини эчтәлек сала» [Мөхәммәтҗанов, 1971, б. 31]. Әүлия каберләре турындагы риваять-легендаларда мәҗүси һәм ислам диненә бәйле карашларның бергә укмашып яшәвен нәкъ шуның белән аңлатырга кирәк.

**Әдәбият**

Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башҡорт халыҡ ижады. Риүәйәттәр, легендалар / төҙөүсеһе, инеш мәҡәлә һәм аңлатмалар авторы Фәнүзә Нәҙершина; яуаплы редакторы Кирәй Мәргән. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1980. 414 б.

*Гилязутдинов С.М.* Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 32 с.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Йола поэзиясе // Татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы мәсьәләләре. Уфа: БДУ нәшрияты, 1971. Б. 30–42.

*Сөләймәнов Ә.М.* Боронғо топонимик легендалар һәм риүәйәттәр // Әҙәбиәт. Фольклор. Әҙәби мираҫ: Беренсе китап / яуаплы редакторы Кирәй Мәргән. Өфө: БДУ нәшриәте, 1975. Б. 103–126.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 388 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты: югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / фәнни мөхәррире Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Мәгариф, 2002. 335 б.

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе кафедрасы доценты (Уфа)*

УДК 94(47).03

***Ф.Ш. Хуҗин***

# УРТА ГАСЫРЛАР ЕВРОПА ТАРИХЫНДА БОЛГАРЛАР

В статье на основе преимущественно археологических материалов, а также письменных источников и лингвистических (топонимических) данных сделана попытка выявить объективную картину участия болгар VII–XIII вв. в исторических событиях и этногенетических процессах народов Восточной и Западной Европы. По мнению автора, они оставили заметный след в культуре ряда народов, говорящих сегодня на тюркских, славянских, финно-угорских, иранских и романских языках.

**Ключевые слова:** археология, болгары VII–XIII вв., территория их расселения, этнические процессы, наследие.

In the article an attempt was made to reveal an objective picture of the participation of Bulgars of the 7th – 13th centuries in historical events and ethnogenetic processes of the peoples of Eastern and Western Europe. Analysis is made on the basis of archaeological materials, as well as written sources and linguistic (toponymic) data. According to the author, they have left a significant mark in the culture of a number of peoples who nowadays speak Turkic, Slavic, Finno-Ugric, Iranian and Romance languages.

**Keywords:** archeology, Bulgars of the 7th – 13th centuries, territory of Bulgars' settlement, ethnic processes, heritage.

Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа халыклары тарихында, бигрәк тә аларның килеп чыгышында, матди һәм рухи культуралары формалашу процессында Урта гасырлар чоры болгарларының ролен анықлау мәсьләләсе галимнәрнең игътибарын әледән-әле җәлеп итеп торды. Әле кайчан гына тарих фәнендә болгарларны хәзерге Идел-Урал татарларының бердәнбер борынгы бабалары дип карау өстенлек итә иде. Дөрес, башка компонентлар да кире кагылмады, әмма Алтын Урда чорында барлыкка килгән тирән этник үзгәрешләр исәпкә алынмады. 1980 еллар ахырында башланып киткән фәнни бәхәсләрдә Идел болгарларының татар этногенезындагы роле бик нык киметеп күрсәтелде, хәтта бөтенләй инкяр ителде дияргә мөмкин. Кайбер мөхтәрәм галимнәребез Медисон (АКШ) университеты профессоры Юлай Шамилоглу хезмәтләрендә әйтелгән фикергә [Shamiloglu, 1991, p. 157–163] ияреп, болгарларның күп өлеше монгол-татар яуларында үлеп беткән, калганнары XIV йөз урталарында бөтен Европага таралган чума пандемиясендә юкка чыккан, дип яздылар [Әхмәтҗанов, 1997]. Тик нишләп соң ул чумада болгарлар гына үлеп беткән, ә аларның мәҗүси күршеләре, бигрәк тә чума котырынган Сарай халкына якынрак торган кыпчаклар, мордвалар һәм башка халыклар исән калган?

Болгар бабаларыбызны монгол яулары нәтиҗәсендә күчеп утырган, сан ягыннан күпчелекне тәшкил иткән татарлар арасында «эреп»

беткән, ягъни ассимиляцияләнгән бер халык итеп караудан «болгарчы» галимнәрнең кире кага алмаслык дәлилләре генә саклап калды.

Соңгы елларда тарихчылар, татар халкының бердәм этник тамыры юк, аның озак гасырларга сузылган этнос буларак оешу процессында һуннар, болгарлар, кыпчаклар һәм нугайлар кебек күчмә дала халыклары да, күрше фин-угорлар һәм славян-руслар кебек утрак тормышта яшәүче урман һәм урман-дала халыклары да катнашкан, дигән уртак фикергә килделәр [История татар..., 2002, с. 5–6]. Бу, нигездә, дөрес фикер, әмма югарыда саналган этник компонентлар татарларның төрле этнографик төркемнәрен барлыкка китерүдә бердәй катнашмаганнар (кыпчак компоненты, мәсәлән – мишәрләрдә, болгар компоненты – Урта Идел татарларында, җирле фин компоненты керәшеннәрдә ачыграк сизелә).

Болгар мирасы турында сүз барганда, әлбәттә, тугандаш чуваш халкының килеп чыгышына караган мәсьәләләрне дә читләтеп үтәргә ярамый. Бүгенге көндә Чувашстан галимнәре арасында әле XX йөз башларында ук Н.И. Ашмарин тарафыннан тәкъдим ителгән болгар-чуваш тәңгәллеге теориясе өстенлек итә [Ашмарин, 1902; Димитриев, 2004]. Татарлар – безнең якларга 1236 елда килеп төпләнгән монгол-татар калдыклары, имеш; димәк, аларның болгар мирасына дәгъва кылырга хаклары юк булып чыга. Соңгы елларда көндәлек матбугат битләрендә генә түгел, хәтта фәнни хезмәтләрдә дә, чувашларның исемен «сувар-болгар»га алыштырырга кирәк, дигән катгый таләпләр яңгырый башлады. «Чуваш» дигән «аһәңсез социаль этноним XVI гасырдан башлап системалы рәвештә геноцид кичергән сувар-болгар халкына карата патша чиновниклары тарафыннан аңлы рәвештә кимсетелеп кулланылган» янәсе [Ювенальев, 2012, с. 293].

Башкорт тарих фәнендә, бигрәк тә археологиядә, болгар мирасына бәйле проблемалар чагыштырмача күптән түгел, әмма шактый кискен формада калкып чыкты. Башкорт галимнәре раславынча, республиканың татарлар – «башкортларның төньяк-көнбатыш этнографик төркеме» – яши торган төбәкләре Идел Болгарының аерылмас бер өлешен тәшкил иткән. Урта гасырлар чорына караган «башкорт шәһәрләре» исемлегенә алар Чаллы һәм Алабуганы гына түгел, хәтта борынгы рус елъязмаларында «Олуг шәһәр» исеме белән аталган Биләрне дә кертәләр. XII гасыр ахырында – XIII гасырның беренче яртысында иҗат иткән мәшһүр шагыйрь һәм фикер иясе, «Кыйссаи Йосыф» поэмасы авторы Кол Гали, «Болгар тарихы»н язган хокук белгече (кади) Ягъкуб бине Ногман башкорт кавеменнән чыккан шәхесләр дип игълан ителә [Мажитов, Султанова, 2010, с. 327–328; Мажитов, 2013, с. 100–102].

Археология, язма чыганакларга, антропология, этнография, лингвистика кебек гуманитар фәннәр тарафыннан тупланган материалларга нигезләнеп, Урта гасырлар болгарларының хәзерге халыклар тарихына һәм мәдәниятенә керткән өлеше турындагы бәхәсле проблемаларга шактый дәрәҗәдә ачыклык кертә ала.

Сүзне болгарларның Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европада таралып утырган, тереклек кылган җирләрен билгеләүдән башлыйк. Болгар кабиләләре турында иң борынгы хәбәрләр теркәлгән ышанычлы чыганаклар V гасырга карый [Сиротенко, 1961, с. 47]. Заманында көнчыгыш тарафтан һуннар урдасы белән күченеп килгән болгарлар Азов һәм Кара диңгез буйларында, Төньяк Кавказ далаларында төпләнеп калганнар, башлыча күчмә тормыш алып барганнар. Тиздән Көнбатыш Европадагы хәрби-сәяси вакыйгаларда актив катнаша башлаганнар – Византия императоры аларны, союздашлар һәм хәрби ялчылар сыйфатында, үзенең дошманнарына каршы көрәштә файдаланган. Әле 475 елда ук болгарлар, Византия чикләренә китеп барышлый, Дунай буйларына килеп чыкканнар [Сиротенко, 1972, с. 202].

Азов һәм Төньяк Кара диңгез далаларында көн күргән төрки кабиләләр VII гасырда Кубрат хан идарәсендәге Бөек Болгар дәүләте составына керәләр. Кубрат болгарлары калдырган археология һәйкәлләре башлыча аерым каберлекләрдән һәм әйбер хәзинәләреннән гыйбарәт. Дәүләтнең башкаласы – антик чордан калган Фанагория, дип фаразлана [Рашев, 2004; Комар, 2006; Комар, Кубышев, Орлов, 2006]. 660 елларда хәзәрләр тарафыннан җиңелеп, Бөек Болгар дәүләте таркалганнан соң, халыкның бер өлеше – Дунай якларына, ә икенче өлеше Урта Иделгә күчеп китә (биредә алар үзләренең мөстәкыйль дәүләтләрен төзиләр). Калганнары исә, «җирле» болгарлар, Хәзәр каганаты составында яшәүләрен дәвам итәләр, әкренләп күрше төбәкләргә дә үтеп керәләр – алар калдырган археология һәйкәлләре Кырымда һәм Төньяк Кавказда күп таралган. VIII–IX гасырларда яшәгән болгарларның археологик эзләре (керамика, сугыш кораллары, ат дирбияләре, бизәнү әйберләре) хәзерге Украина, Молдавия, Румыния һәм Венгрия территорияләрендә дә күпләп табыла [Die Keramik..., 1990]. Бу җирләргә алар Хәзәр каганатыннан һәм Дунай Болгариясеннән таралып утырганнар.

Идел Болгарстанының монголларга кадәрге чикләре бүгенге көнгә кадәр сакланган 2 меңгә якын археология һәйкәлләрен картага төшерү (картографияләү) нигезендә шактый төгәл ачыкланган [Фахрутдинов, 1975]. Ул һәйкәлләрнең күбесе, шул исәптән, тарихи исемнәре билгеле булган шәһәрләр (Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтау, Кашан, Ошель/Ашлы, Чаллы, Кирмән, Алабуга, Казан) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан. Дистәләгән-йөзләгән болгар шәһәрләре һәм авыллары, дөресрәге, аларның археологик калдыклары, күрше Ульяновск, Самара һәм Пенза өлкәләрендә табылган. Югары Кама (ул заманнарда аны – Агыйдел кушылган җирдән югарыдагы өлешен – Чулман дип атаганнар) һәм шул төбәктә яшәп яткан борынгы коми-пермяклар җирендә дә берничә болгар шәһәре – һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре булган. Рождественск (язма чыганакларда сакланган тарихи исеме – Афкула) һәм Кыласово шәһәрлекләренең оборона корылмаларына кадәр болгарлар тарафыннан төзелгән. Казылмалардан чыккан табылдыкларның 80 проценты диярлек бол-

гарларныкы. Шәһәр ныгытмаларына якын гына мөселман зираты урнашкан. Шул тирәдә үк болгар чүлмәкчеләренең остаханәләре, ике ярусы чүлмәк яндыру мичләре казып өйрәнелгән [Белавин, Крыласова, 2008].

Соңгы елларда Түбән Иделдә яшәгән болгарлар турында да яңа мәгълүматлар тупланды. Табигый ки, Хәзәр каганаты таркалганнан соң да (X гасыр ахыры) аның төп халкын тәшкил иткән болгарларның күбесе шул ук җирләрдә яшәп кала. Әмма XI гасырның икенче яртысыннан Түбән Идел, Каспий, Азов һәм Кара диңгез буе далаларына көнчыгыштан кыпчаклар күченеп килә башлыйлар һәм биредә элегрәк яшәгән бәҗәнәкләрне, гузларны, аланнарның һәм болгарларның бер өлешен «йоталар», ассимиляциялиләр. Озак еллар төрки күчмәннәр археологиясе белән шөгыльләнгән күренекле совет галиме профессор С.А. Плетнёва, соңгы тикшеренү нәтиҗәләренә таянып: «Кыпчакларның болгарлар белән кушылуы аларның антропологик кыяфәтенә дә үзгәрешләр кертә, күмү йолаларында да кабергә акбур порошогы һәм агач күмере сибү кебек болгарлардан алынган яңа элементлар килеп чыга», – дип язган иде [Плетнёва, 1997, с. 38].

Иделнең түбән агымына караган төбәкләрдә болгарларның монгол яуларына кадәр күпләп яшәгән шәһәрләре турында XII гасыр сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати кызыклы язмалар калдырган. Саксин шәһәренең үзәгендә, дип яза ул, «Болгардан килгән кешеләрнең әмире яши, аларның җомга намазы укыла торган зур Җамигъ мәчетләре бар, аның тирәсендә болгарлар бистәсе. Аларның (болгарларның) тагын бер Җамигъ мәчетләре бар, бирегә «Сувар кешеләре» дип атала торган халык намазга йөри. Алар шулай ук күпсанлы» [Путешествие..., 1971, с. 27].

Идел елгасы тамагында урнашкан һәм VIII–X гасырларда Хәзәр каганатының башкаласы булып торган Итиль шәһәре турында да язма чыганакларда шуңа охшаш хәбәрләр сакланган.

2000 елдан башлап Әстерхан шәһәреннән 40 чакрым чамасы көньяктарак урнашкан Самосдельское шәһәрлегендә Мәскәү археологлары зур казу эшләре алып баралар. Аларда Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты галимнәре дә катнаша. Шәһәрлекнең гомуми мәйданы 200 га булып, ул, җир өстендә аунап яткан табылдыкларга карап, Алтын Урда чорында яшәгән булырга тиеш, дип фаразлана иде. Әмма биредә һич көтмәгәндә монголларга кадәрге шактый калын культура катламы да ачылды. Һәм бу катламдагы төрле тип торак йорт калдыклары, шул исәптән юрта эзләре, хуҗалык корылмалары, коелар казып тикшерелде. Катлам әйбер табылдыкларына да бай һәм аларның күпчелеге, бигрәк тә керамик савыт-саба, казу эшләренең җитәкчесе профессор Э.Д. Зиливинская сүзләре белән әйткәндә, «X–XII гасырларда яшәгән Идел болгарларыныкына абсолют охшаш» [Зиливинская, 2011, с. 27]. Димәк, бу шәһәрдә яшәүчеләрнең күпчелеген болгарлар тәшкил иткән, дип раслый алабыз. Сүз уңаеннан: элеге шәһәрлекне археолог-

лар инде күптән эзләгән һәм кайбер тарихчылар тарафыннан Каспий диңгезе күтәрелгән чорда су астында калып юкка чыккан, дип фаразланган Итил белән тәңгәлләштерәләр. Дөрес, Саксин каласыдыр дип уйлаучылар да бар.

Түбән Иделдә монголлар чорына кадәрге болгарлар калдырган археологик һәйкәлләр берән-сәрән генә түгел. Казан археологларының тикшеренүләре нәтиҗәсендә ел саен диярлек яңа авыл-шәһәр урыннары табылып тора. Казу эшләре вакытында тупланган материаллар биредә яшәгән кыпчак һәм болгарларның матди культурасын, аның башка төбәкләргә хас булмаган үзенчәлекләрен өйрәнүдә мөһим роль уйныйлар. Табылдыкларның күп өлешен тәшкил иткән керамик эшләнмәләрне җентекләп анализлап, археологлар хәзәрләр һәм болгарларның һөнәрчелек культурасында буыннан-буынга күчеп килә торган охшашлыкларны таптылар. Баксаң, чүлмәкчелекнең Алтын Урда чорында калыплашкан традицияләре дә, нигездә, әнә шул болгар һөнәрчелегенә барып тоташа икән. Алай гына да түгел. Идел буе далаларында әле монголларга кадәр үк салынган һәм кайчандыр тулы канлы тормыш белән яшәп яткан шәһәрләрне өйрәнү, Алтын Урда шәһәрләре халкы утрак тормышны белмәгән, шәһәр кору традицияләре булмаган буш урында үсеп чыкканнар, дигән ялган концепциягә каршы килә. Түбән Иделдә һәм Җучиләр дәүләтенең башка өлкәләрендә барлыкка килгән торак пунктлар, шәһәрләр бу җирләрдә инде күптән оешып җиткән авыл-шәһәр структурасына нигезләнгән, дип һич икеләнмичә әйтә алабыз.

Югарыда китерелгән фактлар шуны да раслый: болгарлар монголларга кадәрге чорда ук Урта Идел (Казан), көнбатыш (мишәрләр), Урал буе (Пермь), Әстерхан татарлары бүген дә яши торган җирләрне биләп торганнар. Себердә болгарлардан калган археология истәлекләре табылмады.

Башкортстан территориясендә болгарларга кагылышлы археология һәйкәлләре юк [Археологическая карта..., 1976]. Димәк, алар бу җирләрдә яшәмәгән. Һәм бу факт болгарларның башкортлар тарихындагы роле проблемасын бик җиңел хәл итә. Татарларны башкортлар белән якынлаштыручы этник компонентлар кыпчаклар белән бәйле. Ә аларның телләре болгар теленә бик якын булган («с болгары язык и род един», – диелә рус елъязмаларында).

Чувашларга килгәндә исә, бу халыкның этник нигезләре формалашуда болгар компонентын инкяр итү ярамас, дип уйлыйм. Шул ук вакытта чуваш галимнәренең катгый рәвештә, чувашлар – үзләрендә болгар культурасының бөтен үзенчәлекләрен саклап калган бердәнбер халык, ә татарларның килеп чыгышы тулысынча Көнчыгыш Европаны басып алган монгол-татарлар белән бәйле, дигән концепцияләре дөреслектән бик ерак тора, дип саныйм. Чөнки нәкъ менә нык үскән болгар мәдәниятенең асылын тәшкил иткән, бары тик аңа гына хас төп компонентлар: гасырлардан килгән дәүләтчелек традицияләре, рун һәм гарәп язмачылыгы, ислам (мөселман) дине,

дөньяви фәннәр (медицина, шул исәптән, фармакология, астрономия, химия/алхимия, тарих һ. б.), поэзия (Кол Гали), шәһәрләр кору һәм монументаль архитектура сәнгате – Урта гасырлар чуваш мәдәнияте өчен бөтенләй чит күренеш. Соңгырак чорларда болар барысы да татар мәдәниятендә күчемле үсеш алалар. Татарларның милли үзаңында чыңгызыйлар түгел, болгар бабалар өстенлекле, ныклы урын алып торалар. Чувашлар һәм башкортлар түгел, бары тик татарлар гына болгарлар белән бәйле ерак үткәнебезгә һаман да эчке бер дулкынлану, соклану һәм горурлык хисләре аша карыйлар, бүгенгә кадәр сакланып калган таш-кирпеч бина хәрабәләренә килеп, бабаларыбыз рухына дога кылып китәләр. Әйе, тел гыйлемендә, борынгы болгар теле, үзенең үсешендә артык үзгәрешләр кичермәгән хәлдә, хәзерге чуваш телендә сакланып калган, дигән сәер теория яшәп килә. Бу теория, беренче чиратта, XIV гасыр мөселман кабер-ташларындагы язмаларга нигезләнгән. Чыннан да чуваш һәм якут телләре бүгенге төрки телләрдән бик нык аерылып тора һәм алар арасында иң борынгыларыннан санала. Әмма чуваш-болгар тәңгәллеген раслау өчен болар гына җитә микән? Чынлыкта без бит болгар телен белмибез, ә белгән кадәресе яманаты чыккан шул теорияне җитди тәнкыйть утына алырга мөмкинлек бирә [Закиев, Кузьмин-Юманади, 1993]. Бу проблема безнең телче галимнәребездән аерым игътибар сорый.

Болгарларга нисбәтле археология һәйкәлләре (2 шәһәрлек һәм берничә дистә авыллык) башлыча Чувашстанның Татарстанга чиктәш көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында, Зөя елгасы бассейнында урнашкан [Фахрутдинов, 1971]. Аларның берсе – Тигәш шәһәрлеге генә яхшы өйрәнелгән. Күренекле археолог Г.А. Фёдоров-Давыдов фикеренчә, ул башта мәҗүсиләр гыйбадәтханәсе булган, соңыннан бай феодал утарына әверелгән [Фёдоров-Давыдов, 1962]. Бу турыда башка фикерләр дә бар: Хузин, Хамидуллин, 2013, с. 216–217]. Бүгенге фән карамагындагы объектив мәгълүматлар чувашларның этнос буларак оешу процессында болгарлар да өлешчә (!) катнашкан дигән фикергә каршы килми, шулай да археология, этнография һәм антропология материаллары чуваш этногенезында өстенлекне җирле фин кабиләләренә бирә [Краснов, 1974; Хузин, 2012].

Фәнни әдәбиятта болгарларның Төньяк Кавказда яшәүче төрки халыклар тарихындагы роле бик аз яктыртылган. Без биредә карачай һәм балкар халыкларын күз алдында тотабыз. Алар яшәгән җирләргә төрки кабиләләр һуннар заманында ук үтеп керә. Язма чыганакларда ул кабиләләр арасында савирлар/суварлар телгә алына. Шунысы кызык, сваннар үзләренең ут күршеләре булган карачайлар һәм балкарларны бүген дә сауарлар/савирлар дип атап йөртә [Кубанов, 1987, с. 48]. Болгарлар бирегә Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, ягъни VII гасыр ахырларында күчеп утырган булса кирәк. Соңрак аларга аланнар да килеп кушыла. Үзенең көчле ныгытмалары һәм рун язмалары белән атаклы Хумара крепостенда болгар-алан хәрби гарнизоны

торган. Карачай-Чиркәсия һәм Кабарда-Балкария республикаларында башка болгар һәйкәлләре дә, шул исәптән, күмү йолалары һәм кабергә куелган әйберләре белән Азов-Дон болгарларыныкына охшаш зиратлар да бар [Степи Евразии..., с. 83 и сл., 224 и сл.].

IX–X гасырларда Урта Идел болгарлары арасында яшәп яткан бәләнҗәр/баранҗарларның һәм берсула/барсилларның да Төньяк Кавказ, хәзерге Дагстан җирләреннән чыккан кавемнәр икәнлеген искә төшереп үтәсе килә. Шул ук вакытта археологларның Кырымда да күпсанлы болгар-хәзәр һәйкәлләрен казып өйрәнүләрен әйтеп узарга кирәк [Баранов, 1990]. Аларның кырым-татар этногенезына катнашы юк дәрәҗәсендә дип саныйлар, әмма бу фикер әлеге истәлекләрнең җитәрлек өйрәнелмәвеннән генә килергә дә мөмкин.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Үзәк һәм Көнбатыш Европага болгарлар V гасырның икенче яртысында килеп чыгалар. Иоанн Антиохийский язмаларына караганда, остготлар һәм аларның юлбашчылары «ромейларны куркуга салдылар, Фракия шәһәрләрен туздырып ташладылар һәм император Зенонны болгарлар белән союздашлык килешүенә күндерделәр» [Сиротенко, 1972, с. 200]. Остготлар белән 488 елгы сугышта болгарлар җиңелә, әмма аларны хәтта дошманнары да, сокланып: «менә дигән җайдаклар, яшен тизлегендә һәм максатчан хәрәкәт итәргә һәм табигый киртәләрне бик җиңел үтәргә сәләтлеләр, искиткеч түземлеләр», – дип сурәтлиләр.

Остготлар Италиягә киткәннән соң, болгарлар, Византия гаскәрләре составында сугышып, Дакия, Фракия, Мёзия җирләрен яулап алалар, 515 елда күтәрелгән Виталиан восстаниесендә җирле халык ягында Анастасий хөкүмәтенә каршы көрәшәләр һәм әкренләп Балкан ярымутравында төпләнә башлыйлар. Павел Диаконның (720–797) «Лангобардлар тарихы»нда лангобардларның һәм алар артыннан ук болгарларның да, аварлар басымы астында, 568 елда Паннониядән Италиягә китүләре турында хәбәр ителә. Әлеге тарихчы Италиянең төньягында, Лангобард корольлегендә, Болгар (Bolgare) исемле крепость-шәһәрчек булуы турында яза. Сүз уңаеннан бу шәһәрнең бүгенге көндә дә шул ук исемне йөртүен әйтеп үтәргә кирәктер [Сиротенко, 1972, с. 207].

Аңлашыла ки, бу вакыйгалар барысы да VI–VII гасырларда болгарларның Түбән һәм Урта Дунай җирләренә күпләп күчеп утыруларына китерә. Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, Аспарух болгарлары бу якларга чагыштырмача тиз һәм җиңел килеп урнаша. 681 елда аларның тарихка Беренче Болгар патшалыгы исеме астында кереп калган дәүләте барлыкка килә.

Болгарларның Кубер исемле юлбашчылары (Кубрат ханның дүртенче улы) җитәкләгән тагын бер төркеме VII гасыр ахырында, ягъни әле бу якларга мадьяр-венгрлар күчеп утырганга кадәр, җирле халык белән килешү төзеп, Паннониягә, хәзерге Венгрия җирләренә килеп төпләнә [Сиротенко, 1972, с. 216]. Әмма чыганакларда Паннониягә тагын да элегрәк килеп эләккән болгарлар турында да хәбәрләр бар.

Фредегар «Хроникасы»ндагы мәгълүматларга караганда, 631–632 елларда ук аварлар һәм алар кул астындагы Паннония болгарлары арасында сугышлар булып торган. Бу сугышларда болгарлар җиңелгән һәм 9 меңгә якын гаилә, юлбашчылары Альцек җитәкчелегендә, Бавариягә китеп урнашырга мәҗбүр булган [Сиротенко, 1972, с. 209]. Франк короле Дагоберт болгарларга кышны үзе күрсәткән җирдә үткәрергә рөхсәт бирә, әмма тиздән аларның барысын да кылычтан үткәрергә боера. Шулай да 700 болгар ире (хатыннары һәм балалары белән) үлемнән качып котыла һәм үзләренә Венет (Венеция) маркасында вакытлыча сыену урыны таба. Павел Диакон хәбәрләренә караганда, лангобард короле аларга Сепин, Бовиана һәм Изерния җирлегендә даими яшәү өчен җир бүлеп бирә. «Һәм алар бу җирләрдә бүгенге көнгә кадәр яшәп яталар, – дип яза Павел Диакон. – Латинча бик әйбәт сөйләшсәләр дә, үзләренең телләрен дә онытып бетермәгәннәр, шул телдә аралашалар» [Сиротенко, 1972, с. 209].

Галимнәр раславынча, Төньяк Италиядә әлеге болгарларның археологик эзләре сакланып калган. Җирле халык күмелгән борынгы зиратларда сирәк булса да башларында ясалма деформация, йөзләрендә монголоид сыйфатлары сизелеп торган кеше сөякләре очраштыргалый. Үлгән кеше янында аның яраткан аты ята. Янәшәдә ат дирбияләре (йөгән детальләре, өзәңге) һәм сугыш кораллары (укҗәя, кылыч-хәнҗәр) куелган. Бу каберләргә болгар сугышчылары күмелгән [Мингазов, 2012, с. 203–204]. Тел белгечләре Италиядә еш очрый торган *Булгаро*, *Булгарелли*, *Булгарени* фамилияләре дә әнә шул VI–VII гасырларда яшәгән болгарлардан килә, дип саныйлар. Төньяк Италиядә килеп чыгышлары белән болгарларга нисбәтле топонимнар да очрый [Мингазов, 2012, с. 204]. Бу урында үземә дә шушы килеп ирешкән бер кызыклы фактка тукталасы килә: 2016 елда, Болгария эшмәкәрләренең матди ярдәме белән, Италиянең Челе де Булгария шәһәре үзәгендә Кубрат ханның төпчек улы Альцекка һәйкәл ачылган икән. Күптән түгел Италиянең Мәскәүдәге илчелеге, Челе де Булгария белән Татарстанның берәр шәһәре арасында туганлык җепләре урнаштырырга теләкләре барлыгын белдереп, ТРның Мәскәүдәге вәкиллегенә мөрәҗәгать иткән. Челе де Булгариягә, минемчә, безнең Болгар тугандаш була ала. Әлбәттә, биредә Кубрат хан белән аның улларына ансамбль рәвешендә матур гына бер һәйкәл куелса, тагын да яхшырак булыр иде.

Болгарларның (гомумән төркиләрнең) Венгриядәге эзләре археологиядә дә, телдә дә бик ачык чагыла [Fodor, 1982a, p. 45–81]. Шулай булырга тиеш тә. Этник тамырлары белән Көньяк Себердәге дала кабиләләренә барып тоташкан мадьярларның борынгы бабалары әле VI гасырның икенче яртысында ук Төрк каганатыннан бәйлелеккә эләгәләр. Бераздан алар, күчмәннәр, көнбатышка таба хәрәкәт итеп, венгрлар тарихына Magna Hungaria (Бөек Венгрия) исеме белән кереп калган Идел – Урал арасындагы җирләргә килеп чыгалар һәм биредә бәҗәнәкләр, болгарлар, угорлар чолганышында калалар [Halikova,

1976, p. 53–78]. IX гасырның беренче яртысында Урта Иделдән көнбатышка таба күчешләрен дәвам итәләр, башта Дон һәм Азов диңгезе буйларында урнашкан легендар Леведия илендә, ә Паннониягә күчеп китәр алдыннан, Хәзәр каганаты кул астындагы «Әтелкузу»да, Днепр – Днестр елгаара өлкәсендә яшәп алалар. Леведиядә венгрларның Алмуц/Алмош исемле юлбашчылары була. Әнә шул Алмошның улы Арпад вакытында, 895 елда, алар Урта Дунай буйларына килеп төпләнәләр һәм биредә Венгрия корольлеге барлыкка килә [Fodor, 1982б; Фодор, 2015].

Бу урында шуны искәртеп үтәргә кирәк: борынгы венгрларның барысы да Урта Идел һәм Урал буйларыннан көнбатышка күчеп китмәгән, бер өлеше әлеге җирләрдә бөтенләйгә утырып калган. Төп төркемнән аерылып калган әнә шул венгрларның зур гына бер зиратын (Алексеевск районы Олы Тигәнәле авылы янында) 1970 елларда Казан археологлары казып өйрәнгән иде [Chalikova, Chalikov, 1981; Халиков, Халикова, 2018].

Венгрларның болгарлар белән тыгыз багланышлары турында сөйләүче чыганакларның беренчесе – тел өлкәсенә караган материаллар:

*Алмош/Алмыш* – Идел Болгарстанының безгә билгеле иң беренче хакиме (әмире) һәм шул ук исемле кеше – Венгр дәүләтенә нигез салган, аның идарәчеләре династиясенең башында торган король.

*Арпад* – Алмошның әтисе; исеме *арпа* сүзеннән килеп чыккан дип фаразлана; *д* – венгрларда кечерәйтү суффиксы [Шушарин, 1997, с. 152].

*Золта* исемле корольнең, аның улы *Такшонның* һәм дә кайбер мадьяр кабиләләренең (*тарьян, ене, кер, кеси*) исемнәре дә төрки телләрдән алынган [Шушарин, 1997, с. 191].

Бер төркем болгарларның Венгриядә яшәгәнлеген раслаучы фактлар арасында бүгенге көнгә кадәр сакланган өч дистә чамасы топонимны да күрсәтергә мөмкин: *Болгар*, *Богард*, *Полгар*, *Полгарди*, *Боляр*, *Берсел* һ. б. [Шушарин, 1997, с. 185]. Форсаттан файдаланып, безнең галимнәргә дә Көнбатыш Европада таралган төрки-татар топонимнарын (аларны Болгариядә киң таралган төрек топонимнары белән бутарга ярамый) җитди рәвештә өйрәнә башларга тәкъдим итәр идем.

Мадьярларның килеп чыгышы турында XIII гасырда ук язып алынган риваять-легендалар бик кызыклы: «Эвилат илендә яшәүче гигант – алыптай гәүдәле Менрот Энет исемле хатыны белән Һунора һәм Мадьяра (Могора) исемле ике угыл тудыралар. Шулардан инде һуннар белән мадьярлар килеп чыккан. Берзаман алар Меотида (Азов) сазлыкларына китеп баралар, биредә Белар исемле кешенең тол халган хатыннарын һәм ятим балаларын очраталар. Бу ике мадьяр аларны бөтен байлыклары белән үзләренә ияртеп алып китәләр...» [Шушарин, 1997, с. 198–203]. Бу риваятьтә безнең игътибарны *Энет* (төрк. *эни/әни*) һәм *Белар* (булар/бүләр/биләр) исемнәре җәлеп итә.

Бүләр/биләр кабиләләре һәм мадьярлар VIII–IX гасырларда күршеләр булып яшәгәннәр. 1235 елда венгр монахы Юлиан, Болгар илендә утырып калган мәҗүси кардәшләрен үзе табынган католик диненә күндерү өчен, нәкъ менә Биләргә – Олуг шәһәргә килә [Хузин, 2006, с. 283].

Әле узган гасыр башларында ук тюрколог галим Золтан Гомбоц тарафыннан тикшерелгән венгр телендәге төрк (башлыча болгар) алынмаларының күпчелеге игенчелек, терлекчелек, аучылык, балыкчылык, мәдәният һәм көндәлек тормыш өлкәләренә карый. Алынмаларның шактые хәзерге татар телендәге сүзләргә охшаш: *arp* – арпа, *alma* – алма, *boršo* – борчак, *torma* – торма, *kapu* – капка, *balta* – балта, *sakal* – сакал, *sirt* – сырт, *kender* – киндер, *oršo* – орчык, *šator* – чатыр, *bator* – батыр, *temen* – төмән (ун мең), *tilmacs* – тылмач, *oroslan* – арыслан, *korom* – корым, *kek* – күк, *beka* – бака һ.б. [Gombocz, 1912, s. 203–210; Шушарин, 1997, с. 206–210; Закиев, Кузьмин-Юманади, 1993, с. 62 и сл.].

X гасырда Идел буе болгарларының венгрлар белән бәйләнешләре турында язылган «Венгр Анонимы»нда (XIII гасыр) кызыклы мәгълүматлар бар. Россиядә бу чыганакны XIX гасырның икенче яртысында күренекле семитолог Д.А. Хвольсон фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Текстның эчтәлеге (Хвольсон комментарийлары белән) түбәндәгечә:

«Bilers, ягъни Биләрдән яки Болгар иленнән чыккан кешеләр – мөселманнар. Мадьяр герцогы (идарәчесе) Таксонь идарә иткән заманда, 970 еллар тирәсендә, Венгриягә Билла һәм Боксу исемле ике бертуган җитәкчелегендә Идел буе болгарлары төркеме килә; бераздан Хәсән җитәкчелегендә тагын бер төркем килә. Аларны дусларча каршы алалар һәм яшәү өчен Дунай елгасының сул ягындагы авылларны бирәләр. Шул урында алар Пешт шәһәренә нигез салалар. Болгарларның бу якларга күченеп килүе – шөбһәсез, 968 елда болгарларга һәм хәзәрләргә каршы кенәз Святослав вакытында булган коточкыч рус явы нәтиҗәседер... Венгриядә Болгардан күчеп килгән әлеге мөселманнарны биләрләр (Bilers), ягъни болгарлар һәм исмаилитлар (Ismahelitae) дип атадылар. Шуннан соң алар Венгриядә, төрлечә кысуларга һәм эзәрлекләүләргә карамастан, откупщиклар һәм финанс белән идарә итүчеләр (управляющийлар) буларак, бик мөһим роль уйнадылар» [Хвольсон, 1869, с. 108–109]. Бу болгарларның нәселләре, Д.А. Хвольсон күрсәтеп үткәнчә, әле XIV гасырда да венгрлар җәмгыятендә күренекле урын биләп торганнар.

Венгриядә болгарларның торак урыннар рәвешендәге археологик эзләре билгеле түгел. Хуш, үзләренең элгәреге, X гасырга караган, авыл урыннары да әле күптән түгел генә табылды бит. Әмма археологлар болгар әйберләрен авар һәм венгр каберлекләрендә еш очраталар. Матесалкта (Собольч өлкәсе) табылган кылычлар, ат дирбияләре, болгарларга хас бизәкләр төшерелгән савыт-саба, алтыннан ясалган бил каеше прәшкәләре, Тисабур (Сольнюк өлкәсе) авылы янындагы

каберлектән чыккан каеш гарнитуры, атаклы Надьсентмиклош (хәзер Румыния территориясендәге Сынниколаул авылы) хәзинәсендәге рун язмалы көмеш савытлар шундыйлардан.

Албаниядә Врап һәм Ерсеке авыллары янында табылган һәм килеп чыгышлары белән болгарларга нисбәтле ике хәзинә билгеле. Аларның беренчесендә 4 потир, 3 чүмеч, 30 га якын каеш детальләре (барысы да алтыннан), төбенә монограммалар уелган көмеш кувшин һәм казан, икенчесендә – 120 дән артык алтын-көмеш каеш детальләре, төбенә Констанца II мөһерләре сугылган (641–651, 659–661) ике көмеш тәлинкә [Friedler, 1996, s. 248–264; Werner, 1986, s. 7–104] бар. Бу әйберләрнең төгәл аналоглары Болгариядә казып тикшерелгән һәм VII–VIII гасырларга караган Велино, Кабиюк, Дивдядово, Злагари, Гледачево каберлекләрендә табылган. Алтын-көмештән ясалган затлы әйберләрнең хуҗалары – һичшиксез, Плиска аксөякләре, болгар ханнары. Галимнәр фикеренчә, Албаниядә табылган Врап һәм Ерсеке хәзинәләрендәге әйберләр авар ханы һөнәрчеләре тарафыннан эшләнеп, ниндидер юллар белән Кубрат ханның Кубер исемле улына килеп эләккән булырга мөмкин. Әмма затлы әйберләр ясауда махсуслашкан һөнәрче остаханәсе Куберның үзенеке үк булмады микән – ул бу вакытта, авар ханы кушуы буенча, Византия чикләрендә торган әсир румлыларның управляющие вазифасын башкарган, ләкин бик тиз, аңа буйсынудан туктап, мөстәкыйль идарәчегә әверелгән [Тотев, Пелевина, 2011, с. 202–218].

Археологлар Молдавиядә һәм Румыниядә Хәзәр каганаты чорына караган һәм болгар һөнәрчелегенә хас савыт-сабалар, (сирәгрәк булса да) сугыш кораллары табылган йөздән артык авыл урынын казып тикшерде [Die Keramik…, 1990, s. 171; Козлов, 2015]. Биләр коллекцияләрендә аналогияләре булган вертикаль тоткачлы керамик казаннар Сербиядә Вршац шәһәре тирәсендәге борынгы торак пунктын казыганда килеп чыккан [Fodor, 1979, p. 315–325]. Моравиядә (Чехия), Саксониядә һәм Баварияда (Германия), Австриядә очрый торган Bolghri, Bulgheria, Pulgram, Pulgarn, Bulhary, Polgren кебек этнотопонимнарның килеп чыгышын тел белгечләре кайчандыр шул төбәкләрдә яшәп көн күргән болгарлар белән бәйләп аңлаталар [Мингазов, 2013, с. 24].

Югарыда телгә алынган фактларның барысы да әлгәреге Урта гасырлар болгарларының Урта Иделдән башлап Дунай-Карпатка кадәр сузылган географик киңлекләрдә таралып утыруларын, бүгенге көндә төрки, славян, фин-угор, иран һәм роман телләрендә сөйләшә торган Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа халыклары тарихында, хәтта аларның этник яктан милләт булып формалашуында сизелерлек роль уйнауларын ачык күрсәтеп тора. Кызганыч, бу мәкаләдә күтәрелгән проблемалар әлегә бик аз өйрәнелгән. Болгар мирасына кагылышлы мәсьәләләр әле һаман да актуальлелеген югалтмый. Киләчәктә алар яңа чыганаклар нигезендә тагын да киңрәк планда өйрәнелсен иде дигән теләктә калабыз.

**Әдәбият**

Археологическая карта Башкирии / отв. ред. О.Н. Бадер. М.: Наука, 1976. 263 с.

*Ашмарин Н.И.* Булгары и чуваши // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1902. Т. XVIII, вып. 1–3. 132 с.

*Әхмәтҗанов М.И.* Болгар теленең язмышы (эпиграфика материаллары буенча) // Татарская археология. 1998. № 1 (2). С. 99–120.

*Баранов И.А.* Таврика в эпоху раннего средневековья. Киев: Наукова думка, 1990. 168 с.

*Белавин А.М., Крыласова Н.Б.* Древняя Афкула: археологический комплекс у с. Рождественск. Пермь: Изд-во Перм. гос. пед. ун-та, 2008. 603 с.

*Димитриев В.Д.* Вопросы этногенеза, этнографии и истории культуры чувашского народа. Чебоксары: Изд-во Чуваш. гос. ун-та, 2004. 312 с.

*Закиев М.З., Кузьмин-Юманади Я.Ф.* Волжские булгары и их потомки. Казань: АН РТ, 1993. 160 с.

*Зиливинская Э.Д.* Раскоп № 1 // Самосдельское городище: вопросы изучения и интерпретации / отв. ред. В.Д. Васильев. Астрахань, 2011. С. 13–35.

История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности / отв. ред. С.Г. Кляшторный. Казань: Рухият, 2002. 552 с.

*Козлов В.И.* Население степного междуречья Дуная и Днестра конца VIII – начала XI веков: балкано-дунайская культура. Казань; СПб.; Кишинев, 2015. 323 с.

*Комар А.В.* Перещепинский комплекс в контексте основных проблем истории и культуры кочевников Восточной Европы VII – начала VIII в. // Степи Европы в эпоху средневековья. Т. 5. Хазарское время / гл. ред. А.В. Евглевский. Донецк, 2006. С. 7–244.

*Комар А.В., Кубышев А.И., Орлов Р.С.* Погребения кочевников VI–VII вв. из Северо-Западного Приазовья // Степи Европы в эпоху средневековья. Т. 5. Хазарское время / гл. ред. А.В. Евглевский. Донецк, 2006. С. 245–374.

*Краснов Ю.А.* Проблема происхождения чувашского народа в свете археологических данных // Советская археология. 1974. № 3. С. 112–124.

*Кубанов А.Х.* К вопросу об этническом составе населения западной Алании // Вопросы археологии и традиционной этнографии Карачаево-Черкесии / отв. ред. А.И. Першиц. Черкесск, 1987. С. 45–59.

*Мажитов Н.А., Султанова А.Н.* История Башкортостана. Древность. Средневековье. Уфа: Китап, 2010. 496 с.

*Мажитов Н.А.* Вопросы древней и средневековой истории башкирского народа. Уфа: Гилем, 2013. 300 с.

*Мингазов Ш.Р.* Наследники Великой Болгарии в Западной Европе // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 1 (2). С. 203–204.

*Мингазов Ш.Р.* Великая Болгария и роль тюркоязычных болгарских племен в истории Европы: автореф. дис. … канд. ист. наук. Казань, 2013. 24 с.

*Плетнёва С.А.* Древние болгары в восточноевропейских степях // Татарская археология. 1997. № 1. С. 31–60.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / публикация О.Г. Большакова, А.Л. Монгайта. М.: Вост. лит-ра, 1971. 136 с.

*Рашев Р.* Прабългарите през V–VII век. София: Фабер, 2004. 348 с.

*Сиротенко В.Т.* Византия и булгары в V–VI вв. // Уч. зап. Перм. гос. ун-та. 1961. Т. XX, вып. 4. С. 43–70.

*Сиротенко В.Т.* Письменные свидетельства о булгарах IV–VII вв. в свете современных им исторических событий // Славяно-балканские исследования. Историография и источниковедение / отв. ред. С.А. Никитин. М.: Наука, 1972. С. 195–218.

Степи Евразии в эпоху средневековья. Археология СССР / отв. ред. С.А. Плетнёва. М.: Наука, 1981. 303 с.

*Тотев Б., Пелевина О.* Сокровище из Врапа (Албания) и аристократические погребения болгар Нижнего Дуная // Археология евразийских степей. Т. 12. Материалы I Междунар. Болгарского форума / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 2011. С. 202–218.

*Фахрутдинов Р.Г.* О степени заселенности булгарами территории современной Чувашской АССР // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1971. С. 175–201.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Фёдоров-Давыдов Г.А.* Тигашевское городище. (Археологические раскопки 1956, 1958 и 1959 гг.) // Материалы и исследования по археологии СССР / отв. ред. А.П. Смирнов. М., 1962. № 111. С. 49–89.

*Фодор И.* Венгры: древняя история и обретение родины. Пермь: ООО «Типография «ЗЁБРА», 2015. 132 с.

*Халикова Е.А., Халиков А.Х.* Ранние венгры на Каме и Урале. (Больше-Тиганский могильник) // Археология евразийских степей. Вып. 25. Казань: Фэн, 2018. 144 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабского писателя начала X века, по рукописи Британского музея. СПб., 1869. 199 с.

*Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары и Волжская Булгария (VIII – начало XIII в.). Казань: Ин-т истории АН РТ, 2006. 583 с.

*Хузин Ф.Ш.* О некоторых проблемах булгарской археологии в аспекте этногенеза чувашского народа // Волжская Болгария (Булгария): этнокультурная ситуация и общественное развитие. Материалы науч. семинара / отв. ред. Г.А. Николаев. Чебоксары: Чув. гос. ин-т гуманит. наук, 2012. С. 37–45.

*Хузин Ф.Ш., Хамидуллин Б.Л.* Еще раз о соотношении язычества и ислама в домонгольской культуре Волжской Булгарии // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 1 (31). С. 214–221.

*Шушарин В.П.* Ранний этап этнической истории венгров: проблемы этнического самосознания. М.: Российская полит. энциклопедия, 1997. 512 с.

*Ювенальев Ю.Ю.* Этническая религия суваро-булгар // Государственность восточных булгар IX–XIII вв. Материалы междунар. науч. конф. Чебоксары: Таус, 2012. С. 292–308.

*Chalikova E.A., Chalikov A.H.* Altungarn an der Kama und im Ural: Das Gräberfeld von Bolschie Tigani / Régészeti Füzetek, ser. II, No 21. Budapest: Maguar Nemzeti Múseum, 1981. 132 s.

Die Keramik der Saltovo-Majaki Kultur und ihrer Varianten / Hrsg. von Csánad Bálint. Budapest, 1990. 342 s.

*Fiedler U.* Die Spätawarenzeitlichen Gürtelbestandteile von Vrap-Erseke aus Velino // Germania. 1996. Bd. 74. S. 248–264.

*Fodor I.* Archaeological traces of the Volga Bulgares in Hungary of the Arpad period // Acta Orientalia Acad. Scient. Hung. 1979. T. XXXIII, 3. P. 315–325.

*Fodor I.* On Magyar-Bulgar-Turkish contacts // Chuvash Studies. Ed. A. Róna-Tas. Budapest, 1982. P. 45–81.

*Fodor I.* Die Grosse Wanderung der Ungarn vom Ural nach Pannonien. Budapest, 1982. 373 s.

*Gombocz Z.* Die bulgarisch-turkischen Lehnwörter in der ungarischen Sprache. Memoires de la Societe Finno-Ougrienne. T. XVIII. Helsinki, 1912. 252 s.

*Halikova J.A*. Ösmagyar temetö a Káma mentén. (Magna Hungaria kérdéséhez). Ancient Hungarian Cemetery along the River Kama. (Contribution on the Issue of Magna Hungaria) // Archaeologica Értesitó. 1976. T. 103. P. 53–78.

*Shamiloglu U.* The End Volga Bulgarian // Varia Eurasiatica. Festschrift für professor Andras Rona-Tas. Szeged, 1991. P. 157–163.

*Werner J.* Der Schatzfund von Vrap in Albanien // Studien zur Archäologie der Awaren. T. II. Wien, 1986. S. 7–104.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты*
*баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 930

*Э.К. Сәлахова*

# «ИСЕМЕ ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ АЛТЫН КАРА БЕЛӘН ЯЗЫЛЫП КАЛЫРГА ТИЕШЛЕ МӨХТӘРӘМ БЕР ЗАТ»

На рубеже XIX–XX вв. начинается формирование татарской исторической науки, содержание которой определялось задачей создания научной истории татарского народа. Среди историков начала XX века свое заслуженное место занял Гайнетдин Нежмутдинович Ахмаров (1864–1911), чья деятельность была значима и многогранна. Целью данного исследования является всестороннее изучение творческого пути учёного. В статье показываются этапы его жизни, рассматривается педагогическая, общественная деятельность Г.Н. Ахмарова, анализируются его научные труды. Автор представляет учёного как яркого представителя формирующийся исторической науки, который одним из первых среди татарских историков в своём творчестве синтезировал традиции восточной и западной исторических наук. Статья посвящена к 155-летию со дня рождения Г.Н. Ахмарова.

**Ключевые слова:** Г. Ахмаров, история Казани, история Булгара, археология, этнография, татарское просвещение.

At the turn of the XIX–XX centuries the formation of the Tatar historical science begins. Its content was determined by the task of creating academic history of the Tatar people. Among historians of the beginning of the 20th century Gainetdin Nezhmutdinovich Akhmerov (1864–1911) took his well-deserved place, his work was significant and diverse. The purpose of this study is a comprehensive study of the creative way of the scholar. The article shows the stages of his life, considers the pedagogical, social activities of G.N. Akhmarov, analyzes his research works. The author presents the scholar as a vivid representative of an emerging historical science who was one of the first among Tatar historians to synthesize the traditions of Eastern and Western historical sciences in his work. The article is dedicated to the 155th anniversary of the birth of G.N. Akhmerov.

**Keywords**: G. Akhmerov, history of Kazan, history of Bulgar, archeology, ethnography, Tatar education.

Егерменче йөз башында хезмәтләре өчен замандашлары тарафыннан югары бәяләнгән бу галимнең эшчәнлеге гаять күпкырлы. Ул педагог, дәреслекләр авторы, тарихчы, татарлардан беренче археолог, җәмәгать эшлеклесе. Мөхтәрәм олуг зат Р. Фәхретдинев Гайнетдин Әхмәревне, Ш. Мәрҗани белән янәшә куеп, «Безнең тәфтишемезгә күрә, Волга вә Урал буйларында торучы мөселманнардан бу көнләргә кадәр өч мөәррих[1] килеп китте. Болардан берсе – мелла Хөсәен Фәезханов, икенчесе фазыйль Мәрҗани вә өченчесе дә – ошбу Гайнетдин әфәндедер», дип яза.

[1] Мөәррих – тарихчы.

Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәрев 1864 елда Казан губернасының Зөя өязе Наратлы (хәзерге Яшел Үзән районындагы Татар Наратлысы) авылында дөньяга килә. Сигез яшенә җиткәч, хәзерге Апас районына караган Шәм-Балыкчы авылындагы үз заманының гыйлемле кешесе булган Бикчәнтәй хәзрәт мәдрәсәсендә укый башлый. Анда белем алганнан соң, мәгърифәтче укытучы Шакирҗан Таһиров киңәше белән, 1881 елда Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Белем алуга омтылышы, кызыксынучанлыгы белән аерылып торган бу егет уку йортын мактау кәгазьләре белән тәмамлый [М.Къ, 1911]. 1885 елда, укытучылык таныклыгы алу белән, хәзерге Әгерҗе районына караган Биектау авылына укытучы итеп җибәрелә, әлеге авыл мәктәбенең ул беренче укытучысы була [КӨ ДА, 205 ф., 2 тасв., 1880 эш, 5а, 5б]. Күпчелек халык белемнән хәбәрсез булган бер чорда татар авылына килеп рус теле укыта башлау яшь галимгә җиңел бирелмәгән. Гайнетдин Әхмәрев бөтен авырлыкларны җиңеп чыга, озак та үтми, үз эшенең нәтиҗәләрен дә күрә башлый. Ул авыл халкының тирән ихтирамын яулый. Моны, ул авылдан киткәндә, халыкның аны күз яшьләре белән озатып калуы ук дәлилли [М.Къ, 1911]. Ул вакытта татар авылында рус теле укытуга нинди караш хөкем сөрүен исәпкә алсак, яшь мөгаллимнең эшенә югары бәя бирергә нигез туа. Аңа мәктәптәге мактаулы хезмәте өчен мәгариф эшләре буенча округ попечителе дә рәхмәт белдерә [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 60б].

Г. Әхмәрев 1891 елның 1 мартыннан Тәтеш шәһәренең рус-татар мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли башлый, ләкин монда аңа рус телен генә түгел, арифметика, уку, ана теле дәресләрен дә алып барырга, ислам кануннарын да укытырга туры килә [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 815 эш, 81а]. Аның мәктәбенә шәһәр мулласы Хәсәнгата Бикташевның мөнәсәбәте начар булып, мулла үз нәүбәтендә, халык арасында да мөгаллимгә карата тискәре караш булдыру өчен тырыша [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 19а]. Г. Әхмәревнең үз сүзләре белән әйткәндә, Тәтештәге хезмәтнең һәрбер елы ун еллык сәламәтлекне бетерерлек дәрәҗәдә катлаулы була. Шуңа карамастан, нәкъ менә Тәтештә эшләгән елларында ул гыйльми эш белән шөгыльләнә башлый. Тәтеш шәһәрендә хатын-кызлар мәктәбе ачылу да Г. Әхмәрев һәм Җ. Мускеев тырышлыгы белән бәйле икәнен әйтергә кирәк [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 907 эш, 68а].

Укытучы булып эшләү елларында Г. Әхмәрев мәктәп дәресләкләренә ихтыяҗ зурлыгын аңлый. 1890 елда аның «Татарлар өчен беренче урыс әлифбасы», «Татарлар өчен беренче кыйраәт китабы» дөнья күрә. Болар өчен ул Казанның фәнни-сәнәгый күргәзмәсе комитеты тарафыннан Мактау кәгазе, укытучылык хезмәтендәге уңышлары өчен, 1899 елда көмеш медаль белән бүләкләнә. Ул җитәкләгән Тәтеш мәктәбе Казан уку округы тарафыннан тәкъдим ителеп, 1900 елда Парижда узган Бөтендөнья күргәзмәсендә җиңеп чыга һәм комитетның мактау дипломына лаек була [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 148а, 179б].

Гайнетдин Әхмәрев Тәтешкә килгәндә үк, үзенең эшчәнлеген үстерү максатында, Казанга күченү хыялы белән яши. «Казанда яшәү Археология, тарих һәм этнография җәмгыте эшендә активрак катнашу һәм университет китапханәсеннән файдалану, ниһаять, үз балаларымны Казан гимназиясендә укыту мөмкинлеге бирер иде» [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 977 эш, 91а], дип яза.

1903 елда Казан шәһәренең татар ир балалары мәктәбенә рус теле укытучысы итеп билгеләнә. Бу мәктәптә озак эшләмәсә дә, мәктәп өчен күп нәрсә башкарырга өлгерә. Әлеге мәктәпнең 1902 елда тәмам янып беткән китапханәсенә, укытучы Миргаяз Иманаев белән бергәләп, китап җыю эшен башлый [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 55а]. Мәктәпне торгызу өчен күп тырышлык куя: югары органнардан матди ярдәм, пособиеләр алуны оештыра. Аның бу хезмәтләре тиешенчә бәяләнә дә, Г. Әхмәрев 1904 елның 6 декабрендә император тарафыннан зур көмеш медаль белән бүләкләнә [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1067 эш, 44а]. Ул бу мәктәпне аякка бастыру өчен күпме генә тырышмасын, югары органнар ярдәменнән башка берни дә эшли алмый. Бу мәктәпкә акча бик аз бүлеп бирелгән, уку һәм яшәү өчен шартлар булмаган. Г. Әхмәрев башка мәктәпкә күчәргә мәҗбүр булган. 1905 елгы уку елын ул Иске Татар бистәсе мәдрәсәсенең рус теле укытучысы буларак каршылый һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда эшли [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1461 эш, 16а].

Эш өчен янып торган, зур максатлар белән яшәгән киң колачлы, күпкырлы галим һәм талантлы педагог Г. Әхмәревнең гомере озын булмый. Озакка сузылган авырудан соң, 1911 елның 20 сентябрендә 47 яшендә ул бакыйлыкка күчә [Казан хәбәрләре, 1911].

Г. Әхмәрев, бигрәк тә Казанда яшәү елларында, укытучылык эшеннән кала, фән белән дә актив шөгыльләнә. Иң элек аның педагогик хезмәтләре – «Төрки әлифба» (2 кисәктә, 1910–1911), «Кыйраәте төрки» (2 кисәктә, 1911), «Гарәби әлифба» (1911), «Хөсне хат нәмунәсе» (1911) дигән китаплары мәктәп дәреслеге буларак әзерләнәләр һәм бер-бер артлы нәшер ителәләр. Бу дәреслекләрдән күп мәктәпләрдә файдаланганнар һәм алар иң уңышлы дәреслекләр рәтендә булганнар. Галим вафатыннан соң да алар берничә мәртәбә басылалар. «Төрки әлифба»сы, Н.Ф. Катанов тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, Казан шәһәре Руханилар академиясендә миссионерлар бүлегенең 1 курсында татар теле өйрәтү өчен кулланылган [Биобиблиографический словарь, 1889, с. 298]. Г. Әхмәревнең татар халкы тарихын яктырткан әһәмиятле хезмәтләре: «Болгар тарихы» (1909), «Казан тарихы» (1910) китаплары да мәктәпләрдә тарих дәреслеге буларак тәкъдим ителә [Обзор учебников, 1917, с. 21–24]. Габдулла Тукай да үзенең «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән җыентыгына «Казан тарихы»ннан өзекләр кертә [Тукай, 1919, б. 75–81].

XX йөз башында матбагачылык, китап басу эше киң колач алып, дәреслек язучылар күбәя. Педагог Г. Әхмәрев шушы вакыйга уңаеннан «Әлифба китапларына тәнкыйть» дигән фәнни-тәнкыйди хезмә-

тен тәкъдим итә [Әхмәрев, 1909]. Әлифбаларны анализлауга корылган бу хезмәт тел белемендә вакыйга буларак кабул ителә.

Галимнең эшләнеп бетми, нәшер ителми калган педагогик хезмәтләре дә булган. Ул, «Хөсне хат нәмунәсе»ндә күрсәтелгәнчә, 2 кисәктән торган «Кыйраәте төрки»нең тагын бер өлешен, шулай ук «Җәгърәфия», «Хисап», «Тарих» китапларын да чыгарырга ниятләгән. Гомере кыска булу сәбәпле, кызганыч ки, бу хезмәтләре дөнья күрә алмыйча калган.

Г. Әхмәревнең тарих белән чынлап торып Тәтештә эшләгән елларында кызыксына башлый. Ул биредә укытучылык эше белән генә чикләнеп калмый, элеккеге Болгар дәүләтенә кергән җирләрдә археологик казу эшләре алып бара, төрле авылларда булып, борынгыдан калган тарихи әйберләрне җыя, иске каберташ язуларын күчереп ала һәм өйрәнә. Г. Әхмәрев – тарихи истәлекләргә сак караш булдырырга өндәгән, тарихны халыкка җиткергән зат ул. Тарих, үткәннәр белән кызыксынуы Г. Әхмәревне Казан университеты каршында оештырылган Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә алып килә. Аның җәмгыять «Хәбәрләр»ендә (Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете) басылган бигрәк тә беренче чор мәкаләләре археологиягә, үзенә таныш булган урыннар тарихына багышлана. 1893 елда «Хәбәрләр»дә «Идел-Кама буе татар авылларындагы берничә каберлекне тикшерү нәтиҗәсе» дигән мәкаләсе басылып чыга [Ахмаров, 1893, с. 277–278]. Анда Идел-Кама төбәгенең кайбер татар авылларында ике яисә өч зират булуга игътибар ителә, «күп кенә татар авылларында «иске зират» һәм «яңа зират» дигән урыннар бар, шуларның иске зират дигәннәре җирле халыкның мәҗүсилек заманнарына караган булырга тиеш», – дип, автор моның сәбәпләрен үзенчә аңлата.

Шул ук елны «Хәбәрләр»дә тарихчының аеруча игътибарга лаек нәүбәттәге тикшерену нәтиҗәсе басыла. Г. Әхмәрев «Борынгы Суар урынына экскурсия» дип исемләнгән мәкаләсендә тарихчылар күптән баш ваткан мәсьәләне чишүгә ирешә [Ахмаров, 1893, с. 478–481]. Ул татарлардан Спас өязендәге Кузнечиха авылы янында борынгы шәһәр урыны барлыгын ишетә һәм шул хакта җәмгыять секретаре профессор И.Н. Смирновка хәбәр итә. Секретарь тәкъдиме буенча Кузнечиха авылына барып, җирле халык ярдәме белән тикшеренүләр уздыра һәм әлеге урында борынгы Болгар шәһәре булганлыгын исбатлый. Г. Әхмәревнең шушы ачышыннан соң, аны Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп алалар. Ул 1893 елның 19 сентябреннән әлеге җәмгыятьтә – әгъза-хезмәткәр һәм 1904 елның 20 апреленнән эшлекле әгъза булып тора [Протоколы..., 1906].

«Хәбәрләр»дә дөнья күргән «Гөбнә елгасы буендагы Япанчы шәһәрлеге» исемле мәкаләсен ул Япанчы шәһәрлегенең географиясен сурәтләүдән башлый, үзенә мәгълүм булган кадәр шәһәрлекнең тарихын сөйли, халык арасында йөргән риваятьләрне дә укучыга

җиткерә [Ахмаров, 1894, с. 182]. Бу шәһәрлекнең тарихын аңлату өчен, Г. Әхмәревкә халык риваятьләре генә түгел, ә авылдашы хаҗи Хәмит Ишмөхәммәтевтән калган чыганаклар, рус тарихчыларының язмалары да ярдәм итә. Шунысын да әйтергә кирәк, Г. Әхмәревнең күпсанлы фәнни хезмәтләре арасыннан бары тик әлеге тикшеренүенең генә кулъязмасы безнең көннәргә килеп җиткән.

Галимнең җәмгыять җыелышында укылган тәфсилле докладларының кайберләре «Хәбәрләр»дә тулысынча басылмый да кала. Шундыйларның берсе – «1894 һәм 1895 еллдарда Казан губернасының Тәтеш һәм Спас өязләренә археологик һәм этнографик максат белән ясалган сәяхәт турында». Җәмгыятьнең 1895 елның 21 сентябрендә уздырылган җыелышында галим үзе катнаша алмаганлыктан, аның 74 биттән торган докладын җәмгыятьнең секретаре Н.Ф. Катанов укый. «Хәбәрләр»дә бары тик докладның төп нәтиҗәләре генә басыла. Кызганыч ки, бу хезмәтнең тулы тексты сакланмаган. Җыелышка йомгак ясап, Н.Ф. Катанов Г. Әхмәревнең экспедиция нәтиҗәләрен югары бәяли, аның тарихи кыйммәткә ия күп кенә әйберләр алып кайтуын ассызыклый. Ул тапкан 52 тарихи истәлек халыкка күрсәтелә һәм музейга тапшырыла [Ахмаров, 1899, с. 454].

Кызганычка каршы, «Тимер явына кадәр Болгар дәүләте», «Тимер һөҗүме турындагы татар риваятьләрен тикшерү» нәтиҗәләренең дә тулы тексты басылып чыкмау сәбәпле, алар фәнни әйләнешкә кертелә алмыйлар [Ахмаров, 1899, с. 450].

Әгъза-хезмәткәр Г. Әхмәревнең «Хәбәрләр»дә басылмаган янә бер хезмәте «Болгар ханлыгы турындагы татар риваятьләрен тикшерү» дип атала. Язма 1893–1894 елларда Казан губернасы Спас һәм Тәтеш өязләрендә башкарылган тикшерү нәтиҗәсе буларак туа. Анда ул, гарәп һәм татар язмаларына таянып, Болгар дәүләтендә ислам дине, Болгар дәүләтенең җимерелүе мәсьәләсенә кагыла [Протоколы..., 1899].

1909 елда җәмгыять каршында, Казан губернасының археологик һәм этнографик картасын төзү максаты белән, 13 кешедән торган махсус комиссия төзелә. Комиссия составына П.В. Кротов, Н.Ф. Высоцкий, М.М. Хомяков, И.В. Никольский, Г.И. Комиссаров, Е.А. Кузьмин, В.А. Карасев, С.А. Багина, О.А. Андреев, И.И. Аристов, П.М. Кунаев, А.С. Лебедов, Г.Н. Әхмәрев керә [Протоколы..., 1907]. Шушы максат белән тарихчы Зөя һәм Тәтеш өязләренә фәнни экспедицияләр оештыра. Сәфәрнең нәтиҗәләрен галим «1909 елда Казан губернасы Зөя һәм Тәтеш өязләренә оештырылган сәяхәтнең хисабы» дигән мәкаләсендә яктырткан. Үзенең эзләнүләре ярдәмендә ул С.М. Шпилевский, И.А. Износков хезмәтләрендәге хаталарны күрсәтә һәм төзәтүләр кертә [Протоколы..., 1907].

Г. Әхмәрев – этнография буенча да әһәмиятле хезмәтләр авторы. Аның һәрбер тарихи хезмәтендә этнографик күзәтүләр дә, тикшеренүләр дә бар. Җәмгыять хәбәрләрендә ул шушы темага багышланган өч зур хезмәтен тәкъдим итә. Шуларның берсе – хәзерге вакытта да галимнәр еш мөрәҗәгать итә торган «Мишәрләр һәм аларның

телләре» дигән күләмле һәм бай эчтәлекле мәкаләсе [Ахмаров, 1910, с. 91–160]. XX йөз башында, татар милләтенең үткәненә, киләчәгенә игътибар арткан чорда, татар матбугатында мишәрләр кемнәр, дигән сорау астында язмалар күренә башлый. Г. Әхмәрев тә, әлеге темага мөрәҗәгать итеп, махсус фәнни хезмәт яза. Галим искәртүенчә, ул бу мәкаләсендә мишәрләрне этнографик яктан һәрьяклап тасвирлауны максат итеп куймый, ә тел фактларына, гореф-гадәт һәм йолаларга таянып, аларның килеп чыгышын аңлатуны күз алдында тота. Хезмәттә ономастика, этнография буенча да бай мәгълүмат табарга мөмкин. Күренекле тарихчы Р. Фәхретдин, шушы хезмәт басылып чykканнан соң, аның әһәмиятен күрсәтеп, һәм үзенең канәгатьлек хисен белдереп, авторга хат җибәрә. Хатында ул мөселман халыклары арасында «типтәр» дигән кавемнең дә булуын әйтеп, шул хакта да тулырак мәгълүмат бирә алмассызмы дип мөрәҗәгать итә. Г. Әхмәрев Вятка губернасында эшләгән елларыннан ук типтәрләр белән таныш булган, өстәвенә 1906 елның җәендә аңа берничә ай алар арасында яшәргә дә туры килгән. Шуңа күрә галим типтәрләр турында шактый гына материал туплап өлгергән була. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1908 елда җәмгыять «Хәбәрләр»ендә «Типтәрләр һәи аларның килеп чыгышлары» дигән хезмәте басыла. Автор язуынча, ул бу хезмәтендә дә типтәрләрне этнографик яктан тасвирлауны максат итеп куймый, ә үзенә билгеле булган чыганакларга таянып, бары тик типтәрләр турындагы бәхәсле сорауларга күпмедер дәрәҗәдә ачыклык кертүне генә күз алдында тота [Известия, 1908, XXIII, вып. 5].

Г. Әхмәревнең татар һәм рус телләрен бер үк дәрәҗәдә яхшы белүе, аңа төрле характердагы чыганаклар белән эшләргә мөмкинлек биргән. Аның уенча, күпчелек рус тарихчылары татар тарихын, гореф-гадәтләрен тикшергәндә, тел белмәү сәбәпле, фәндә гафу ителмәслек тупас хаталар җибәргәннәр. Г. Әхмәрев К. Фуксның «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» [Фукс, 1844] дигән хезмәтендә югарыда әйтелгән сәбәп аркасында җибәрелгән хатаны да күрсәтеп, һәм үзенең тикшерену нәтиҗәләрен, туплаган тәҗрибәсен халыкка җиткерү максатыннан, татарларның зур бер төркеменә багышланган «Казан татарларының туй йолалары» дигән хезмәтен яза һәм җәмгыять «Хәбәрләр»ендә бастыра. Биредә ул Казан татарларының иң күркәм йолаларының берсе – туй үткәрү тәртибен, тарих белән бәйләп, төрле вариантларын күрсәтеп, тәфсилләп аңлатып бирә [Известия, 1907, XXIII т., вып. 5].

Г. Әхмәревнең Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә күренекле тарихчылар, этнографлар, телчеләр белән якыннан аралашуы, үзенең хезмәтләрен алар хөкеменә тәкъдим итеп, фикер алышулары аның галим буларак камилләшүенә гаять зур тәэсир ясый. Шуңа күрә ул үткән белән гадәти кызыксынучы гына түгел, бәлки тиз арада үз эшенең остасы булып җитешә.

Г. Әхмәрев мөгаллимлек һәм фәнни эшчәнлектән тыш, төрле җәмәгать эшләрен дә теләп башкарган. 1896 елдан Казан губернасы

мөгаллимнәренең үзара ярдәмләшү җәмгыятендә [ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 977 эш, 90а], 1907 елдан Казан җәмгыяте хәйриясендә әгъза булып торган [Отчёт Правления, 1908, с. 22]. Казан шәһәрендә 1906 елда эшли башлаган «Шәрык клубы»н оештыручыларның һәм аның иң эшлекле әгъзаларының берсе булган. 1908 елда идарә әгъзалыгына, клубның китапханә һәм фатир комиссияләренә сайланган. 1909 елдан башлап «Шәрык клубы» рәисе ярдәмчесе вазифаларын үтәгән, лекцияләр оештыру комиссиясе әгъзасы булып торган [Казан шәһәрендә..., 109, б. 3–5]. Аны тарихчы буларак танытkan ике зур хезмәте – «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» – нәкъ менә шушы җәмгыять утырышларында беренче мәртәбә халык хөкеменә тапшырылган. Матбугат битләрендәге хәбәрләрдән күренгәнчә, бу лекцияләрне тыңларга халык күп килгән һәм аның чыгышларын яратып кабул иткән [Казан тарихы..., 1909].

1906 елны ук ул тарих китапларының кирәклегенә басым ясап, тарих фәненең әһәмиятен күрсәтеп, «Ватан вә милләт тарихы хакында» дигән мәкаләсендә болай дип язган иде: «Асылымызны яхшылап тикшереп, милләтемез тарихын барлыкка чыгару өчен үземезгә тырышу лязим[1] буладыр. Тырышмый, эзләми никадәр торсак та, безгә тарих китапларын бирүче булмас. Иҗтиһад итсәк[2], иншалла, үземезнең кем икәнлегемезне белермез һәм гайре[3] милләтләргә дә аңлатырмыз. Дәхи ватан вә милләт тарихын да барлыкка чыгарырмыз» [Әхмәрев, 1906]. Г. Әхмәревнең татар халкының дәүләтләре тарихына багышланган «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» «Бәянелхак» нәшриятында аерым китаплар булып дөнья күрә. Матбугатта китаплар турында «...Гайнетдин әфәнде кебек гыйльме тарихка[4] маһир бер затның каләменнән чыккан тарих китапларына теш-тырнакларымыз беләнябышып укырмыз» [Казан тарихы..., 1909], диелә. Аны киң җәмәгатьчелеккә таныткан шушы ике хезмәте озак еллар буе җыелган, гомере буе өйрәнгән, тикшергән материаллар нигезендә туа. Алар галимнең бөтен тарихи эшчәнлегенең йомгакхисабы рәвешендә кабул ителә.

Г. Әхмәрев, тарихи тикшеренүләрен дәвам иттереп, «Шәрык клубы»нда «Сөембикә тарихы» дигән лекциясен дә укый. Г. Камал аның бу лекциясе турында болай дип яза: «...Гайнетдин әфәнденең Сөембикә хакында сөйләгән лекциясен тәртип итү өчен, күп китаплар актарырга, бик күп әсәрләрне карарга..., нәтиҗәләр чыгарганга кадәр бик күп мәшәкатьләр күрергә лязим идеке күрелде. Гайнетдин әфәнде бу мәшәкатьләрне, әлбәттә, күргән һәм башыннан кичергән. Ул үзенең ошбу кичәдә халыкка сөйләгән тарихын вөҗүдкә китерү

[1] Лязим – тиеш.
[2] Иҗтиһад итсәк – тырышсак.
[3] Гайре – башка, бүтән.
[4] Гыйльме тарих – тарих гыйлеме

өчен асаре гатыйка җәмгыятенә[1] әгъза булып, ничә еллар асаре гатыйка тәфтишләре илә мәшгуль булган, никадәр рус тарихчыларын укып чыккан һәм шуның соңында гына ошбу лекцияне сөйләрлек дәрәҗәгә китереп чыгарган» [Камал Г., 1910]. Матбугаттагы хәбәрләрдән күренгәнчә, аның бу лекциясе аерым китап итеп тә бастырылырга тиеш була, галимнең гомере кыска булу сәбәпле, дөнья күрми кала.

Хәзерге вакытка Г. Әхмәревнең барлыгы 44 хезмәте билгеле, шуларның 23 е – газета мәкаләләре. Соңгылары татар тарихындагы төрле проблемаларны анализлауга багышланган. Аларның һәрберсен аерым бер тикшеренү дип кабул итәргә мөмкин.

Г. Әхмәрев кыска гына гомере эчендә үзен тарихчы, педагог, этнограф һәм җәмәгать эшлеклесе итеп таныта. Аның фикерләре хәзерге чорда да актуаль, мирасы галимнәребезнең тәфсилле тикшеренүләрен көтә. Г. Әхмәрев хезмәтләренә күренекле тел галиме Мөхетдин Корбангалиев биргән бәя аның бөтен эшчәнлегенең мөһимлеген билгеле. «Без аны милли тарихымызга нигез салучы чын татар мөаррихе дияргә җөрьәт итәмез, һәм дә исеме тарих сәхифәләрендә алтын кара белән язылып калырга тиешле мөхтәрәм бер зат, дия беләмез» [М.Къ, 1911].

### Әдәбият

*Ахмаров Г.* Городище Япанчино на реке Кубне // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском университете. Казань, 1894. Т. XII. Вып. 2. С. 182.

*Ахмаров Г.* Заметки происхождения нескольких кладбищ при татарских селениях Волжского-Камского края // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском университете. Казань, 1893. Т. XI. Вып. 3. С. 277–278.

*Ахмаров Г.* История Болгарского царства до времени нашествия Тимура // Известия Общества археологии, истории и этнографии: Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии, 1899. Т. XV. Вып. 4. С. 450.

*Ахмаров Г.* О языке и народностей мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском университете. Казань, 1893. Т. XIX. Вып. 2. С. 91–160.

*Ахмаров Г.* Разбор татарских сказаний о нашествии Тимура на Болгарские города // Известия Общества археологии, истории и этнографии, 1899. Т. XV. Вып. 4. С. 454.

*Ахмаров Г.* Тептяри и их происхождение // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском университете. Казань, 1908. Т. XXIII. Вып. 5. С. 340–364.

*Ахмаров Г.* Экскурсия на место древнего Сувара // Известия Общества археологии, истории и этнографии, 1893. Т. XI. Вып. 5. С. 478–481.

*Әхмәрев Г.* Әлифба китапларына тәнкыйть. Казан: Мәгариф, 1909.

*Әхмәрев Г.* Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. 1906. 12, 14 апр.

---

[1] Гатыйка җәмгыяте – Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте.

Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. М: Наука, 1889.

Казан тарихы хакында лекция // Бәянелхак. 1909. 15 фев.

Казан хәбәрләре // Йолдыз. 1911. 22 сентябрь.

Казан шәһәрендә торучы мөселманнар җәмгыяте «Шәрык клубы»ның 1907/08 сәнәләр өчен хисабы. Казан, 1909.

*Камал Г.* Кеше тавыгы күркә // Йолдыз. 1910. 10 март.

Киров өлкәсенең дәүләт архивы (КӨ ДА). 205 ф., 2 тасв., 1880 эш.

*М.Къ.* [Мөхетдин Корбангалиев]. Мөгаллим вә мөәррих Гайнетдин бине Нәҗметдин Әхмәревнең тәрҗемәи хәле // Йолдыз. 1911. 13 окт.

Обзор учебников, принятых к употреблению в татарских конфессиональных школах (мектебе и медресе) и изданных большой частью за последние 3 года (1911–1913). Казань: Центральная типография, 1917.

Отчёт Правления Общества пособия бедным мусульманам г. Казани, со состоящими при нем богодельней, приютом и начальной женской школой (мектебе) за 1907 год. Казань, 1908.

Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии за 1898 г. // Известия Общества археологии, истории и этнографии, 1899. Т. XV. Вып. 4.

Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии за 1906 г. // Известия Общества археологии, истории и этнографии, 1907. Т. XXIII. Вып. 6.

Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии за 1909 г. // Известия Общества археологии, истории и этнографии, 1910. Т. XXVI. Вып. 4.

Татарстан республикасының Дәүләт архивы (ТР ДА). 160 ф., 1 тасв., 1017 эш.

ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1067 эш.

ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1461 эш.

ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 815 эш.

ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 907 эш.

ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 977 эш.

*Тукай Г.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Мәгариф, 1919.

*Фукс К.* Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1844. 131 с.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 372.8

*Л.Т. Мөхәммәтшина*

# УКУЧЫЛАРНЫҢ ФӘННИ ТИКШЕРЕНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ БЕЛЕШМӘ ӘДӘБИЯТНЫ КУЛЛАНУ
## («Татарстан Республикасы торак пунктлары» энциклопедиясе мисалында)

В статье проанализированы различные формы использования материалов иллюстрированной энциклопедии «Населённые пункты Республики Татарстан» при написании научно-исследовательских работ учащихся: от прямого цитирования представленных в ней сведений до сравнительной характеристики социокультурного пространства населённых пунктов республики; применения имеющейся в энциклопедии библиографии в качестве базы для дальнейших исследований. Делается вывод о необходимости обращения учащихся к справочной литературе для освоения ими норм научного стиля и выработки навыков работы с источниками.

**Ключевые слова:** краеведение, регионоведение, энциклопедия, населенные пункты Республики Татарстан, научно-исследовательская деятельность учащихся.

The article analyzes various forms of using the materials of the illustrated encyclopedia «Inhabited localities of the Republic of Tatarstan» when writing research papers of students: from direct citation of the information presented in it to a comparative description of the socio-cultural space of inhabited localities of the republic; using of the bibliography in the encyclopedia as a base for further research. The conclusion is made about the necessity for students of using reference books to acquire the norms of academic style and develop skills in working with sources.

**Keywords:** area studies, regional studies, encyclopedia, inhabited localities of the Republic of Tatarstan, students' research activities.

Бүгенге көндә уку-укыту өлкәсендә ике юнәлешле үсеш тенденциясе күзәтелә. Бер яктан, укучылар белем бирү ресурсларыннан, төрле мәгълүматтан файдалана ала. Аларның үзлегеннән укып белем алу мөмкинлекләре дә зур. Шул ук вакытта хәзерге заман укучысы өчен күләмле мәгълүматны истә калдыру (гел «кул астында» булганлыктан, аны саклау зарурлыгы юк, шул сәбәпле озак вакытлар истә тотарга кирәкми дә), анализлау һәм гамәли эшчәнлектә куллану авыр. Әлеге шартларда иҗади, эзләнүчән, фикерләү сәләтенә ия шәхес тәрбияләү максатында проблемалы ситуация тудыру укытучының бурычы булып тора. Шул очракта гына укучылар белемнәренең җитмәвен яхшы аңлый, аларны тулыландырырга омтыла.

Тарих дәресләрендә мәктәп балаларында яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру алымнарының берсе – туган якны өйрәнү. Әгәр совет чорында туган якны тикшерү ысуллары тәрбияви максатларда кулланылса, хәзерге көндә алар танып белү эшчәнлеген

үстерүдә һәм укучыларда үзләренең кыйммәтләр системасын булдыруда төп урынны алып тора [Будяченко; Седельникова; Сейненский]. Мәктәп балаларына туган якны өйрәтү эшен шартлы рәвештә өч баскычка бүлеп карарга мөмкин: беренче чиратта, «әзер» белемне үзләштерү; икенчедән, укучыларның нинди дә булса мәгълүматны мөстәкыйль эзләп табуы (бу аларның танып белү эшчәнлеген актив үстерә); өченче баскыч балаларның төбәкне өйрәнү материалларын тирәнтен тикшерүен (шул исәптән фәнни тикшеренү эшләрен алып барганда да) күз уңында тота.

Йомгаклау аттестациясенең Төп дәүләт имтиханы һәм Бердәм дәүләт имтиханы кебек формалары укытучының туган як турында белешмәләрне уку-укыту процессында актив куллануына ярдәм итми дә кебек. Әмма төбәкләрдә мәктәп укучыларының фәнни-гамәли конференцияләрен уздыру укучыларны фәнни тикшеренү эшчәнлегенә җәлеп итүдә киң таралган ысулларның берсе булып тора. Аерым алганда, Татарстан Республикасында һәм аннан читтә 1980 елдан бирле үткәрелә торган Н.И. Лобачевский исемендәге Бөтенроссия (Идел буе) укучылар фәнни конференциясе күпләргә яхшы билгеле. Конференциядә җиңүчеләрнең һәм призлы урыннарга лаек булучыларның (XI сыйныф укучылары) Казан федераль университетына укырга кергәндә Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләренә өстәмә баллар алуы укучылар өчен өстәмә кызыксындыру чарасы да булып тора [Научная конференция...].

Конференциядә катнашучыларның саны елдан-ел арта бара. Бу исә темалар сайлаганда педагоглардан аерым игътибар таләп итә, укучыларны чыгыш ясауга тагын да яхшырак итеп әзерләү, аларда фәнни тикшеренү эшчәнлеге күнекмәләрен үстерү-ныгыту бурычларын куя. Шушы әзерлек компонентларының берсе – белешмә әдәбият белән эшләү. Кагыйдә буларак, сүзлекләргә һәм төрле белешмәлекләргә терминнар һәм төшенчәләрнең мәгънәләрен ачыклау, тикшеренү эше предметын билгеләү өчен, фәнни темага чыгыш әзерли башлаган этапта мөрәҗәгать ителә. Шуның белән алардан файдалану тәмамлана. Әлеге мәкаләдә без Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан әзерләнә торган «Татарстан Республикасы торак пунктлары» иллюстрацияле энциклопедиясе мисалында мондый төр басмаларны куллануның башка юнәлешләрен дә карарбыз.

«Татарстан Республикасы торак пунктлары» энциклопедиясе – республика торак пунктлары тарихын, аларның хәзерге торышын һәм тарихи-мәдәни үзенчәлеген ачыклауга багышланган беренче комплекслы басма. Беренче томга Татарстанның 14 районы (А–Б хәрефләре) турында мәгълүмат кертелгән. Һәр бүлек район һәм район үзәге турында мәкаләләр белән башланып китә, алга таба алфавит тәртибендә башка торак пунктлар хакында мәгълүматлар китерелә. Мәкаләләрнең үзләрен шартлы рәвештә ике өлешкә бүлергә мөмкин: тарихи өлештә җирлекләрнең исемен алыштыру, аларның оешу чоры һәм

нигез салучылары (булган очракта), халык составы, әлеге торак пунктка хас хуҗалык эшчәнлеге, кәсепләр һәм һөнәрләр турында белешмә урын ала. Ул чорның төп архитектура ядкярләре, белем бирү учреждениеләре хакында кыскача информация бирелә. 1917 елгы революциядән соңгы чор тасвирланганда, торак пунктның кайсы административ берәмлеккә керүе, күмәк хуҗалыклар төзелү, белем бирү учреждениеләре, музейлар, китапханәләр ачылу вакыты күрсәтелә; архитектура истәлекләре барлана. Мәкаләләрдә җирлекләрдәге мәдәниятнең, мәгариф һәм медицинаның хәзерге торышы, гамәлдәге мәчетләр һәм чиркәүләр турында да сөйләнә. Әлеге торак пунктларда туып-үскән күренекле кешеләр, шулай ук аларның шәхес буларак формалашуына зур өлеш керткән, йогынты ясаган якташлары турында да укып белергә мөмкин. Китапта халык санының XVIII гасыр ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәрге үзгәреше динамикада күрсәтелә.

Мәгълүм ки, туган якны өйрәнү материалларын җәлеп итү укучыларның үзләренә аңлаешлы, билгеле фактлар һәм күренешләр аша тирәнтен тарихи гомумиләштерүләрне, гомумроссия тенденцияләрен тикшерүне күз уңында тота. Энциклопедиядә күрсәтелгән тарихи белешмәләргә таянып, халыкның теге яисә бу районга килеп урнашу тарихын, аның милли составын анализларга, нинди дә булса кәсепләрнең һәм һөнәрләрнең ни өчен шушы җирлектә үсеш алганын нигезләргә була. Мәсәлән, Базарлы Матак авылы (Әлки районы үзәге) халкының күпмилләтле составы бу территориядә XVIII гасыр башында иң элек чувашларның, аннары русларның, шул исәптән расколчы-староверларның килеп урнашуына бәйле. Татарлар совет чорында гына авыл халкының күпчелеген тәшкил итә башлый. Әлки районы җирләре күбесенчә кара һәм соры урман туфраклы, шунлыктан монда элек-электән авыл хуҗалыгы юнәлеше өстенлек иткән. Урманнар аз булу сәбәпле, традицион һөнәрләр киң таралмаган, аның каравы сәүдә актив үсеш алган: Покров һәм Никольский ярминкәләре уздырылган. Чагыштырма этнографик тикшеренүләр дә кызыклы, мисал өчен, Әлки һәм Актаныш районнарында яшәүче халыкларны карыйк. Араларында типтәрләр һәм вотчиналы башкортлар күпчелекне тәшкил иткән Актаныш халкы умартачылык белән шөгыльләнгән, көнлекле эштә хезмәт куйган. Шулай ук урман кисү, киез итек басу, чыпта ясау һөнәрләре дә киң таралган. Актаныш районы торак пунктлары тасвирламаларында «Изге Гурий туганлыгы» мәктәпләре яисә яңа керәшен мәктәпләре ачылу хакында мәгълүмат табып булмаячак, аның каравы райондагы 87 җирлекнең 25 ендәге халык 1773–1775 еллардагы Крестьян сугышында Е.И. Пугачёв тарафдарлары ягында көрәшә (мәсәлән, Әтәс авылыннан Мөхәммәтрәхим Йосыпов, Атнагул Тимеров җитәкчелегендәге отрядта – Түбән Гәрәй авылы кешеләре, А. Ягъфәров отряды составында Түке авылыннан 13 кеше катнаша). Торак пунктларның социомәдәни торышын характерлауда энциклопедия мәкаләләрендә тәкъдим ителгән халык саны үзгәреше статистикасы да ярдәм итә. Укучыларның

фәнни эшләрендә илдәге тарихи вакыйгаларга (Идел буендагы ачлык, коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы һ.б.) карап халык санының үзгәрүен, авылларның юкка чыгу процессының асылында нинди сәбәпләр ятуын ачыклау кызык булыр иде. Торак пунктларның социомәдәни йөзе җирлекнең истәлекле урыннарын, гамәлдәге чиркәүләрне һәм мәчетләрне өйрәнмичә генә тулы була алмый, энциклопедиядә аларның элеккеге һәм хәзерге фоторәсемнәре урнаштырылган. Һичшиксез, бер басма, хәтта ул өч томнан торса да, туган якны һәм төбәкне өйрәнү барышында тупланган мәгълүматның бөтенесен дә сыйдыра алмый. Шуңа күрә һәр бүлектә район һәм аның торак пунктлары турында бай әдәбият исемлеге бирелә. Нәкъ менә шушы исемлек алга таба тикшеренүләр алып барырга ярдәм итәчәк.

«Татарстан Республикасы торак пунктлары» энциклопедиясе үзенә республика җирлекләре турында күпьяклы мәгълүматны туплаган, һәм укучылар аны фәнни эшләрен язганда белешмәлек буларак кына түгел, ә гыйльми база итеп тә куллана ала. Җирле материал тарихи үткәннәр һәм хәзерге заман арасында бәйләнеш табарга, Татарстан авылларының тарихи-мәдәни потенциалын характерларга ярдәм итә. Моннан тыш, энциклопедик мәкаләләрне өйрәнү мәктәп балаларына фәнни стиль нормаларын үзләштерергә, аларны чыганаклар белән эшләү күнекмәләренә өйрәтергә дә булыша.

**Әдәбият**

*Будяченко М.В.* Краеведение как один из способов повышения эффективности воспитательной деятельности в системе школьного исторического образования // Профессионально-педагогическая культура: стратегия развития воспитания: материалы Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием (г. Белгород, 25–26 февр. 2016 г.). Белгород: ИД «Белгород» НИУ «БелГУ», 2016. С. 35–37.

Научная конференция учащихся имени Н.И. Лобачевского [Электронный ресурс]. URL: https://kpfu.ru/edu/dovuzovskoe-obrazovanie-v-kfu/centr-dovuzovskogo-obrazovaniya/povolzhskaya-nauchnaya-konferenciya-uchaschihsya (дата обращения: 09.10.2018).

*Седельникова Н.А.* Значение и основные задачи исторического краеведения в современном школьном историческом образовании // Сельские территории: проблемы и перспективы устойчивого развития: материалы Междунар. науч.-практ. конф. Тара: Изд-во ФГБОУ ВО Омский ГАУ, 2017. С. 53–57.

*Сейненский А.Е.* Краеведение в школьном историческом образовании // Преподавание истории и обществознания в школе. 2004. № 10. С. 19–28.

***Мөхәммәтшина Лилия Тәлгать кызы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 371.3

***Р.Ф. Фәттахова***

# БЕЛЕМНӘРНЕ СИСТЕМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ГОМУМИЛӘШТЕРҮ ДӘРЕСЕ

В статье ставится задача рассмотреть особенности проведения уроков систематизации знаний: освещаются цели, описываются примерная структура, приёмы и методы проведения, формы урока. Урок систематизации и обобщения знаний является сравнительно новым типом урока, и зачастую учителя проводят его, используя традиционные методы обучения. В настоящее время необходимо осуществлять переход от информационно-объяснительных методов обучения к деятельностным, развивающим методам. Статья предназначена для учителей, осуществляющих работу по ФГОС.

**Ключевые слова:** уроки систематизации и обобщения знаний, системно-деятельностный подход, требования к урокам, педагогические методы и приёмы, структура урока.

The article aims to consider the features of conducting lessons of knowledge systematization: the goals are highlighted, the approximate structure, techniques and methods of conducting of the lesson, its forms are described. The lesson of systematization and generalization of knowledge is a relatively new type of lesson, but teachers often conduct it using traditional teaching methods. At present, it is necessary to make the transition from information-explanatory teaching methods to activity-based, developing methods. The article is intended for teachers carrying out work on the Federal Educational Standard.

**Keywords:** lessons of systematization and generalization of knowledge, system-activity approach, requirements for lessons, pedagogical methods and techniques, lesson structure.

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системалы-эшчәнлекле юнәлешкә корыла һәм ул мәктәптә барлык фәннәрне, шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын укытуга да кагыла. Укыту барышында әлеге юнәлеш укучыларның белем алу эшчәнлеген актив, төрле яклы, максималь дәрәҗәдә мөстәкыйль, тиешле нәтиҗәгә ирешерлек итеп планлаштырырга һәм оештырырга ярдәм итә, укучы шәхесенең рухи потенциалын үстерергә, иҗади сәләтен ачарга, уку предметына кызыксыну уятырга ярдәм итә. Укытучы дәрестә яңа белемнәрне әзер килеш бирми, укучыларның белемнәрне «ачу» эшчәнлеген оештыра. Бу иҗади процесста укучының белем дәрәҗәсе арту, фикерләү сәләте үсү, индивидуаль үзенчәлекләре камилләшү белән берлектә, аңа тормышта үз урынын табарга мөмкинлек бирәчәк эшчәнлек сыйфатлары да барлыкка килә: максат кую, максатка ирешү юлларын мөстәкыйль табу, эшне планлаштыру һәм оештыру, фикерли, анализлый, чагыштыра һәм гомумиләштерә белү, эш нәтиҗәләрен адекват бәяләү, эшнең барышы һәм нәтиҗәсе өчен җаваплылык сизү, командада эшли алу, үз фикерен әйтү һәм

дәлилләү һ. б. Шулай итеп, белем бирүдә системалы-эшчәнлекле юнәлешне куллану предмет буенча белемнәрне үзләштерүнең сыйфатын күтәререргә, укыту барышын яңача оештырырга һәм яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә булыша. Әлеге юнәлеш белем бирүдә традицион методларны инкяр итми, бары шул җирлектә заманча белем бирү максатларын тормышка ашырганда яңа эшчәнлек төрләрен, укыту технологияләрен куллануны алга чыгара. К.Д. Ушинскийның: «Балалар мөмкин кадәр мөстәкыйль укысыннар, ә укытучы бу процесс белән идарә итсен һәм юнәлеш бирсен», – дигән сүзләре хәзерге заман дәресенең асылын ачып бирә.

ФДБС белем бирүдә баланың шәхесе үсеше мәсьәләсен алгы планга чыгара. Шуңа күрә яңа стандартлар нигезендә оештырылган дәресләргә түбәндәге таләпләр куела:

– дәрескә уңай мотивация булдыру;

– дәреснең максатчанлыгы, универсаль уку гамәлләре формалашу өчен төпле җирлек булу;

– дәресләр, дәрес этаплары арасында бәйләнешне тәэмин итү, һәр этапның нәтиҗә белән тәмамлануы;

– парлап һәм төркемдә эшләүне оештыру (коллектив эш нормаларын үзләштерү һәм коммуникатив компетенцияләрне үстерү);

– танып белү эшчәнлеге барышында укучыларның мөстәкыйль эшчәнлекләрен күз алдында тоткан блокларның булуы;

– дәрестә техник чаралар куллану;

– дәрестә бирелгән белемнәрнең гамәли әһәмиятен төгәл билгеләү (үзләштерелгән белемнәрнең гамәлдә куллану мөмкинлеген ассызыклау);

– рефлексия алымнары, мөстәкыйль эшләү һәм аның нәтиҗәләре өчен җаваплылык формалаштыру;

– укучыларның һәр төр эшчәнлегенә сыйфатлы уңай бәя бирү (уңай уку мотивациясе формалаштыруга этәрү);

– өй эшләренең күләмен минимальләштерү һәм өч вариантта тәкъдим итү;

– дәрестә сәламәтлек саклау өчен шартлар булдыру.

Системалы-эшчәнлекле юнәлеш кысаларында дүрт дәрес тибы, шул исәптән белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресләре үткәрү каралган. Бу тип дәрес башкача гомуми методик юнәлешле дәрес дип тә атала һәм зур тема, бүлек яки блокны өйрәнү вакытында яки аны тәмамлаганнан соң үткәрелә.

ФДБС шартларында белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресләренең максатлары: тема (бүлек, блок) буенча укучыларның белем дәрәҗәсен ачыклау; белемнәрне актуальләштерү, системалаштыру, гомумиләштерү. Әлеге тип дәресләрдә укучыларның гомуми культурасын үстерү, үз-үзләрен бәяләү өчен шартлар тудыру, фикерләү, иҗади сәләтләрен, төркемдә эшләү күнекмәләрен формалаштыру, танып белүгә кызыксыну уяту, лидерлык сыйфатлары тәрбияләү, үзанализ, чагыштыру, аралашу күнекмәләре, бе-

лемнәрне системалаштыру осталыгы булдыру юнәлешендә эшчәнлек алып барыла.

Бу тип дәресләрне традицион укыту алымнарын һәм ысулларын кулланып үткәргәндә, дәрес *«ишеттем → истә калдырдым → сөйләп бирдем»* схемасына корыла. ФДБСта мондый схемадан баш тартырга һәм укучының актив позициясен алгы планга куйган яңа алгоритмга күчәргә кирәклек ассызыклана. Хәзерге таләпләрдән чыгып белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресе түбәндәге схемага нигезләнгән булырга тиеш: *«белемне кабул итү һәм аерым фактларны аңлау → әлеге фактларны гомумиләштерү → төшенчә барлыкка китерү һәм белемнәрне системалаштыру → белемнәрне тирәнәйтү»*.

Димәк, тема буенча белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү материалны аңлатып бирү рәвешендә генә түгел, ә эшлекле, үстерелешле белем бирү принципларына нигезләнеп алып барылырга тиеш.

Гомуми методик юнәлешле дәресләрдә төрле эш алымнары (әңгәмә, бәхәс, лаборатор эшләр, күнегүләр эшләү, рецензия язу, проект эшләре яклау) кулланыла, шуннан чыгып дәрес төрләре дә берничә була ала: лекция-дәрес, семинар-дәрес, практикум, консультация-дәрес, әңгәмә-дәрес, диспут-дәрес, уен (КВН, конкурс, викторина), конференция, театральләштерелгән дәрес (суд-дәрес), сәяхәт-дәрес. Дәрестә репродуктив-эзләнү, өлешчә эзләнү, иҗади методларны куллану белем алу процессының нәтиҗәлелеген арттырачак. Алган белемнәрне яңа шартларда куллану мөмкинлеген тудыру укучыларның белемнәрен тирәнәйтергә, иҗади осталыкларын үстерергә һәм белемнәрнең гамәли әһәмиятен тоярга ярдәм итәчәк.

Әлеге тип дәресләргә әзерләнгәндә, күрсәтмәлелеккә игътибарлы булу зарур. Тема буенча белемнәрне гомумиләштерү һәм конкретлаштыруга юнәлдерелгән графиклар, таблицалар, схемалар, диаграммалар, рәсемнәр, модельләр, карталар өстендә эш этаплап алып барыла, һәр графикны яки схеманы тикшергәндә аерым аспектларның үзара бәйләнешен ассызыклау, төп төшенчәләрне атау, теге яки бу фактларны чагыштыру, аларның охшаш һәм аермалы билгеләрен табу эшчәнлеге оештырыла.

Актуальләштерү яки белемнәрне беренчел ныгыту этапларында аудио- һәм видео материаллар, диафильмнар, өйрәтү фильмнары, нәфис яки документаль фильм фрагментлары һ. б. күрсәтү отышлы. Аларны караганнан соң, укучылар, эчтәлекне сөйләп яки сюжеты турында фикер алышып кына калмыйча, дәреслек материалы, үзләренең белемнәре белән дә бәйләнешне чагылдырырга тиешләр.

Белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресе түбәндәге төзелешкә ия.

**1. Оештыру этабы (үзбилгеләнеш).**

Дәрес башында укучыларда дәрескә уңай мотивация булдырыла, сыйныфта яхшы психологик халәт тудырыла. Моның өчен

һәр укытучының арсеналында үз алымнары бар: сүз белән сәламләү, аутотренинг, музыка тыңлау, дәрескә эпиграф уку, цитаталар, мәкаль-әйтемнәр, канатлы фразалар әйтү, һава торышы турында сөйләшеп алу, комплиментлар әйтү һ. б. Әлеге этапта кулланылган материал дәреснең алдагы эчтәлегенә туры килергә һәм аңа төпле җирлек булып хезмәт итәргә тиеш.

**2. Белемнәрне актуальләштерү һәм авырлыкларны билгеләү этабы.**

Бу өлештә теманы, бүлекне өйрәнү вакытында барлыкка килгән төп проблемалар барлана. Әлеге этапның максаты – укучыларның, укытучы тәкъдим иткән биремнәрне эшләп, үз белемнәренең кысаларын билгеләвенә, авырлыкларны, проблемаларны ачыклавына ирешү.

Укытучы укучыларга алдагы дәресләрдә алган белемнәрне һәм күнекмәләрне искә төшерүгә һәм гамәлдә куллануга юнәлтелгән берничә гади эш төре (биремнәр, күнегүләр) тәкъдим итә (биремнәр күләме буенча зур түгел, 5–7 минутка исәпләнгән булырга тиеш):

– «ассоциатив рәт» (өйрәнелә торган тема тудырган ассоциацияләрне санау (төшенчәләр, образлар, идеяләр, фразалар, истәлекләр, хисләр һ. б.);

– сораулар бирү (редуктив һәм иҗади характерда);

– «Хата тап!»;

– тест эшләү (стандарт һәм логик фикерләүгә яки чагыштыруга корылган тестлар. Мәсәлән, төшенчәләрне тәңгәл китерү, логик чылбыр төзү);

– «ачкыч терминнар» (тема буенча иң мөһим һәм истә кала торган терминнарны әйтү (саны конкрет бирелергә мөмкин, мәсәлән, биш), аларның өйрәнелә яки кабатлана торган тема кысаларында әһәмиятен ачыклау, бәхәсләшү);

– Кроссенс алымы (тугыз рәсемнән торган ассоциатив чылбырлы башваткыч чишү);

– Блум кубигы (тема буенча белемнәрне аңлату, куллану, анализлау, синтезлау, бәяләү);

– проблемалы ситуация тудыру яки проблемалы сорау бирү;

– дидактик уеннар.

**3. Уку мәсьәләсен кую һәм ситуациядән чыгу проектын төзү этабы.**

Бу этапта укытучының бурычы – укучыда биремнәрне эшләү барышында килеп туган авырлыкларны танырга ярдәм итү, аларны бетерү планын (проектын) төзүгә этәрү (укучылар дәресне планлаштыралар).

Ситуациядән чыгу проектын билгеле бер план буенча башкару уңайлы:

– укучы биремнәрне эшләү вакытында туган проблеманы күрә, хатасын таба;

– укучы хатаның кайсы тема белән бәйле булуын ачыклый (бу яңа темамы әллә элегрәк үткән темамы);

– укучы проблеманы хәл итү юлын эзли: кирәкле кагыйдәне табу, сүзлек, белешмә, терәк, күрсәтмә материаллар белән эшләү, үткән теманы кабатлау, алда эшләгәннәргә охшаган күнегүләр эшләү, интернет ресурсларга мөрәҗәгать итү һ. б.

Әлеге этапта эшлекле уеннар, пресс-конференция, фикер алышулар, бәхәс отышлы булып санала.

**4. Проектны тормышка ашыру этабы.**

Укучылар үзләре төзегән проектның гамәлдә ни дәрәҗәдә уңышлы икәнен тикшерәләр.

Әлеге этапта башкарылган эш төрләре укучыларның белемнәрен һәм күнекмәләрен искә төшереп гомумиләштерүгә, системага салуга китерергә, гамәлдә куллана алу мөмкинлеген күрсәтергә тиеш.

Дәреслек белән эшләү уңышлы була ала: тезислар язу, конспектлау, дәреслектә бирелгән мәгълүматны таблицага тутыру, белемнәрне графиклар, схемалар рәвешендә гомумиләштерү (модельләштерү) һ. б.

**5. Ныгыту этабы.**

Әлеге этапның максаты – үзләштергән белемнәрне яңа шартларда, гамәлдә куллану. Шуңа күрә укытучы, биремнәрне төзегәндә, аларның белем һәм күнекмәләрне гомумиләштерү, системага салу мөмкинлеген күздә тотып эш итә, шулай ук биремнәр теманың практик яктан әһәмиятен дә ассызыкларга тиеш. Биремнәр шулай ук белемнәрне яңа шартларда куллану мөмкинлеген дә истә тотып төзелә. Мәсәлән, «Сөйләм стиле» темасы өйрәнелгән икән, хатлар стилен һәм СМСлар телен чагыштырырга, аларга хас үзенчәлекләрне атарга тәкъдим итәргә мөмкин.

**6. Мөстәкыйль эш һәм эталон буенча тикшерү.**

Бу этапта уку материалын бербөтен система итеп күрсәтү, теманы ныгыту максаты куела. Укучыларга түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителергә мөмкин:

– алгоритм төзү;

– карточкалар белән эшләү;

– тикшерену эшләре яки мини-проектлар;

– «реставратор» (укытучы бозып яки кыскартып биргән текстны төзәтү);

– «Фишбоун» (тема буенча проблеманы, сәбәп-максат бәйләнешләрен, аерым фактларны, нәтиҗәне график чагылдыру);

– сорашу;

– интеллект (менталь) карта (теманы структуралаштыру буенча схема, карта төзү).

Укучылар, мөстәкыйль эш эшләгәннән соң, укытучы биргән өлгегә нигезләнеп, үзконтроль һәм үзтикшерү эше башкаралар.

**7. Рефлексия.**

Дәреснең ахыргы этабында уку эшчәнлегенә йомгак ясала, нәтиҗәләр чыгарыла. Укучылар үзләренең дәрестәге эшчәнлекләрен бәялиләр, нәтиҗәләр ясыйлар, билгеләр куялар. Рефлексиядә инсерт, кластер, «светофор», «алты эшләпә» алымнарын куллану отышлы булачак.

Сыйныфның үзенчәлегенә, теманың катлаулылыгына карап, гамәлдә гомуми методик юнәлешле дәресләр төзелешләре, үткәрү формалары буенча бер-берсеннән аерылырга мөмкин. Һәр укытучы, үз предметыннан һәм дәрескә куелган максатлардан чыгып, дәрес схемасын җайлаштырып төзи.

**Әдәбият**

*Кудрявцева Н.Г.* Системно-деятельностный подход как механизм реализации ФГОС нового поколения // Справочник заместителя директора школы. 2011. № 4. С. 13–30.

Новый взгляд на урок с учётом ФГОС. Конструирование на основе современных образовательных технологий. ФГОС. М.: СИНТЕГ, 2014. 346 с.

Примерная основная образовательная программа образовательного учреждения. Основная школа / сост. Е. С. Савинов. М.: Просвещение, 2011. 342 с.

*Ушинский К.Д.* Собрание сочинений. М., 1985. Т. 2. 67 с.

Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования / М-во образования и науки Рос. Федерации. М.: Просвещение, 2011. 48 с.

Фундаментальное ядро содержания общего образования / под ред. В.В. Козлова, А.М. Кодакова. М.: Просвещение, 2010. 59 с.

***Фәттахова Рузилә Фирдәвес кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 730

*Т.Н. Кривошеева*

# КАЗАН СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ СКУЛЬПТУРА УКЫТУДА КӨНБАТЫШ ЕВРОПА ҺӘМ ШӘРЫК МӘКТӘПЛӘРЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Статья посвящена межкультурной, межэтнической коммуникации региона, отражённой в педагогической деятельности одного из старейших творческих учебных заведений республики – Казанского художественного училища имени Н. Фешина.

**Ключевые слова:** скульптура, пластика, этнос, школа.

The article is devoted to the intercultural, interethnic communication of the region, reflected in the pedagogical activity of one of the oldest creative educational institutions of the republic – Kazan Art School named after N. Feshin.

**Keywords:** sculpture, plastic arts, ethnos, school.

Хәзерге вакытта Казан сәнгать училищесы һәм Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтының скульптура бүлекләрендә сынчыларның яңа буыны әзерләнә. Аларга нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен, техник һәм матди мөмкинлекләр тудыру белән беррәттән, иҗади эзләнү һәм мәдәни мохиттә үзенчәлекле үз урыныңны табу-танылу максатында, үткәндәге тәҗрибәне аңлау-төшенү дә кирәк.

Үсеш юлын карасак, татар скульптурасының тарихы шактый катлаулы юл узган: хакимлек иткән дини һәм идеологик карашлар басымы астында озак вакытлар дәвамында иҗат процессы бик нык чикләнгән.

Стиль барлыкка китергән тенденцияләр буларак төп ике сәнгать традициясенә тукталыйк: академик реализмга (Европа мәктәбе) һәм этник (Шәрык, «борынгы төрки») юнәлешкә.

XX гасыр башында Казан сәнгать мәктәбе каршындагы (алга таба КСМ) скульптура бүлеген республикада скульптура белемен кертү өлкәсендә үзенең көчле һәм революционлыгы ягыннан беренче уникаль тәҗрибә дип карарга кирәк. Ул Петербург сәнгать академиясендә пластика укыту тенденцияләренә таянган. Бүлекнең әлеге чор эшчәнлегендә укытучылардан П. Дзюбанов һәм В. Богатырев үзенчәлекле эз калдырган (Т.Н. Кривошеева, 2006)

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Казан сәнгать-педагогика техникумында (КСМнең күп тапкырлар үзгәртелгән исемнәренең берсе) белем бирүне халык хуҗалыгы өчен кирәкле сәнгать төре юнәлешендә оештырырга тәкъдим итеlә. «Ялгыз талантлар турында түгел, ә массачыл уртакул мәдәният турында уйларга кирәк», – бу юллар сәнгать белеме буенча методкомиссия утырышында яңгыраган чыгыштан. 1926 елда КСМ Казан берләштерелгән сәнгать-театр

техникумы буларак эшли. Шушы техникумда методик комиссия утырышларының берсендә (нәкъ менә 1926 елның 9 гыйнварында) АРХУМАС каршында «совет» уенчыклары ясарга өйрәтү курслары оештыру турындагы мәсьәлә көн тәртибенә куела.

1937 елда Казан сәнгать училищесында (алга таба КСУ) скульптура фәнен башта Урал сәнгать-сәнәгать техникумын, аннан соң А. Матвеев шәкерте булып сәнгать академиясен тәмамлаган Садри Ахун укыта башлый. Ул төбәктә кешене, портретларны һәм хайваннар дөньясын академик традициягә нигезләнеп иҗат итә башлаган беренче татар сәнкатькяре була.

Садри Ахун КСУ да 1937 елдан алып 1952 елга кадәр укыта. Әмма уку йортында аерым скульптура бүлеге 1948 елда гына оеша. Соңрак совет рәссамнары берлегенең татар секциясе үзәген тәшкил иткән Н. Гаделев, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина нәкъ менә шул вакытта укырга керәләр. Казан сәнгать мәктәбендә академик скульптура укытуның Богатырев киткәннән соңгы икенче этабы шушы бүлекнең эшчәнлеге белән бәйле.

Бу заманда эшләнгән скульптур композицияләрнең стилистикасы агымдагы моментка тулаем туры килә, ягъни мәдәнияттә хакимлек иткән «социалистик реализм» кысаларыннан чыкмый.

XX–XXI гасырлар чигендә Татарстанның догмалардан азат ирекле үсеш юлына әйләнеп кайтуы татар скульпторларына иҗатта үзләрен күрсәтү өчен яңа мөмкинлекләр ача.

XXI гасыр башында КСУ администрациясе тагын бер тапкыр пластика укыта башларга омтылып карый. Бу хәлләр архитектор К. Мюфке тарафыннан махсус Казан сәнгать мәктәбе өчен төзелгән тарихи бинаның Казан сәнгать училищесына кайтарылуы белән бәйле. Моңарчы әлеге бинада урнашкан Казан авиация институты бер остаханәне сәнгать керамикасы бүлеге өчен арендага гына биреп торган була. Студентлар монда рәсем ясау һәм нәкыш белән беррәттән, декоратив скульптура, әвәләү һәм калыпка салу белән дә шөгыльләнәләр.

Бу чорны пластика укытуның яңа этабы дип карарга кирәк.

XX гасырның соңгы утыз елында Көнбатыш Европа һәм Россиянең мәдәни мохитендә сәнгатьтә яңа юллар эзләү юнәлешендә яңа формалар пәйда була. Аларны, модернизмга каршы куеп, постмодернизм дип атыйлар. Татарстан мәдәни мохите пластикасында бу, барыннан да элек, җирле архетипка басым ясауда, борынгы мәҗүси һәм мөселман мәдәниятләре эзләрен саклауда чагыла. Борынгыдан килгән фикерләү кысаларында скульптура үсеше яңа формалар белән байый. КСУдагы сәнгать керамикасы бүлеге, композицияләр иҗат иткәндә, төбәктәге иң-иң борынгы фигуратив формаларга (чынбарлыкның реаль предметларын, кеше фигураларын сурәтләүче) һәм орнамент мотивларына таяна. Керамика, декоратив скульптура буларак, бакчапарклар пластикасында да, кече формаларда да скульптура үз урынын ала. Шуңа күрә керамика бүлегендә укучылар академик кысалардан

читтәрәк торалар, стильләштерүне, сәнгати тәэсирле алымнарны киң кулланалар.

Моңа нисбәтән, З. Гәрәеваның «Татар малае», Р. Сабировның «Тормыш әйләнеше», «Алтын урдалылар», Т. Зәбировның «Бәрән» дип исемләнгән курс эшләре һәм З. Гәрәеваның «Очсыз-кырыйсыз бергәлек», Т. Зәбировның «Үгезләр» дип аталган диплом эшләре аеруча кызыклы.

З. Гәрәеваның «Татар малае» таш скульптура стилендә булып, сынның аскы өлешенең өске өлештән кыскарак булуы очраклы түгел. Билдән алып иңбашка кадәрге өске өлеш киресенчә озынайтылган. Гомумән алганда, гәүдә нәзакәтле, озын муенлы яшүсмер кыяфәтендә. Малай мәктәп яки мәдрәсә шәкерте киеменнән. Кайбер детальләр – кабарынкы, башкалары – тирән тырналмалар рәвешендә. Батынкылыклар бакыр окисе кушылган характерлы фирәзә (зәңгәр) төсендәге эмаль белән капланган.

Шул ук авторның «Тормыш әйләнеше» композициясе берничә элементтан тора: ат, кулларын баш өстендә түгәрәк ясап тоташтырган хатын-кыз алиһәләр һәм кошлар. Фигуралар борынгы керамик шарсыман конуслардагы (сфероконус) атларны символлаштыручы графиканы хәтерләтә, бары тик сызыклары калын һәм персонажлар өстәлгән. Шунысы кызыклы, студент кыз бу композицияне жгут техникасында башкарган. Чүлмәк ясауның нәрсә икәнен дә белмәгән, әвәләп савытлар ясаган чорда да әлеге техника кулланылган.

Р. Сабировның «Алтын урдалылыр» сыны кыя ташлы конфигурацияне хәтерләтүче таш скульптура стилендә. Алар фронталь түгел, төрле яктан караганда да – үтә нәзакәтле. Сурәтләү өлеше саерак булганга күрә, автор график таплар һәм линияләр ярдәмендә сынның формасын авангард стилендә билгели.

Т. Зәбировның «Бәрән» һәм «Үгезләр» анималистик скульптураларын уртак пластик чишелеш берләштерә. Юкса аларның беренчесе – өстәлгә куела торган сын, икенчесе – бакча-парк пластикасы. Ике очракта да хайваннарның зур гомумиләштерелгән формасы нәзакәтле детальләр белән тулыландырыла һәм бизәлә. Мәсәлән, бәрәннең кара ярымсферасына алтын соляр тамгалар яньчеп төшерелгән, аның башы һәм мөгезләре дә шул рәвешле бизәлгән.

2001 елда Казан сәнгать училищесында скульптура бүлегенең яңадан эшли башлавы скульптор һәм педагог А.М. Миңнуллина исеме белән бәйле. Ул, әйтергә кирәк, бүлекнең матди базасын яңабаштан булдыра. Училище акрынлап станоклар, эш кораллары, үзле балчык, гипс сатып ала башлый.

Скульптура остаханәсенең эше шактый озак тукталып тору аркасында, программаны да, педагогик алымнарны да өр-яңадан булдырырга туры килә. Әмма беренче чыгарылышның ахырына уку-укытуның билгеле бер системасы оеша. Ул Сәнгать академиясендә гасыр башында кулланылган белем бирү принципларына да таяна, яңа методикаларга да мөрәҗәгать итә. Ачылуына өченче ел китүгә

үк бүлек профессиональ яктан шактый оста итеп башкарылган эшләр тәкъдим итә. Студентларның композицияләре имтихан алу комиссиясе тарафыннан югары бәяләнә һәм теләсә-кайсы күргәзмә залында профессиональ сынчыларның әсәрләре белән янәшә куела ала. Остаз үз методикасында, студентлар белән бергәләп, дөньякүләм танылган борынгы пластика сәнгате үрнәкләрен өйрәнүгә таяна.

Бүгенге көндә дә КСУда белем бирү системасының нигезендә Сәнгать академиясендә XX гасыр башында кертелгән уку-укыту принциплары ята. Алар – антик үрнәкләрне өйрәнү, сюжет һәм теманың беренче урынга куелуы, образны реалистик аңлату. 2006 елгы диплом эшләре арасында Ф. Вәлиуллинның «Яшьлек», С. Ненароковның «Зәңгәр яулык», Ф. Миңнебаевның «Әти», З. Мөхәммәтҗанованың «Авыр сөйләшү» кебек эшләре игътибарга лаек.

Ф. Вәлиуллинның «Җайдак» композициясендә яшьлеккә дан җырлана. Җайдак – татар халкының иң яраткан персонажларыннан берсе, ә атта оста йөрүче яшь егет, К. Петров-Водкин картиналарындагы персонаж белән аваздаш булып, хыял, өмет, киләчәкне тоемларга ярдәм итә.

З. Мөхәммәтҗанова да ике фигурадан торган катлаулы композиция тудырган. Яшь егет һәм кыз фигуралары архитектоник планда киеренке халәттә сурәтләнгән. Алар кара-каршы статик хәлдә диярлек басып торалар. Әмма скульптураны карап әйләнеп чыксаң, сөйләшү интригасы һәрвакыт яңа ракурстан ачыла. «Әти» һәм «Зәңгәр яулык» – утырып торучы ялгыз фигуралар. Беренче скульптурада эскәмиядә утырып торучы өлкән яшьтәге кеше тулаем тынычланганлык рухы белән сугарылса, икенчесендә фронтта сугыш туктап торган арада гармунда уйнаучы сугышчы үзенең «тальянын» киң итеп сузган хәлдә катып калган.

Шул рәвешле, без тикшергән күләмле композицияләр, КСУда скульптура укытуда ике төп магистраль юлны аерып күрсәтергә мөмкинлек бирә. Аларның берсе символика, билге-тамга белән эш итүче этник пластикага юнәлеш тота. Һәм бу аның морфологик үзенчәлекләрендә дә чагылыш таба. Икенчесе (соңрак Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтының Казан филиалында дәвам иттерелгәне) – реалистик юл, ул күпертүдән, гротесктан азат, аның нигезендә хәятне тормыштагыча сурәтләү ята.

Хәзерге заман сәнгатендә бер генә традициягә ияру авыр, рус һәм бөтендөнья сәнгатенең авангардлык юнәлешләре мәдәниятләр синтезына юл ачтылар. Ул бер үк сәнгать әсәрендә борынгы этник стилистика һәм рус-европа мәктәпләренә хас алымнарның синтетик рәвештә берләшүеннән гыйбарәт.

***Кривошеева Татьяна Николаевна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Н.И. Фешин исемендәге*
*Казан сәнгать училищесы укытучысы, рәссам*

УДК 77.0

***Д.В. Рахманова***

# «ТАСМА» КАЗАН ФОТОТӨРКЕМЕ ИҖАТЫНЫҢ МИЛЛИ АСПЕКТЫ: МӘСЬӘЛӘНЕҢ КУЕЛЫШЫНА КАРАТА

В статье дается краткая характеристика ведущего объединения фотохудожников Казани последней трети XX века «Тасма» и обзор одного из наиболее значимых направлений их творчества, связанного с национальной темой. Автор выделяет фотографов, которые в своем творчестве уделяли национальной теме наибольшее внимание – Р. Якупов, Ф. Губаев, Л. Кузнецова, Р. Мухаметзянов, которые смогли в рамках репортажной фотографии выразить самобытность народов, их особенные черты, через повседневность, быт, праздники, традиции.

**Ключевые слова:** фотография, «казанская фотошкола», фотолюбительское движение, советская документальная и репортажная фотография, национальные мотивы, этнографический аспект фотографии.

The article gives a brief description of the leading association of photographers of Kazan named «Tasma» in the last third of the twentieth century and an overview of one of the most significant areas of their work related to the national theme. The author identifies the photographers who in their work gave the national theme the most attention – R. Yakupov, F. Gubaev, L. Kuznetsova, R. Mukhametzyanov, who were able to express the originality of peoples, their particular features through everyday life, holidays, traditions as part of reportage photography.

**Keywords:** photography, “Kazan photo school”, photo enthusiast movement, Soviet documentary and reportage photography, national motives, ethnographic aspect of photography.

Республикабыз мәдәниятендә «ТАСМА» фототөркеменең алыштыргысыз үз урыны бар. Ул хәзерге заман Татарстан фотография сәнгате һәм Казан фотомәктәбе оешуга сизелерлек йогынты ясады. Фотоберләшмә төрле милләт вәкилләрен берләштерде, һәм бу, һичшиксез, аның иҗат эшчәнлегендә дә чагылмый калмады. Казан фототөркемендә катнашучылар үз иҗатларында тормыш-көнкүрештәге актуаль темаларны гына ачып калмадылар, милли аспектка – төрле милләтләрнең (татар, үзбәк, чегәннәр) үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен һәм бәйрәмнәрен яктыртуга да зур урын бирделәр. Татарстандагы һәм Россиядәге документаль фотография сәнгате үсешендә «ТАСМА»-ның роле һәм аның милли аспекты җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бүгенге көндә Казан фототөркеменә кергән сәнгатькярләрнең иҗатын фәнни анализлау – бик кирәкле гамәл.

«ТАСМА» 1974 елда Казанда барлыкка килде. Исеме Татар яктылыкны сизә торган материаллары (Татарские светочувствительные материалы) дигәннән кыскартып алынды, шулай ук татар телендәге *тасма* сүзенә дә барып тоташа иде. Фотосөючеләр аны үзләренчә яңа

мәгънә белән дә баеттылар – «Хәзерге заман татар осталары» («Татарские современные мастера») дип атадылар.

1976–1977 елларга «ТАСМА» уналты кешене берләштерә иде[1].

1980 елларда «ТАСМА»га тагын ун фотограф килә [Губаев][2].

1970 елларда «ТАСМА» фототөркеме оешуга ук аның үзенчәлекле иҗатына журналистлар, сәнгатькярләр һәм философлар гына түгел, башка белгечләр дә игътибар итә. 1980 елларда сәнгать белгечләре А.С. Вартанов [Вартанов, 1980], В.Н. Разумейченко [Разумейченко] мәкаләләре басылып чыга. Соңыннан, фототөркем таркалгач, аның элеккеге әгъзалары В.Ю. Юринов, С. Колина, О. Кручин, Е. Мокеева һ. б. ның шәхси күргәзмәләре турында аналитик мәкаләләр һәм рецензияләр дөнья күрә [Колина, 2011; Кручина; Мокеева; Юринов]. Төркем турындагы төп хезмәтләр 2014 елда «ТАСМА»ның 40 еллык иҗат эшчәнлеге уңаеннан нәшер ителгән «ТАСМА. Казан фототөркеме» дип исемләнгән басмада туплап бирелгән. Төркемнең күренекле әгъзалары иҗаты монографик характердагы альбомнар рәвешендә дә басылган [Кузнецова; Сабантуй в фотографиях...]. «ТАСМА»ның әйдәп баручы фотографлары Л.М. Кузнецова, Р.С. Мөхәммәтҗанов, Р.Г. Якупов турындагы мәкаләләр «Татар энциклопедиясе»нә дә кертелгән [Валеева-Сулейманова, 2006, с. 494–495; Валеева-Сулейманова, 2006, с. 507–508; Мухаметзянов]. Нәкъ менә аларның иҗатында милли тема төп урынны ала да инде.

«ТАСМА» төркеменең беренче күргәзмәсе 1975 елда Казанда Химиклар Мәдәният сараенда оештырыла. Шуннан соң ул ел саен СССР шәһәрләрендә һәм чит илләрдә уздырылган күргәзмәләрдә даими катнашып килде.

1979 елда Мәскәүдә «Совет фотосы» журналы редакциясендә «ТАСМА» өчен гаять әһәмиятле күргәзмә булып уза. Аңа башкала тәнкыйтьчеләре, танылган фотография осталары үз бәясен бирә. Филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Дәүләт сәнгать белеме институтының массакүләм коммуникация чараларында сәнгати проблемалар бүлеге мөдире А.С. Вартанов үзенең «ТАСМА» фототөркеме турындагы беренче һәм чагыштырмача тулы аналитик мәкаләсендә әлеге күргәзмә һәм аны аннан соңгы тикшерүләр турында яза [Вартанов, 1980,

[1] Төркемнең җитәкчесе һәм оештыручысы Владимир Николаевич Богданов (1942–2000), Фәрит Сәет улы Гобәев (1951), Ләлә Миңлебай кызы Кузнецова (1946), Рифкать Госман улы Якупов (1944), Александр Ананеевич Тамбулов («Грек») (1950–2016), Эдвард Морат улы Хәкимов (1938), Владимир Николаевич Зотов (1939), Зөфәр Гомәр улы Бәширов (1937), Владимир Николаевич Разумейченко (1951 – 1999), Вадим Павлович Никифоров (1944–2005), Борис Сергеевич Давыдов (1942–1995), Валерий Константинович Михайлов (1946), Рөстәм Сөләйман улы Мөхәммәтҗанов (1946), Юрий Геннадьевич Филлимонов (1941), Альберт Әхмәт улы Баһаветдинов (1954).

[2] Василий Егорович Мартинков (1938–2004), Виталий Хашев (1960), Шамил Әхмәт улы Бәширов (1951), Валерий Георгиевич Павлов (1953), Сергей Владимирович Свинцов (1957), Евгений Зиновьевич Балашов (1958), Юрий Степанович Федотов (1938).

с. 21–23]. Ул Казан фототөркеменең үзенә бертөрле булуын ассызыклый, «ТАСМА»ның заманча тенденцияләр артыннан кумавын, ә милли темаларны күтәрүен, кешеләрне чолгап алган яшәеш мохитен, көнкүрешне һәм бәйрәмнәрне игътибар үзәгенә алып, көндәлек тормыштагы уникальлекне чагылдыруын билгеләп үтә.

Милли темага аерым игътибар төркемнең интернациональ составы (күбрәк татарлар) һәм фотографларны чолгап алган әйләнә-тирә мохит белән дә аңлатыла. Татар темасы беренче планга чыга, һәм ул Р. Якуповның иҗатында төп юнәлешне билгели. Ф. Гобәев, Р. Мөхәммәтҗанов, Л. Кузнецова, В. Богданов, З. Бәширов, Ю. Филимонов эшләрендә дә миллилек әһәмиятле урын алып тора.

Рифкать Якупов татар гаиләсендә дөньяга килә. Һөнәри осталыгы арта барган саен, ул үзенең фотограф буларак эзләнүләре нигезендә милли тема ятуын аңлый. Татар халкының кабатланмас гореф-гадәт һәм йолалары аның иҗатында лейтмотивка әверелә. Ул еш кына Татарстан авылларына этнографик экспедицияләргә чыга, Сабантуй бәйрәменә хас үзенчәлекләрне барлый, милли йолаларны, һөнәрләрне фоторәсемгә төшерә. Үзенең эшләрендә табигать матурлыгын, туган халкының рухын күрсәтергә омтыла. Тулы бер альбомны тәшкил иткән «Сабантуй» сериясе (1970 еллар) – фотографның әлеге сәяхәтләренең гүзәл нәтиҗәсе [Сабантуй в фотографиях...]. Кырым татарларының язмышы – Р. Якупов иҗатында аерым бер сәхифә. 1995 елда ул Кырымда, БМО миссиясе заказы буенча, депортацияләнгән халыкларның тарихи ватаннарына кайтуы турында репортаж төшерә. Аның фоторәсемнәре эчке хөрлек һәм традицияләргә тугрылык, туган җиргә һәм тарихи тамырларга бирелгәнлек, милли бердәмлек хакында сөйли. Аларда лиризм, эчкерсезлек, үз халкың, аның мәдәнияте һәм тарихы белән горурлану ярылып ята.

Фәрит Гобәев 35 елдан артык республика матбугатында эшләгән, озак вакытлар «Вечерняя Казань» газетасы фотохәбәрчесе булган. Р. Якупов кебек ул да милли тема белән мавыккан: татар авылларындагы гади кешеләрнең, гореф-гадәтләрне, мәҗлесләрне, бәйрәмнәрне чагылдырган күренешләрнең, милли Сабан туйларының менә дигән фоторәсемнәрен эшләгән (1976). Аның «Авыл туе» сериясеннән эшләре дә (1986) милли бәйрәмнәр темасына карый. Башы-аягы белән татар темасына чумган Р. Якуповтан аермалы буларак, Ф. Гобәев читтән торып күзәтүче ролен сайлый сыман. Шуңа күрә аның фотосурәтләренең үз фикере, үзгә хисси бизәлеше бар.

Ләлә Кузнецова милли темага киңрәк планда якын килә: ул татарларны, үзбәкләрне, еврейләрне төшерә, әмма фото сәнгате тарихына Татарстан, Россия, Урта Азия һәм Украина чегәннәре турындагы фотографияләр сериясе белән кереп кала. 1980 еллар уртасыннан ук Л. Кузнецованың исеме Лондонда басылып чыккан «Халыкара фотографияләр энциклопедиясе»ндә урын ала [Шаталов]. 1988 елда шул заманда популяр булган «Огонёк» журналында Л. Кузнецованың берничә эше басыла. Бу аның Союз күләмендә танылуы хакында сөйли.

Үзенең аеруча танылган һәм әһәмиятле «Казан» (1981–1996), «Чегәннәр» (1992–1998), «Бохараның аръягында» дип исемләнгән циклларында Л. Кузнецова һәр халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләрен, җиргә һәм традицияләргә мәхәббәтен күрсәтә, аның фотосурәтләренә киңлек, хөрлек хас. Ирек сөючән халыклар дөньясына чумып, ул «тере» һәм хиссиятле рәсемнәр төшерә. Шулар фоторәссамны союз һәм дөнья күләмендә таныта. Рөстәм Мөхәммәтҗанов фоторәсемнәренә дә («Танышу» (1988), «Намаз» (1988)) лирика һәм сюжетлылык хас. Иҗатының төп темалары: Татарстанның шәһәр, авылларында яшәүче гади кешеләрнең көндәлек тормышы («Казан вокзалында», «Киносөючеләр түгәрәге», «Диңгез көе»), татар халкының бәйрәмнәре һәм йолалары («Шәледә күңел ачу», «Безнең чемпион», «Көзге туй» (1987)).

«ТАСМА»ның калган әгъзалары да – Владимир Богданов, Зөфәр Бәширов, Альберт Баһаветдинов, Шамил Бәширов, Владимир Зотов, Валерий Михайлов, Александр Тамбулов, Эдвард Хәкимов, Юрий Филлимонов, Валерий Павлов, Сергей Свинцов, Виталий Хашев, Василий Мартинков, Евгений Балашов, Владимир Разумейченко, Борис Давыдов, Вадим Никифоров – милли теманы читләтеп үтмиләр.

«ТАСМА» фотографлары билгеле бер халык яки җәмгыятьтәге төрле катлам кешеләренең тормышы белән кызыксынып, инсанның вакыт аралыгында һәм социумда яшәвен яңача аңлый-аңлата башладылар. Аны шәхси тәҗрибәдән чыгып, вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдергән читтән (әмма туры) караш дип бәяләп булыр иде. Милли теманы һәр фотограф диярлек үз итте, кайберәүләр аны иҗатының нигез ташына әйләндерде. Нәкъ менә милли үзенчәлекләргә басым ясавы белән «ТАСМА» илнең төрле төбәкләрендә һәм союздаш республикаларда барлыкка килгән башка фотоберләшмәләрдән аерылып торды да. Бәйрәмнәр, көндәлек тормыш, кабатланмас үзенчәлекләр, ирек һәм үзбилгеләнү, тарихи тамырларга бирелгәнлек, дәвамчанлык – «тасма»лылар иҗатында еш очраган әлеге фундаменталь темалар татар милләтенең үзенә генә хас сыйфатларын ассызыклап, аны җанлы итеп гәүдәләндерәләр. Традицияләргә хөрмәт йөзеннән дә аларны тарихта калдыру гаять мөһим. «ТАСМА» фотографлары тәэсирле чаралар, һәр темага индивидуаль якын килүләре белән милли фотосурәтләрне тарихи документ кына түгел, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрделәр.

**Әдәбият**

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Кузнецова Л.М. // Татарская энциклопедия: в 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2006. Т. 3: К–Л. С. 494–495.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Фотоискусство // Татарская энциклопедия: в 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 6: К–Л. С. 132–133.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Якупов Р.Г. // Татарская энциклопедия: в 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2006. Т. 6: К–Л. С. 507–508.

*Вартанов А.С.* Второй шаг // ТАСМА. Казанская фотогруппа. Казань, 2014. С. 8–9.

*Вартанов А.С.* Начало // Советское фото. 1980. № 1. С. 21–23.

*Губаев Ф.* Мы делали фотографии, а они создавали нас // Журнал «Казань» [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://kazan-journal.ru/pages/item/716-myi-delali-fotografii-a-oni-sozdavali-nas, свободный (16.08.2018).

*Климов О.А.* Казанская фотография // Мультимедийный блог «libertu.su» [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://klimov.liberty.su/2009/06/казанская-фотография/, свободный (20.08.2018).

*Колина С.* Поиски и находки Рифа Якупова // Казань. 2011. № 5. С. 44–51.

*Колина С.* Владимир Зотов в своей стихии //Казань. 2011. № 11. С. 43–55.

*Кручина О.* Риф Якупов: «Я открывал для себя мой народ» // Общественно-политическая газета Республика Татарстан [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://rt-online.ru/p-rubr-kult-36535/, свободный (6.12.2018).

*Кузнецова Л.* Дорога. М.: Изд-ль Л. Гусев, 2010. 208 с.

*Мокеева Е.* Новейшая история: Фотогруппа «ТАСМА». 40 лет // Ежемесячный журнал «Собака.ру» [Электронный ресурс]. Режим доступа: http: // www.sobaka.ru/kzn/city/art/27815, свободный (8.08.2018).

Мухаметзянов Р.С. // Татарская энциклопедия: в 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4: М–П. С. 308–309.

*Разумейченко В.Н.* Говоря жизни «Да!» // Вечерняя Казань. 20.06.1988. С. 40–44.

Сабантуй в фотографиях Рифката Якупова: [фотоальбом] / [авт. текстов А. Каримова, Ш. Идиатуллин, Р. Якупов]. М.: Изд. дом Марджани, 2014. 168 с.: фот.

Советское фото: Журнал [Электронный ресурс]. Режим доступа: http:// journal-club.ru/?q=image/tid/76, свободный (14.08.2018).

ТАСМА. Казанская фотогруппа / авт.-сост.: Ф. Губаев, В. Зотов, Т. Лескова, Л. Кузнецова, О. Вербина. Казань, 2014. 144 с.: ил.

*Чернов А.* Фарит Губаев. Казанская фотографическая школа // Журнал «Русский репортёр» [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://rusrep.ru/ article/2011/07/15/kazan_school (20.08.2018).

*Шарипов В.* Сабантуй, который всегда с нами // Советское фото. 1980. № 7. С. 11–14.

*Шаталов А.* Люди и птицы Ляли Кузнецовой // Журнал «Новое время» [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://newtimes.ru/articles/detail/49053/, свободный (6.12.2018).

*Юринов В.Ю.* Социальная фотография: несколько фрагментов творчества участников фотогруппы «ТАСМА» // ТАСМА. Казанская фотогруппа. Казань, 2014. С. 12–13.

***Рахманова Дарья Владимировна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 930

***В.М. Усманов***

## ЭСТӘРЛЕБАШ ТАШЪЯЗМАЛАРЫ

Статья посвящена изучению мусульманских эпиграфических памятников на территории Стерлибашевского района Республики Башкортостан.

**Ключевые слова:** Стерлибашевское кабрташи, каталоги, хаттаты-каллиграфы, резчики по камню, карьеры известняка.

The article is devoted to the study of Muslim epigraphic monuments on the territory of the Sterlibash district of the Republic of Bashkortostan.

**Keywords:** gravestones of Sterlibash, catalogs, calligrapher-hattats, stone carvers, limestone quarries.

Госманлы төрекләрнең бөек архитекторы Синан (1480–1578) хөсне хат осталарының хезмәтен бик югары бәяләгән һәм каллиграфия сәнгатен үзенең мигъмарчылык эшенә һәм осталыгына караганда, өстенрәк куйган. Гомумән, Шәрекъ илләрендә матур язу сәнгатенә бик зур игътибар бирелгән һәм хаттатларга олуг хөрмәт күрсәтелгән. Мәгълүм ки, гаҗәеп гүзәл хәреф-бизәкләрдән торган гарәп язуының нәкышләү мөмкинлекләре чиксез зур. «Ни один алфавит мира не получил такого эстетического значения, как арабский, широко распространенный во всех «мусульманских» странах. Высоко ценилась форма исполнения письма; «чистота письма» считалась признаком «чистоты души»» – дип язган сәнгать белгече Б.В. Веймарн [Червонная, 1987, с. 157].

Аңлашыла ки, мөселманнар өчен иң зәвыклы, иң гүзәл һәм изге нәрсәләр – мәшһүр каллиграфлар тарафыннан күчерелгән Коръән китабы, матур кульязмалар, шәмаилләр, «газиз ташлар» дип аталган борынгы эпиграфик һәйкәлләр.

Эстәрлебаш һәм аның тирә-ягындагы авылларның иске зиратларында борынгы каберташ язулары чагыштырмача яхшы сакланган. Матур итеп калкытып һәм бизәп эшләнгән каберташ язуларының эстетик һәм тәрбияви әһәмияте гаять зур (район территориясендә андый ташларның саны ике йөздән артып китә). Татар халкының борынгы эпиграфик ядкярләре галимнәр тарафыннан яхшы өйрәнелгән. Әмма Эстәрлебаш төбәгендәге эпиграфик һәйкәлләр моңарчы фән даирәсенең игътибарыннан читтә калып килде.

XI гасырда яшәгән бөек шагыйрь Йосыф Баласагунлы:

> «Җыйган дөнья байлыклары таралыр,
> Язылган сүз җиһанда мәңге калыр» –

дип язган [Миңнегулов, 1996].

Күрәсең, Эстәрлебаш хаттатлары да шушы сүзләргә колак салып иҗат иткәннәр. Кульязма китаплар күчерүдә һәм эпиграфик һәйкәл-

ләр ясауда Эстәрлебаш төбәге зыялылары аеруча тырышлык куйганнар. Мәсәлән, бу якларда дистәләгән мәшһүр «таш язгучы» оста яшәгән: Эстәрлебаштан – Гали хәлфә бине Ысанали әл-Казаки, мулла Габдулла бине Мөхәммәдхарис Тукаев, хаҗи Габдеррәхим Галиев, мулла Габдеррахман Айдабулов, мулла Ләтыйфулла бине шәйех Зәйнулла Галиәкәев, Габделвахид бине Әбүнәгыйм, Габделмәҗид бине Әбүнәгыйм Монасыйпов, Яшерганнан – мәзин Гарифулла бине Габдулла, Гыйзеддин бине Бәхтегани, Хәлекәйдән – кятиб вә мәзин Мөхәммәдхәсән бине Мөхәммәд-Әмин бине Габдессаттар бине Уразгилде бине Госман бине Юныс, Шаһмөхәммәд бине Габделләтыйф, Табылдыдан – имам Баймөхәммәд бине Бикмөхәммәд Динестән – Ибнеябан хәлфә бине Габделгани һ. б. Бу исемлекне тагын да дәвам итеп булыр иде, әмма аларның күбесенең (мәсәлән, Куганакбаш яисә кайбер Эстәрлебаш авылы хаттатларының) исемшәрифләре безгә мәгълүм түгел (күрәсең, осталар үзләрен бик тыйнак тотканнар). Әйтәсе килгән фикерем шул: Эстәрлебаш төбәгендә гомер кичергән мулла Габдулла Тукаев яисә мәзин Гарифулла Дәүләтъяров кебек мәшһүр хаттатларның башкарган эшләре Камаледдин Бәхзат, Солтан-Гали Мәшһәди кебек бөек сәнгатькярләр иҗатына тиң.

Биредә шундый сорау туа: ни сәбәпле Эстәрлебаш авылында һәм аның тирә-юнендә хөсне хат сәнгате югары кимәлгә күтәрелә алган? Әлбәттә, бу түбәндәге уңай шартларның булуы белән бәйләнгән:

1) Алтын Урда заманнарыннан килгән гореф-гадәтләр Эстәрлебаш төбәгендә яхшы сакланып калган. Чөнки Идел буенда сүнеп барган ислам мәдәнияте Эстәрлебаш мәдрәсәләре кебек уку йортлары «йогынтысы астында терелә, халык арасында яза белүчеләр күбәя башлый һәм галимнәр сыйныфы ягъни заманына күрә бер зыялылар катламы барлыкка килә» [Баттал, 1996, б. 96];

2) атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсе мәдәни мәркәзләрнең берсе була;

3) төрки-мөселман мәгариф теземе сакланып кала;

4) биредә милли мәдәниятебезгә ярдәм күрсәтүче химаячеменценатлар була;

5) Эстәрлебаш суфичылык үзәге булып исәпләнә («нәкышьбәнди тарикасы» дип аталган дини юнәлеш хөсне хат сәнгатенең камилләшүенә һәм үсешенә зур йогынты ясаган);

6) XIX гасыр азагы XX гасыр башларында җирле халыкның тормыш шартлары (1917 елга кадәр) чагыштырмача гел яхшы якка үзгәрә;

7) биредә (Айтуган, Яшерган авылларында) җиңел эшкәртелүчән ташлар чыгарыла.

Эстәрлебаш тирәсендә генә дә өч таш карьеры билгеле: «кардон» тавында (анда төзелеш өчен комташ күп чыгарылган), «Гөмбазы» ягында («Бакырчагылтау» дип аталган урында) һәм «калячный чокыр»да. Андагы кызгылт төстәге йомшак эшкәртелүчән ташны




Эстәрлебашта Тукаевларның төрбә диварына бөркетелгән ташъязма һәм аның рәсем-күчермәсе

төзү эшендә дә, кабер ташларын ясауда да кулланганнар. Әмма җирле хаттатлар өчен Яшерганныкыннан да яхшы таш булмаган. Олы яшьтәге кешеләрнең сөйләүләре буенча, Яшерган ташчылары чирәпташ-известнякны Таштаудан һәм Айтуган авылына якын урнашкан тау сыртларындагы карьерлардан чыгарганнар[1]. «Яшерган ташлары» җир астыннан чыгарылуга дымлы килеш «шалкан кебек җиңел киселгән». Аны күп очракта ике метр озынлыктагы зур пычкы (утызынчы елларда аны «стахан пычкысы» дип атаганнар) белән дүрткырлы итеп кискәннәр, балта белән эшкәрткәннәр, каләм белән язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә чокып нәкышләгәннәр. Әгәр, эш барышында таш кибеп китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны бераз суга салып тотканнар яисә өстенә су сибеп торганнар, шул рәвешле ташны, йомшартып, әүвәлге хәленә кайтарганнар.

Эстәрлебаш төбәгенә караган авыллардагы ташъязмаларның кайберләре Каргалы осталары тарафыннан башкарылган. Аңлашыла ки, эпитафик һәйкәлләр ясату матди чыгымнар белән бәйләнгән. Еш кына кабер ташлары яздырту эшенең бәясе ишек, тәрәзә кебек нәрсәләр ясатуга бәрабәр булган.

Каллиграфлардан тыш, таш кисүче һөнәрчеләр турында да мәгълүматлар бар. Яшерган кешесе Хәйрулла бабай уллары (Сәйфулла, Фәтхулла, Зәкиулла (ул, укымышлы булган, «таш язган»), Миңлеяр, Миңлебай, Хөснетдин һәм Шәрифулла) ташларны кисеп-эшкәртеп Эстәрлебаш төбәгендәге авылларга, хәтта ерак Оренбург якларына да илтеп сатканнар.

Сүзне бер шәҗәрә язуы белән дәвам итәбез: *Айдабул (?) – Ысанали – Гали хәлфә (?–1920) – Габдеррәхим Гали – (һәм Габдеррахман Айдабулов)*

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Габдеррәхим Галиев (1867– 1966), Габдеррахман Айдабулов (1881–1972) һәм аларның ата-бабалары да китап күчерүчеләр һәм таш язучы осталар булган.

[1] Эстәрлебаш авылындагы мәзиннәр нәселеннән булган мәрхүм Ибраһим Галиев сөйләгәннәрдән: шахтадагы шикелле тауны тишеп кергәннәр дә, сыер сауган кебек таш сауганнар.

1898 елгы ташъязмаларның берсендә: *«...әл-мөнәкъкаш әл-хаҗи Габдеррәхим бине Гали хәлфә әл-казакый...»* (ягъни, «казакъ – хаҗи Габдеррәхим Гали хәлфә улы нәкышьләде...» дигән сүзләр язылган. Габдеррәхим 1897 елга кадәр (чама белән 1887–1897 еллар арасында) хаҗга барган һәм шул вакытта берничә ел Төркиядә укыган. Өлкән яшьтәге кешеләрнең сөйләүләренә караганда, Габдеррәхим Истанбул шәһәрендә төрек солтанына каршы оештырылган фетнәләр вакытында кулга алынган һәм чит ил кешесе булу сәбәпле генә үлем җәзасыннан котылып калган. Совет чорында 1960 елга кадәр (тарихчы Мәхмүд Гобәй улы Мәхмүдовның сүзләре буенча) таш язу эше белән Эстәрлебаш авылында фәкать ул гына шөгыльләнгән.

Гали хәлфәнең икенче улы – Габдеррахман да Эстәрлебаш мәдрәсәсендә төпле белем алган, шул ук мәдрәсәдә хәлфәлек иткән, түбәндәге мәчеттә мулла вазифаларын үтәгән. Совет чорында мәдрәсәләр ябылгач, берничә ел үз өендә укыткан. Аннары сөргенгә сөрелгән, Беломор каналын төзүдә катнашкан. Туган якларына әйләнеп кайткач, яңадан мулла булган, якын туганнары яисә дус-ишләре соравы буенча, «таш язу» эше белән дә шөгыльләнгән.

Эстәрлебаш төбәгендәге ташъязма мирасны өйрәнү барышында биш йөздән артык кабер ташы исәпкә алынды һәм хронологик регистр рәвешендә каталог төзелде. Киләчәктә ул китап булып та басылып чыгар дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**

*Бигиев З.* Зур гөнаһлар. Казан, 1991. 324 б.

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. М., 1987. 351 б.; [32] л. ил.

*Миңнегулов Х.* «Бу «Гөлестан» даимә(н) күңел ачар» // Мирас. 1996. № 7–8.

*Баттал Г.* Казан төркиләре / тәрҗ. А. Рәхимова. Казан, 1996. 191 б.

***Усманов Венер Мөдәррис улы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 502.3

***С.Ф. Шәйхелова,***
***Г.Ф. Фахруллина,***
***Л.Р. Нигәмәтҗанова,***
***Р.Ф. Фахруллин***

# *CAENORHABDITIS ELEGANS* СУАЛЧАНЫНЫҢ БИО-НАНОАГУЛЫКНЫ ӨЙРӘНҮДӘ АЛДЫНГЫ ӨЛГЕ БУЛУЫ

В статье приводится общее описание анатомии свободноживущих нематод *Caenorhabditis elegans* и подчеркиваются основные особенности, которые делают этих беспозвоночных животных ценным объектом исследования, в частности, в инженерии анализа токсичности наноматериалов и биомедицине. Гомология генома *C. elegans* с геномом человека позволяет прогнозировать полученные исследователями результаты на высших эукариотах. В работе представлены примеры недавних работ по оценке токсичности химических соединений, редкоземельных элементов, наночастиц и других материалов с использованием нематод *C. elegans*.

**Ключевые слова**: нематоды, *Caenorhabditis elegans*, модельный организм, нанотоксикология, экотоксикология.

The article provides a general description of the anatomy of free-living nematodes *Caenorhabditis elegans* and highlights the main features that make these invertebrate animals a valuable object for research, in particular, in the engineering of the analysis of the toxicity of nanomaterials and biomedicine. The homology of the *C. elegans* genome with the human genome allows us to predict the results obtained by researchers in higher eukaryotes. The paper presents examples of recent work on the assessment of the toxicity of chemical species, rare-earth elements, nanoparticles and other materials using the *C. elegans* nematode.

**Key words:** nematodes, Caenorhabditis elegans, model organism, nanotoxicology, ecotoxicology.

Нематодалар – туфрак тирәлегендә иң күп таралган хайваннар. Аларны шулай ук сулы тирәлектә дә, утырма токымнарда да очратырга мөмкин [Leung *et al.*, 2008]. *Caenorhabditis elegans* шундый нематода төрләренең берсе булып тора. Ул озынлыгы 1 мм, киңлеге 70–90 мкм булган, туфракта ирекле тереклек итүче суалчан [Cabreiro *et al.*, 2013]. *C. elegans* суалчаннары бар җирдә дә, бигрәк тә дымлы уртача климатлы өлкәләрдә күп очрыйлар [Kiontke *et al.*, 2011; Andersen *et al.*, 2012]. Суалчаннарның әлеге төре органик таркалу барышында зур әһәмияткә ия һәм туклану чылбырында тоташтыручы буын булып тора [Kim *et al.*, 2013]. *C. elegans* суалчаннарының җиләк-җимеш һәм калын үләнчел сабаклар таркалган урыннарда булуы ачыкланды [Felix, Duveau, 2012]. Әлеге череп баручы туклыклы матдәләр таркалуның соңгы чорларында нематодаларны мул бактериаль ризык белән тәэмин итә [Frezal, Felix, 2015].




1 нче рәсем. *C. elegans* суалчанының анатомия сызымы

*C. elegans* суалчаннары күп очракта – һермафродитлар, ата затлар 0,1% ешлыгы белән очрый. Суалчаннар күзәнәк саны даими булган (өлгергән һермафродит затларда 959 күзәнәк) гади һәм төгәл анатомиягә ия (1 нче рәсем).

Әлеге күзәнәкләрнең 302 сен нейроннар тәшкил итә [Sulston *et al.*, 1983]. Күзәнәкләр саны аз булуга карамастан, *C. elegans* тышкы яктан каты тышча (кутикула) белән сакланучы ашкайнату, үрчү, нерв һәм бүлеп чыгару кебек катлаулы әгъзалар системасына ия [Gonzalez-Moragas *et al.*, 2015].

Тышча, яки кутикула – суалчаннарның күзәнәктән тыш каты өслеге. Ул хайваннарны әйләнә-тирәнең уңайсыз шартларыннан саклый, эрегән матдәләрнең тышка чыгып кимүен булдырмый, кайбер молекулаларның тышкы тирәлектән керүен тоткарлый, тәннең бербөтенлеген сакларга ярдәм итә, хәрәкәт иткәндә дә зур әһәмияткә ия. Өлгергән затларның тышчасы 0,5 мкм калынлыкта, ул үз эченә 5 катламны ала, болар – гликоаксымнар белән капланган өслек, липидлардан хасил булган эпитышча, коллагеннар һәм башка аксымнардан торучы кабык катлам, сыеклык белән тулы, коллаген ялгауларыннан торган урта катлам һәм коллаген фибриллаларыннан барлыкка килгән базаль катлам [Andrew *et al.*, 2012]. Умырткасызларның эпидермисы, төзелеше һәм эшчәнлеге ягыннан, кешенең һәм башка умырткалы хайваннарның тиресенә башлангыч бирүче булып тора. Шулай итеп, *C. Elegans* суалчанының тышчасы һәм эпителиаль системасы тиренең (эпидермисның) гадиләштерелгән өлгесе буларак кулланыла ала [Andrew *et al.*, 2012].

*C. elegans* суалчаннарының ашкайнату системасы өч төп әгъзаны үз эченә ала: авыз куышлыгы (стома), йоткылык һәм эчәклек (алгы, урта һәм арткы). *C. elegans* – туфрактагы бактерияләр белән тукланa, ул – сөзеп тукланучы хайван. Йоткылыкка үтеп кергәннән соң, азык йотыла, ә сыеклык исә авыз куышлыгы аша кире тышкы якка чыгарыла [Fang-Yen *et al.*, 2009]. Суалчаннарның йоткылыгы шулай ук өч өлешкә бүленгән: корпус (прокорпус һәм метакорпус), муентык (истмус) һәм ваклау җайланмасы булган терминаль бүлбус (киңәйгән урын) [Chiang *et al.*, 2006]. Туклану вакытында ике төрле хәрәкәт катнаша: йоткылык суыргычы һәм муентыктагы шома мускулларның дулкынсыман кыскаруы [Fang-Yen *et al.*, 2009]. Суыргыч ул – йоткылык мускулларының кыскару һәм яңадан үз халәтенә кайтуыннан

гыйбарәт өзлексез әйләнеш. Кыскару вакытында йоткылык куышлыгы ачыла һәм сыеклык, кисәкчекләр яки бактерияләр белән бергә, эчкә суыртыла. Йомшару вакытында куышлык тиз генә ябыла һәм сыеклык тышка чыгарыла, азык кисәкчекләре исә йоткылыкта кала һәм муентыкның мускуллары кыскару хисабына бүлбуска үтә, анда, эчәклеккә керер алдыннан, махсус җайланма ярдәмендә ваклана. Алга таба, күрәсең, күзәнәк тышчасы һәм бактерияләрнең плазматик мембранасы эчәклектә бүленеп чыгучы лизоцим белән сапозин/амебапор тәэсирендә таркала. Макромолекулаларның һидролизын алгы эчәктә бүленеп чыгучы пептидазалар һәм липазалар башкара. Туклыклы матдәләрнең сеңдерелүе эчәклек күзәнәкләренең апикаль өлешендә микротөкчәләр, шулай ук пептидларны һәм нуклеозидларны күчереп йөртүчеләр ярдәмендә башкарыла. Ашкайнату дефекация (эчәктәге азык калдыкларын чыгару) белән тәмамлана. Аның барышында ашкайнату юлыннан үзләштерелмәгән әйберләрнең 47% ы тышкы тирәлеккә чыгарыла [Gonzalez-Moragas *et al.*, 2015].

Суалчаннарның бүлеп чыгару системасы эшчәнлеге ягыннан югары төзелешле хайваннарның бөерләр системасын хәтерләтә һәм осмотик/ионнарны көйләүдә катнашучы дүрт төрле үзенчәлекле күзәнәкләрдән тора. Бүлеп чыгару системасы бозылган очракта, суалчаннар кирәгеннән артык суны эчләренә алалар һәм бу «таяксыман» (rod-like) үлем фенотибына китерә [Liegeois *et al.*, 2007]. Анатомия күзлегеннән караганда, суалчаннарның бүлеп чыгару системасын имезүчеләрнең бөерләре белән чагыштырып булмый. Шулай да аның электролитлы һәм осмотик һомеостазны молекуляр дәрәҗәдә өйрәнгән вакытта әһәмияте зур. Шулай итеп, *C. elegans* суалчаннарында бөерләр авыруы геннарының охшаш әһәмияте күрсәтелгән [Barr *et al.*, 2011].

Үрчү системасы өлгергән гаметалар ясала торган һәм аталандыру, йомырка салу өчен кирәкле икенчел әгъза буларак карала. Һермафродит затлар үзлектән аталану юлы белән 300 гә якын яралгы җитештерә. Аталанган күкәйләр аналыкка үтеп керәләр һәм анда тулысынча өлгерәләр, тышча белән капланалар. Йомырка салу көчле мускуллар белән тәэмин ителгән тышкы җенес тишеме – вүлва ярдәмендә башкарыла. 20 $^0$C та яралгының барлыкка килүе 18 сәгатькә сузыла, үсеше 48 сәгать дәвам итә һәм, җенси яктан җитлеккән зат булу өчен, үз эченә кабык салу белән алмашынучы дүрт корт чорын ала, болар L1, L2, L3 һәм L4 суалчаннары. Суалчаннар уңайсыз шартларда исән калуга юнәлтелгән чорга – даүәр корт чорына керергә сәләтле. Әлеге даүәр кортларын аз күләмдәге азык белән дүрт айга кадәр сакларга мөмкин [Zhao *et al.*, 2013].

Суалчаннарның кан әйләнеше һәм сулыш системалары юк. Аларның ялган целомик сыеклыклары күзәнәк эчендәге уттуар, күмер серкәсе кушылмасы һәм туклыклы матдәләр күчеше өчен тирәлек булып тора. Моннан тыш, һидростатик басымның тигезлеген саклап һәм

эчке әгъзалар арасында майлау матдәсе кебек тәэсир итеп, ул ионлы тигезләнеш булдыруга ярдәм итә [Gonzalez-Moragas *et al.*, 2015].

Үрчү тизлеге, тәненең үтә-күренмәлеге, кыска тереклек вакыты (3 көн), кыска гомер озынлыгы (2–3 атна), арзанлыгы һәм лаборатория шартларында үрчетүнең чагыштырмача гади булуы суалчаннарның әлеге төрләрен уңайлы өлге ясый [Qu *et al.*, 2011]. Моннан тыш, *C. elegans* – геномы билгеләнгән (1998) беренче күп күзәнәкле тереклек иясе [Gonzalez-Moragas *et al.*, 2015]. Геном зурлыгы 100 миллион пар тирәсе нигездән гыйбарәт; бу сан кеше геномына караганда шактый аз булса да, ике геном да охшаш сандагы геннарга ия (суалчанда – 20000 ген, кешедә – 23000). Биомәгълүмат тикшерүе билгеләгәнчә, *C. elegans* суалчанының 60–80% гены кешенеке белән охшаш [Hulme *et al.*, 2011]. Яхшы өйрәнелгән геном, күзәнәк сызыгының тулы харитасы, нокаут мутантлар җыелмасы һәм (мутагенез, трансгенез һәм РНӘ-интерференцияне дә кертеп) билгеләнелгән генетик алымнар *C. elegans* суалчанын молекуляр дәрәҗәдә дә өйрәнергә мөмкинлек бирә [Leung *et al.*, 2008].

*C. elegans* суалчаннары кайбер үзенчәлекләре аркасында биологик тикшеренүләрдә өлге буларак киң кулланыла. Иң элек, *C. elegans* суалчаннары, *Escherichia coli* бактерияләре белән тукланып, лаборатория шартларында зур чыгымнарсыз үстерелә ала. Кыска тереклек вакыты һәм югары үрчемлелеге аркасында, әлеге хайваннар аз вакыт эчендә зур сандагы токым бирергә сәләтле. Суалчаннарның озынлыгы (1,0 мм дан алып 1,5 мм га кадәр) һәм тәннәренең үтә-күренмәле булуы нанокисәкчекләрнең яки бактерияләрнең эчке әгъзаларда җыелуын һәм бүленешен күзәтергә мөмкинлек бирә (2 нче рәсем).

Йоткылык суыргычы белән дефекация дәвамлыгын күзәтү, мәсәлән, нанотоксикологиядә тәртип тайпылышларын өйрәнгәндә кулланыла [Zhao *et al.*, 2015]. Суалчаннарның нанокисәкчекләрне йотулары йоткылык суыргычының тизлегенә бәйле. Йоткылык суыргычы тизлеге белән исә азыкның булу-булмавы, температура, азык




2 нче рәсем. Караңгы кыр микроскобы ярдәмендә ясалган һиперспектраль микросурәтләр. А – Көмеш нанокисәкчекләрен ашаган *C. elegans* суалчанының алгы эчәклеге. Б – Табигый һәлосайт нанокөпшәләре ашаган *C. elegans* суалчанының йоткылыгы.

сыйфаты кебек эчке һәм тышкы сәбәпләр идарә итә. Мәсәлән, азык булмаганда, йоткылык суыргычының тизлеге дүрт тапкыр кимрәк була һәм дефекация вакыты 80 секундка арта [Fang-Yen *et al.*, 2009].

*C. elegans* тумыштан килгән иммунитетны һәм киеренкелеккә җавап бирүне өйрәнүдә алдынгы өлге булып тора. Суалчаннарның эчәклеге – агулы матдәләргә һәм әйләнә-тирәнең химик ярсыткычларына җавап бирүче төп урын. Төрле нанокисәкчекләрнең, эчәклектән үрчү системасына үтеп кереп, оогенезга, яралгының үсешенә, йомырка салуга, шулай ук киләчәк буынга да тәэсир итүе ачыкланган [Pluskota *et al.*, 2009].

Китерелгән таблицада төрле агулы матдәләр, җирдә сирәк очрый торган элементлар, нанокисәкчекләр һәм башка матдәләрнең *C. elegans* суалчаннарының үзтотышы, гомер озынлыгы, үсеше һәм геннар ифадәсенә тәэсир итүен билгеләүгә юнәлдерелгән тикшеренүләр турында мәгълүмат бирелгән.

Төрле матдәләр белән тәэсир итү вакытында *C. elegans* суалчаннарының үзтотышы, гомер озынлыгы һәм геннар ифадәсендә күзәтелгән үзгәрешләр һәм аларны микроскоп ярдәмендә сурәткә төшерү өлкәсендә уздырылган тикшеренүләр

| Агулылыкка тест | Күрсәткеч | Төрле матдәләр белән тәэсир итү | Сылтама |
|---|---|---|---|
| Үзтотыш | Хәрәкәт | Триадименол (фунгицид) *C. elegans* суалчанының хәрәкәт тотышына тискәре тәэсир итә. | [How, 2018] |
| | Дефекация | Җәрафин оксиды (100 мг / мл) яки квант нокталары (5 - 20 мг / л) белән озак вакыт тәэсир иткәннән соң, дефекация әйләнешенең уртача дәвамлыгы арту күзәтелә. | [Wu, 2014] [Wu, 2016] |
| | Йоткылык суыргычы | Җирдә сирәк очрый торган элементлар ($NdCl_3$ һәм $ScCl_3$ (30 мг / л), $PrCl_3$ (10 мг / л)) белән тәэсир иткәннән соң, йоткылык суыргычының ешлыгы кимегән. | [Xu, 2017] |
| | Һемотаксис | Бета-амилоидның нейрон ифадәсе NaCl аттрактантына карата һемотаксисны шактый кимәтә. | [Ahmad, 2018] |
| Картаю | Гомер озынлыгы | Силика яки көмеш нанокисәкчекләре (0,1–10 мг / мл) белән эшкәрткәннән соң, суалчаннарның гомер озынлыгы шактый кимегән. | [Acosta, 2018] [Piechulek, 2018] |
| | Үлем | Арсенит белән тәэсир итү лайпофусцин тупланышын арттыра. 100 мкМ лифосат (һербицид) белән тәэсир иткәндә тулы үлем күзәтелгән. | [García-Espiñeira, 2018] [Yu, 2016] |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Үсеш | Лайпофусцин тупланышы | Бисфенол А белән тәэсир итү вакытында лайпофусцин тупланышында әһәмиятле үзгәрешләр күзәтелмәгән. | [Tan, 2015] |
| | Уттуарның актив шикелләре | $TiO_2$, ZnO һәм ротенон уттуарның актив шикелләре туплануының артуына китерә. | [Sonane, 2017] |
| | Суалчаннарның үсеше | Антипиреннар иң аз күләмдә булганда суалчаннарның үсешен туктаталар. | [Behl, 2016] |
| | Гәүдә озынлыгы | Һәлосайт белән эшкәртелмәгән өлгеләр белән чагыштырганда, һәлосайтның (0,05–1 мг/мл аралыгында) нематодаларның гадәттәге гәүдә озынлыгына тискәре йогынты ясавы ачыкланган. Бу үсешнең тайпылышын күрсәтә. Тик һәлосайт белән капланган *E. coli* күзәнәкләрен йоту гәүдә озынлыгын киметми. | [Fakhrullina, 2015] |
| | Йомыркалар/ токым саны | Контроль белән чагыштырганда (72,2 ± 8,9 суалчан), цитринин токым санын 40,4 ± 9,6 суалчанга кадәр киметә. | [Keller, 2018] |
| Генетика | Геннар ифадәсе | Вакланган нәзек күмер кисәкчекләре белән тәэсир итү оксидлашу киеренкелеге белән идарә итүче геннар ифадәсендә үзгәрешләр китереп чыгара. | [Sun, 2015] |
| Микротехнологияләр | | Аерым-аерым урнаштырылган *C. elegans* нематодалары өчен микросыекчалы җайланма эшләнелгән. Әлеге җайланма ярдәмендә аерым суалчаннарның бөтен гомер озынлыгында зурлыкларындагы һәм гәүдә хәрәкәтләрендәге үзгәрешләрне күзәтеп барырга мөмкин. | [Hulme, 2010] |
| Микроскопия | | Исән нематодаларның эпитышчасы өслеген тикшерү өчен атом-көч микроскопиясен кулланганнар. Югары җетелекле караңгы кыр микроскопиясе ярдәмендә суалчаннарның эчәклегендә җыелган магнит һәм көмеш нанокисәкчекләренең таралышын күзәтергә мөмкин. Магнит нанокисәкчекләрнең нематодаларда бүленешен тагын да җентекләп өйрәнү өчен, үтүче электрон микроскоп та кулланылган. | [Akhatova, 2018] [Däwlätşina, 2013] [Naumenko, 2014] |

Суалчаннар туклыклы матдәләр әйләнешендә һәм әйләнә-тирәне саклауда зур әһәмияткә ия. Әлеге үзенчәлекләр аларны экотоксикологик тикшеренүләрдә файдалану өчен зур мөмкинлекләр ачты, һәм 1970 еллардан башлап, суалчаннарның кайбер төрләрен экология мәсьәләләрен өйрәнгәндә дә кулланалар [Leung *et al.,*2008].

Шулай итеп, *Caenorhabditis elegans* йомры суалчаннары гади, әмма бик җентекләп өйрәнелгән өлге булып торалар һәм алар ярдәмендә нано-био-тәэсир итешүне әгъзалар һәм молекулалар дәрәҗәсендә дә тикшерергә мөмкин.

**Әдәбият**

*Acosta C., Barat J.M., Martinez-Manez R., Sancenon F., Llopis S., Gonzalez N., Genoves S., Ramon D., Martorell P.* Toxicological assessment of mesoporous silica particles in the nematode *Caenorhabditis elegans* // Environmental Research. 2018. V. 166, P. 61–70.

*Ahmad W., Ebert P. R.* 5-Methoxyindole-2-carboxylic acid (MICA) suppresses Aβ-mediated pathology in *C. elegans* // Experimental Gerontology. 2018. V. 108, P. 215–225.

*Akhatova F., Fakhrullina G., Khakimova E., Fakhrullin R.* Atomic force microscopy for imaging and nanomechanical characterisation of live nematode epicuticle: A comparative *Caenorhabditis elegans* and *Turbatrix aceti* study // Ultramicroscopy. 2018. V. 194, P. 40–47.

*Andrew D., Suhong X.* The *Caenorhabditis elegans* epidermis as a model skin. II: differentiation and physiological roles // Wiley Interdisciplinary Reviews: Developmental Biology.http://www.ncbi.nlm.nih.gov/pubmed/25772622 2012. V. 1. P. 879–902.

*Barr M.M., De Modena J., Braun D., Nguyen C.Q, Hall D.H., Sternberg P.W.* The *Caenorhabditis elegans* autosomal dominant polycystic kidney disease gene homologs lov-1 and pkd-2 act in the same pathway // Curr Biol. 2001. V. 11. P. 1341–1346.

*Behl M., Rice J.R., Smith M.V., Co C.A., Bridge M., Hsieh J.-H., Freedman J.H., Boyd W.A.* Comparative toxicity of organophosphate flame retardants and polybrominateddiphenyl ethers to *C. elegans* // Toxicological Sciences. 2016. V. 154, P. 241–252.

*Cabreiro F., Gems D.*Worms need microbes too: microbiota, health and aging in *Caenorhabditis elegans* // EMBO Mol Med. 2013. V. 5. P. 1300–1310.

*Chiang J.T.,Steciuk M., Shtonda B., Avery L.* Evolution of pharyngeal behaviors and neuronal functions in free-living soil nematodes // J Exp Biol. 2006. V. 209. P. 1859–1873.

*Däwlätşina G.I., Minullina R.T., Fakhrullin R.F.* Microworms swallow the nanobait: the use of nanocoated microbial cells for the direct delivery of nanoparticles into *Caenorhabditis elegans* // Nanoscale. 2013. V. 5, P. 11761–9.

*Fakhrullina G.I., Akhatova F.S., Lvov Y.M., Fakhrullin R.F.,* Toxicity of halloysite clay nanotubes in vivo: a *Caenorhabditis elegans* study // Environmental Science: Nano. 2015. V. 2, P. 54–59.

*Fang-Yen C., Avery L., Samuel A.D.* Two size-selective mechanisms specifically trap bacteria-sized food particles in *Caenorhabditis elegans* // Proc Natl Acad Sci USA. 2009. V. 106. P. 20093–20096.

*Garcia-Espineira M., Tejeda-Benitez L., Olivero-Verbel J.* Toxicity of atrazine- and glyphosate-based formulations on *Caenorhabditis elegans* // Ecotoxicology and Environmental Safety. 2018. V. 156, P. 216–222.

*Gonzalez-Moragas L., Roig A., Laromaine A. C. elegans* as a tool for in vivo nanoparticle assessment // Adv Colloid Interface Sci. 2015. V. 210. P. 10–26.

*How C.M., Li S.-W., Liao V.H.* Chronic exposure to triadimenol at environmentally relevant concentration adversely affects aging biomarkers in *Caenorhabditis elegans* associated with insulin / IGF-1 signaling pathway // Science of the Total Environment. 2018. V. 640–641, P. 485–492.

*Hulme S.E., Shevkoplyas S. S., McGuigan A. P., Apfeld J., Fontana W., Whitesides G., M.* Lifespan-on-a-chip: microfluidic chambers for performing lifelong observation of *C. elegans* // Lab Chip. 2010. V. 10, P. 58–597.

*Hulme, S.E., Whitesides G. M.* Chemistry and the Worm: *Caenorhabditis elegans* as a Platform for Integrating Chemical and Biological Research // Angew. Chem.-Int. 2011. V. 50. P. 4774–4807.

*Keller J., Borzekowski A., Haase H., Menzel R., Rue L., Koch M.* Toxicity Assay for Citrinin, Zearalenone and Zearalenone-14-Sulfate Using the Nematode *Caenorhabditis elegans* as Model Organism // Toxins. 2018. V. 10, P. 284.

*Kim, S.W., Kwak J.I., An Y.J.* Multigenerational study of gold nanoparticles in *Caenorhabditis elegans*: transgenerational effect of maternal exposure // Environ Sci Technol.2013. V.47. P. 5393–5399.

*Leung, C.K., Williams P.F., Benedetto A., Au K., Helmcke K.J., Aschner M., Meyer J.N. Caenorhabditis elegans*: An Emerging Model in Biomedical and Environmental Toxicology // Toxicol Sci. 2008. V. 105. P. 5–28.

*Liegeois, S., Benedetto A., Michaux G., Belliard G., Labouesse M.* Genes required for osmoregulation and apical secretion in *Caenorhabditis elegans* //Genetics. http://www.ncbi.nlm.nih.gov/pubmed/25772622 – 2007. V. 175. P. 709–724.

*Naumenko E.A., Dzamukova M.R., Fakhrullina G. I., Akhatova F.S., Fakhrullin R.F.* Nano-labelled cells — a functional tool in biomedical applications // Current Opinion in Pharmacology. 2014. V. 18, P. 84–90.

*Piechulek A., A. von Mikecz.* Life span-resolved nanotoxicology enables identification of age-associated neuromuscular vulnerabilities in the nematode *Caenorhabditis elegans* // Environmental Pollution. 2018. V. 233, P. 1095–1103.

*Pluskota, A., Horzowski E., Bossinger O., Mikecz A.* In *Caenorhabditis elegans* Nanoparticle-Bio-Interactions Become Transparent: Silica-Nanoparticles Induce Reproductive Senescence // PLoSOne. 2009. V. 4. e6622.

*Qu, Y., Li W., Zhou Y., Liu X., Zhang L., Wang L., Li Y.F., Iida A., Tang Z., Zhao Y., Chai Z., Chen C.* Full assessment of fate and physiological behavior of quantum dots utilizing *Caenorhabditis elegans* as a model organism // Nano Lett. 2011. V. 11. P. 3174–3183.

*Sonane M., Moin N., Satish A.* The role of antioxidants in attenuation of *Caenorhabditis elegans* lethality on exposure to $TiO_2$ and ZnO nanoparticles // Chemosphere. 2017. V. 187, P. 240–247.

*Sulston, J.E., Schierenberg E., White J.G., Thomson J.N.,* The embryonic cell lineage of the nematode *Caenorhabditis elegans* // Dev Biol.http://www.ncbi.nlm.nih.gov/pubmed/25772622 1983. V. 100. P. 64–119.

*SunL., Lin Z., Liao K., Xi Z., Wang D.* Adverse effects of coal combustion related fine particulate matter (PM2.5) on nematode *Caenorhabditis elegans* // Science of the Total Environment. 2015. V. 512–513, P. 251–260.

*Tan L., Wang S., Wang Y., He M., Liu D.* Bisphenol A exposure accelerated the aging process in the nematode *Caenorhabditis elegans* // Toxicology Letters. 2015. V. 235, P. 75–83.

*Zhao, Y., Qian L., Shakoor S., Gong J., Wang D.* Transgenerational safety of nitrogen-doped graphene quantum dots and the underlying cellular mechanism in *Caenorhabditis elegans* // Toxicol. Res. 2015. V. 4. P. 270–280.

*Zhao Y., Qiuli W., Li Y., Wang D.* Translocation, transfer, and in vivo safety evaluation of engineered nanomaterials in the non-mammalian alternative toxicity assay model of nematode *Caenorhabditis elegans* // RSC Adv. 2013. V. 3. P. 5741–5757.

*WuQ., Zhao Y., Li Y., Wang D.* Molecular signals regulating translocation and toxicity of graphene oxide in the nematode *Caenorhabditis elegans* // Nanoscale. 2014. V. 6, P. 11204–12.

*Wu Q., Zhi L., Qu Y., Wang D.* Quantum dots increased fat storage in intestine of *Caenorhabditis elegans* by influencing molecular basis for fatty acid metabolism // Nanomedicine. 2016. V. 12, P. 1175–1184.

*Xu T., Zhang M., Hu J., Li Z., Wu T., Bao J., Wu S., Lei L., He D.* Behavioral deficits and neural damage of *Caenorhabditis elegans* induced by three rare earth elements // Chemosphere. 2017. V. 181, P. 55–62.

*Yu C.W., How C.-M., Liao V.-H.* Arsenite exposure accelerates aging process regulated by the transcription factor DAF-16 / FOXO in *Caenorhabditis elegans* // Chemosphere. 2016. V. 150, P. 632–638.

*Мәкалә Рәсәй фундаменталь тикшеренүләр маясының 18-3400778 № лы гранты кысаларында тормышка ашырылды.*

***Фахруллин Равил Фәрид улы,***
*биология фәннәре докторы, Казан федераль университеты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының баш гыйльми хезмәткәре*

***Шәйхелова Сәрбиназ Фәнис кызы,***
*Казан федераль университеты бакалавры, Фундаменталь медицина һәм биология институтының лаборанты*

***Фахруллина Гөлнур Илдар кызы,***
*Казан федераль университеты аспиранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының гыйльми хезмәткәре*

***Нигәмәтҗанова Ләйсән Рәфис кызы,***
*Казан федераль университеты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының лаборанты*

УДК 821.512.145

*А.Ф. Ганиева*

# МИЛЛИ ҖАНЛЫ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ һӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ
## (Флүн Мусинның тууына 80 ел)

Флюн Муслахович Мусин внёс большой вклад в изучение истории татарской литературы XX века. Автор статьи рассматривает наследие учёного не только в области литературоведения и литературной критики, но и освещает его общественно-педагогическую деятельность.

**Ключевые слова:** Флюн Муслахович Мусин, учёный, татарская литература, критика, проза.

Flyun Muslakhovich Musin made a great contribution to the study of the history of Tatar literature of the twentieth century. The author of the article not only considers the heritage of a scientist in the field of literary criticism, but also highlights his social and pedagogical activity.

**Keywords:** Flyun Muslakhovich Musin, scientist, Tatar literature, criticism, prose.

Татар әдәбият белеме һәм тәнкыйте үсешенә зур өлеш керткән Флүн Мусинның фән өлкәсендә яулаган уңышлары сокланырлык һәм үрнәк алырлык. Ул – филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Кол Гали исемендәге бүләк иясе. Тормышын фәнгә, үз халкының рухи хәзинәсен барлауга багышлаган могтәбәр затның тормыш юлы сикәлтәләрсез генә булмый.

Флүн Мөслах улы Мусин 1939 елның 23 февралендә Татарстанның Мөслим районы Иске Карамалы авылында дөньяга килә. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк этисе хәбәрсез югалган малайны тормыш кечкенәдән авырлыкларга бирешмәскә өйрәтә. Башлангыч белемне Флүн үз авылында алса, урта мәктәпне күрше Күбәктә тәмамлый. Алга таба үсмер Флүн ул чор авыл баласы өчен табигый булмаган адым ясый: А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтына укырга керергә дип, Мәскәүгә китеп бара. Әлеге институтка студентлар Язучылар союзыннан тәкъдим кәгазе белән генә алынганлыктан, Ф. Мусин анда кабул ителми, әмма имтиханнарны уңышлы тапшырып, Мәскәү дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, билгеләнү буенча, Казанга кайтып, «Социалистик Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый.

Мәскәүдә уку, башка халыкларның да әдәби мохитендә кайнау, мәдәни тормышларында катнашу, табигый, Ф. Мусинның дөньяга карашын киңәйтә. Чордашлары билгеләвенчә, булачак галим 60–70 нче елларда «яңача фикер йөртүче» буларак таныла [Хәбибуллин, б. 84]. Газета битләрендәге мәкаләләре фәнни нигезле, объектив фикерле,

заманча булулары белән аерылып тора. Шулай да аны фән дөньясы ныграк кызыксындыра. Һәм ул 1963 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлый.

1968 елда «60 нчы елларда татар прозасында уңай герой проблемасы» дигән темага – кандидатлык, ә 1983 елда А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында «Татар совет прозасында сәнгатьлелек тәҗрибәсенең күчемле үсеше» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

Ф. Мусин күпкырлы гыйльми эшчәнлек алып бару белән беррәттән, әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә җитди шөгыльләнә. Аның мәкаләләре еш кына үзәк матбугатта, аерым алганда, «Правда», «Литературная газета», «Вопросы литературы», «Журналист», «Дружба народов», «Октябрь», «Тюркология» кебек газета-журналларда дөнья күрә. Моның белән ул, бер яктан, татар әдәбиятын танытуга булыша, икенче яктан, әдәбият белемен һәм тәнкыйтен үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертә.

1960–1980 елларда Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, әдәби тәнкыйть секциясе җитәкчесе буларак, Ф. Мусин әдәби тәнкыйть эшен оештыруга күп көч куя. Ф. Мусин республика матбугатында хәзерге әдәбиятның актуаль мәсьәләләре хакында түгәрәк өстәлләр, дискуссияләр оештыра, алдынгы язучылар һәм галимнәр катнашында милли әдәбият турында зур сөйләшүләр алып бара. Ә инде Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире вазифасын башкарганда «Татар әдәбияты тарихы»н фәнни нигездә эшләүне башлап йөрүчеләрдән була. Институтның Г. Тукай, И. Гаспринский, Ә. Кунанбаев, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Җәлил, Һ. Такташ, Ш. Госманов, кебек шәхесләргә багышлап үткәргән халыкара фәнни-гамәли конференцияләрен оештыру эшләрендә катнаша һәм тирән эчтәлекле докладлар белән чыгыш ясый.

Ярты гасыр дәвамында республиканың мәдәни тормышында актив кайнаган Ф. Мусин милли әдәби-тәнкыйди һәм әдәби фикер үсеше үзенчәлекләрен билгеләүче фигураларның берсенә әверелә. Күпгасырлык әдәбиятыбызның кайсы гына чорын алма, галимнең һәр язучы иҗатына үз бәяләмәсе, аерым бер дәвергә карата үз фәнни карашы бар. Ф. Мусин татар әдәбиятының актуаль мәсьәләләренә, аерым язучылар иҗатына багышлап 400 дән артык мәкалә яза, 15 китап нәшер итә. Аның «Тормыш сынавы» (Казан, 1969), «Тарих һәм заман» (Казан, 1974), «По координатам жизни» (Мәскәү, 1976), «Связь времён» (Казан, 1979), «Тормыш үзәненнән» (Казан, 1987), «Көмеш көзге» (Казан, 1989), «Гаяз Исхакый: тормышы һәм эшчәнлеге» (Казан, 1998), «Гаяз Исхакыйның революциягә кадәрге иҗаты» (Казан, 1998), «Татар әдәбиятының хәзерге этаптагы үсеше мәсьәләләре» китап-монографияләрендә галим, әдәбият фәне һәм бөтенсоюз әдәбияты ирешкән казанышлар югарылыгыннан торып, татар прозасының бүгенге хәленә күз ташлый, аның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәреш-

ләрен, тематикасын, жанр үзенчәлекләрен, аерым язучыларның теге яки бу жанрга керткән өлешен, яңалыгын тикшерә, бер үк вакытта әдәби традицияләрдән файдалану юллары, әдәби герой һәм чынбарлык, халыкчанлык, прозада документаль нигез, тарихилык, милли стиль, әдәбиятның публицистик пафосы кебек мөһим теоретик проблемалар турында сүз алып бара [Габидуллина, б. 88].

Узган гасырның 80 нче еллары уртасында галим халкыбызның рухи-мәдәни мирасын тагын да әтрафлырак өйрәнеп, халыктан яшереп яткырылган әсәрләрне кире кайтару турында уйлана башлый. 1987 елда Республика мирас комиссиясе төзелә һәм аның җитәкчесе итеп Ф. Мусин билгеләнә. Бу комиссия күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый мирасын туган халкына кайтаруны максат итеп куя. Сөенечле нәтиҗәләр дә озак көттерми: әлеге комиссия Татар «Мирас» фонды булып рәсми рәвештә теркәлә һәм Ф. Мусин аның президенты итеп сайлана. Фонд 1991 елда үзенең матбугат органын – «Мирас» журналын гамәлгә куя. Татар «Мирас» фонды, бөтендөнья татарларын берләштерү максатында, халыкара татар корылтаен үткәрү инициативасы белән чыга. Белүебезчә, Бөтендөнья татар конгрессының инде берничә корылтае булып узды.

Ф. Мусин, Гаяз Исхакыйның әдәби һәм сәяси эшчәнлеген өйрәнеп, милләтебезне рухи савыктыру турында уйлана. Шул елларда матбугатта дөнья күргән «Татарның киләчәген кайгыртып», «Татарны ничек сакларга», «Русиядә татар булып яшәү җиңелме?», «Интернет хаталансын, дисәк...», «Татарны чын татар итү турында» дигән мәкаләләрендә галим халкыбыз язмышына кагылышлы җитди мәсьәләләр күтәрә, милләтнең киләчәге яшь буынны тәрбияләүгә бәйле булуына басым ясый. Мәсәлән, «Милли идея байрагы астында» дигән мәкаләсендә Ф. Мусин XXI гасыр кешелекнең гуманлашу дәвере булырга тиешлеген ассызыклый һәм гуманитар фәннәрнең иҗтимагый-идеологик роле арту турында яза. Әлеге фәннәр заман ихтыяҗына бәйле рәвештә яңартылырга тиеш. Флүн Мусин бу эшнең фәнни-методологик характердагы программ документ – гуманитар фәннәрне алга таба үстерүнең яңа концепциясен булдырудан башланырга тиешлеген әйтә, әдәбият тарихы һәм теориясен, хәзерге карашлардан чыгып, максатчан, системалы һәм комплекслы өйрәнү юнәлешләрен эшләүдә үз тәкъдимнәрен кертә. Галим концепция нигезендә милли идея ятарга тиешлеген ассызыклый.

90 нчы елларда барлыкка килгән рухи-сәяси үзгәрешләр мәгариф өлкәсенә дә үтеп керде һәм яңа дәреслекләр эшләү мәсьәләсен көн тәртибенә куйды. Ф. Мусин бу өлкәдә дә активлык күрсәтә: методистлар һәм укытучылар белән берлектә, рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбияттан программалар һәм 7–11 нче сыйныфлар өчен дәреслек-хрестоматия төзүдә катнаша.

Кешелекнең яңа дәвергә аяк басу чорында яшь буынга гуманлы тәрбия бирүнең асылын нечкә тоемлаган галим бу эшнең ана теле мөгаллимнәренә бәйле булуын ачык күзаллап, аларга бүгенге көн

таләпләренә җавап бирерлек белем бирү буенча җитди эш алып бара, Казан дәүләт университетында, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында, ТР Укытучылар белемен күтәрү институтында укыта, Россиянең татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә булып, анда татар теле һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрү юнәлешендә эшли.

Флүн Мусин – татар әдәбияты фәнендә үз мәктәбен булдыруга ирешкән галим. Аның дистәләгән шәкертләре, укучылары, әдәбият фәне өлкәсендә һәм татар иҗтимагый тормышында актив эшләп, остазлары юлын дәвам итәләр.

**Әдәбият**

*Габидуллина Ф.И.* Флүн Мусин хезмәтләрендә Г. Ибраһимов // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы Международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 2017. С. 88–95.

*Хәбибуллин М.* Галим, көрәшче, милләтпәрвәр // Мирас. 1999. № 2. Б. 83–86.

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Эрҗан Алкая***

# ТЕЛ ГАЛИМЕ – ИЛ АГАСЫ
## (Фәрит Йосыповка 80 яшь)

В статье освещаются основные вехи и направления научной деятельности известного татарского языковеда (лингвиста, диалектолога) и общественного деятеля Ф.Ю. Юсупова, труды которого внесли большой вклад в развитие современного татарского языкознания. Она посвящается 80-летию со дня рождения учёного.

**Ключевые слова:** татарское языкознание, диалектология, лингвистичекая география, ареальная лингвистика, татарский диалектный язык.

The article highlights the main milestones and directions of research activities of the famous Tatar linguist (linguist, dialectologist) and public figure F.Yu. Yusupov, whose works have greatly contributed to the development of modern Tatar linguistics. It is dedicated to the $80^{th}$ birthday of the scholar.

**Key words:** Tatar linguistics, dialectology, linguistic geography, areal linguistics, Tatar dialect language.

Фәрит (Феритс) Йосыф улы Йосыпов – XX гасырның икенче яртысында иҗат итә башлап, тюркология һәм татар тел белеменә яңа юнәлешләр алып килгән галимнәрнең берсе. Ул Татарстанның Яшел Үзән районында Алтын Урда дәүләтенең атаклы Кара Хуҗа нәселләре тарафыннан нигез салынган Караужа (Кара Хуҗа) авылында 1939 елда гаиләдә өченче бала булып дөньяга килгән. Атасы Йосыф Камалиев Икенче Бөтендөнья сугышында каһарманнарча һәлак булган. Әнисе Асия өч баласын да сугыш елларындагы коточкыч ачлыктан саклап калып, соңыннан аларга югары белем алырга ярдәм иткән. Сугышка чыгып киткәндә, әтисе ике яшьлек улы Фәритне кулына алып: «Әнисе, бу балам – багалмамны, исән-имин үстереп, университетта укытырга тырыш инде. Бигрәк кечкенә бит. Сәләте дә күренеп тора. Абыйсы да, апасы да аякларында нык басып торалар. Алар үзләрен үзләре сакларлык инде. Монысы өчен бигрәк өзеләм», – дигән. Бер елдан соң иң дәһшәтле сугышлар булган Курск дугасында Йосыф ага мәңгелеккә ятып кала. Асия апа иренә биргән изге антына тугрылыклы кала: өч баласына да югары белем бирә. Олы улы Йөзем Камалиев хәрби университет тәмамлый, лаеклы ялга чыкканчы, Мордовия, Марий Эл республикаларында хәрби комиссариат башлыгы булып эшли. Бик күп дәүләт бүләкләренә лаек була.

Фәрит, туган авылында урта мәктәпне уңышлы тәмамлап, 1956 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты каршында сугыш елларында яңа ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент елларын да бушка үткәрми ул: фән белән шөгыльләнә башлый, вакыты булганда татар радиосында һәм телевидениедә эшли.

Фәрит Йосыповның диплом эше дә төрки тел белемендә экспериментать фонетика юнәлешенә нигез салган, 1928 елда Халыкара эксперименталь фонетика җәмгыятенә әгъза итеп сайланган күренекле татар телчесе, Татарстан Автономияле республикасын төзүдә катнашкан, әмма репрессия корбаны булган Галимҗан Шәрәфнең югалган хезмәтләрен табып өйрәнүгә багышланган була. Бу эш белән хәтта хөкүмәт оешмалары да шөгыльләнеп караган, әмма татар фәне күгендә якты йолдызга тиң галимнең бер генә хезмәте дә табылмаган. Рәсми хисап язмаларында галимнең басылган һәм басылмаган хезмәтләре репрессия елларында тулаем юкка чыккан дигән юллар бар. Ф. Йосыпов Г. Шәрәфнең үз куллары белән берничә капчыкка тутырып калдырган кульязмаларын ягарга дип әзерләнгән макулатура арасыннан табып ала.

Бу вакыйганы татар галимнәре искиткеч куанычлы вакыйга дип кабул итәләр. Остазлары әйтүенчә, студент Ф. Йосыповның бу гамәле татар халкы тарихына, татар фәненә керткән беренче хезмәте буларак бәяләнә.

Университетны тәмамлаганнан соң, ул Кама Тамагында район газетасының җаваплы сәркатибе, аннан соң СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми хезмәткәр булып эшли. Күп тә үтми яшь белгечне, М.З. Зәкиев, Д.Г. Тумашева, Л.Т. Мәхмүтова кебек үз чорының атаклы галимнәре белән бергә, татар теленең беренче академик грамматикасын язу белән шөгыльләнәчәк авторлар коллективына кабул итәләр. 1969 елда рус телендә Мәскәүдә басылып чыккан әлеге китап хәзер дә татар тел белеме өлкәсендәге мөһим хезмәтләрдән санала. Яшь галим аның «Бәйлекләр», «Ярдәмче исемнәр», «Теркәгечләр», «Модаль сүзләр» һәм «Ымлыклар» дип исемләнгән өлешләрен яза. Аларда ярдәмче сүз төркемнәре килеп чыгышлары ягыннан, грамматик һәм модаль мәгънәләреннән чыгып өйрәнелгән. Әлеге басма бүген дә башка төрки телләр буенча язылачак грамматикаларга өлге булып тора.

Ф. Йосыпов Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлаган елларда Советлар Берлегендә яшәүче төрки халыкларның Диалектология атласын төзү эше башлана. Соңыннан барлык телләр буенча җыелган материалларны фәнни-теоретик яктан гомумиләштерү фараз ителә. Әлеге юнәлешнең төп координаторы итеп дөньякүләм билгеле төрки телләр белгече Ә.Р. Тенишев (киләчәктә Ф. Йосыповның докторлык диссертациясенең фәнни җитәкчесе) билгеләнә. Күренекле диалектологлар Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова белән беррәттән, Ф. Йосыпов та Татар атласының төп төзүчесе буларак раслана. Татар диалектологлары бу эшкә аеруча рухланып тотыналар.

Шушы өлкәдә җаны-тәны белән бирелеп эшләгән Ф. Йосыповка остазлары Көньяк Урал һәм Урал артында таралган татар сөйләшләрен лингвистик-географик метод кулланып өйрәнү эшен тапшыралар. Ул аның кандидатлык диссертациясенең темасы да була.

Кайбер белгечләр әлеге сөйләшләрне, Казан ханлыгы җимерелгәч, геноцидтан һәм көчләп чукындырудан качып килгән казан татарлары белән бәйләп карыйлар. Ф. Йосыпов, бу фикерләргә каршы чыгып, аларның элеккеге Себер ханлыгы җирләрендә яшәгән себер татарлары авылларына казан татарлары килеп утыргач, кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән мөстәкыйль этник төркемнәр булуын әйтә.

Соңрак Ф. Йосыповның Урал артында яшәүче татарларның телен, рухи мирасын өйрәнүгә багышланган зур күләмле фәнни монографияләре басылып чыга. Шуларның берсенә – татар телендә язылган «Сафакүл татарлары. Үткәне һәм бүгенгесе» китабына – Курган өлкәсе губернаторы О. Богомолов кереш сүз язып, бу төбәк татарларының эш сөючәнлеген, борынгы тарихлары белән горурланып, ата-бабаларыннан килгән гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап калуга омтылуларын, туган якны ихлас яратуларын ассызыклый. Китап авторын үз халкы белән горурланучы талантлы татар галиме дип атый.

Урал төбәгендәге татар сөйләшләрен өйрәнеп бетергәннән соң, Ф. Йосыпов башка өлкәләрдә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен тикшерүне дәвам итә.

Ф. Йосыпов себер татарлары арасына беренче тапкыр остазы, ул вакытта Казан университеты доценты Диләрә Гариф кызы Тумашева җитәкләгән фәнни экспедиция составында килә. Себер татарлары белән очрашу аңарда онытылмаслык хатирәләр калдыра. Телләре бераз сәеррәк яңгыраса да, колакка шул кадәр ятышлы булып тоела. Себер татарлары арасында Ф. Йосыпов үзен җанлы музейдагы кебек хис итә. Себернең иксез-чиксез киңлекләре аны тылсымлы энергиясе белән һәр елны үзенә тарта башлый. Ул, 1957 елдан башлап, 50 ел рәттән себер татарлары янына барып йөри, киләчәк фәнни эзләнүләренә нигез булырлык бихисап матераллар туплый.

Бүгенге көндә татар диалектологлары барлык татар сөйләшләрен лингвистик-географик метод белән өйрәнүне тәмамлап, татар ареалогиясе фәне «капкаларына» килеп җиттеләр. Тел географиясе бер тел системасындагы аермалы яки уртак якларны, шул тел туфрагында таралган тел күренешләрен махсус изоглоссалар белән күрсәтсә, ареалогия фәне исә бу күренешләрне бер тел эчендә генә түгел, ә бәлки кардәш телләр семьялыгы кысаларында өйрәнә. Бу очракта халыклар, телләр арасында бик борынгы заманнарда булган тарихи мөнәсәбәтләрне күзәтергә мөмкин. Ф. Йосыповның «Татар фигыльләрен ареалогик метод белән өйрәнү. Фигыль категорияләре» (1988) дигән докторлык диссертациясе татар тел белемендә бу фәннең беренче карлыгачы булып саналырга хаклы.

Галим, Россиянең иксез-чиксез территорияләрен йөреп чыгып, татар диалектлары, бер төркем аермалы билгеләре белән бер-берләренә каршы куелуга карамастан, иң беренче чиратта, уртак системалы элементлар нигезендә, милли телнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр дигән әһәмиятле нәтиҗәгә килә. Ул диалектлар системасында

күзәтелгән аермалыклар һәр диалектның классификацион билгеләре булып кына саналырга тиеш дип исәпли. Татар теленең төрле шивә һәм сөйләшләре арасында кайбер аермалыклар булуга карамастан, әлеге өлешләрне бер система итеп берләштерә торган тел бөтенлеге яшәп килә. Хәзерге татар телен катлаулы структур элементларның системалы җыелмасы буларак өйрәнү аның аерым элементлары арасындагы закончалыклы бәйләнешләрне аңлауда мөһим теоретик һәм гамәли әһәмияткә ия. Галим фикеренчә, диалектлар арасындагы бәйләнешләрнең макро-система (милли тел) кысаларындагы мөнәсәбәтләре, аның катлаулы системалар системасы буларак яшәп килүен чагылдыра. Татар шивәләрен, сөйләшләрен гомер буе өйрәнгән тәҗрибәле диалектолог түбәндәге нәтиҗәгә килә: милли тел составындагы диалектлар, бер яктан, барлык диалектлар өчен уртак элементларның, икенче яктан, һәр диалект өчен генә хас үзенчәлекләрнең диалектик бердәмлеген тәшкил итә. Уртак билгеләр нигезендә хосусый диалектлар (яки барлык диалектлар системасы) системалар системасы (милли тел яки милли телнең бер варианты) буларак аңлатыла.

Татар шивә теле актив кулланыла торган билгеләре белән башка кыпчак телләренә, аерым алганда, Алтын Урда дәүләте составында булган башкорт, карачай-балкар, комык, кырым татарлары, караим телләренә якын тора. Чик буе элементлары исә татар шивәләренең хосусый билгеләрен хасил итәләр.

Ф. Йосыпов, татар шивәләрен, сөйләшләрен шушы рәвешчә өйрәнү өчен, аларны әдәби тел статусына тиңләргә киңәш итә. Сөйләш яки шивә – әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган аралашу чарасы түгел, бәлки төзелеше ягыннан әдәби тел кебек бер күренеш. Аларның төзелеше әдәби телгә хас категорияләрнеке кебек. Әгәр дә шивә телендә бөтенләй яңа категорияләр күзәтелсә, ул башка телләрдән кергән күренеш итеп карала. Мондый күренешләр системалы төс алганда, бу шивә яки сөйләш күрше телнең сөйләше яки бер телдән икенче телгә күчүче телара шивә, я булмаса, телара сөйләш итеп каралырга тиеш була.

Тюркология фәнендә яңалык булган бу диссертацияне Россия фәнни җәмәгатьчелеге зур кызыксыну белән кабул итә. Татар галименең әлеге хезмәтендәге төп фикерләре аның Россиядә һәм чит илләрдә нәшер ителгән күпсанлы мәкаләләрендә һәм китапларында чагылыш таба. Шуларның кайберләрен генә әйтеп китәбез: «Неличные формы глагола в диалектах татарского языка (академик Э.Р. Тенишев фәнни редакциясендә. Казан университеты нәшрияты, 1985. 321 б.); «Татар фигыльләрен өйрәнү» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1986, 300 б.); «Морфология татарского диалектного языка. Категории глагола» (Казан: Фән, 2004, 592 б.); «Tatar şive dillinin morfolojisi» (Elazig: Manas, 2013, 602 s.).

Ф. Йосыповның «Морфология татарского диалектного языка. Категории глагола» монографиясе 2004 елда Казан университетының 200 еллыгына багышланган фәнни хезмәтләр конкурсында 500 хезмәт

арасында беренче урынны ала. Шул ук китап Россия мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан классик университетлар өчен ареалогия буенча дәреслек буларак раслану турында махсус диплом белән бүләкләнә.

Ф. Йосыпов тарафыннан төзелә башлаган «Себер татарлары халык әдәбияты антологиясе» дә себер татарларының рухи хәзинәләрен саклап калуга үзенең өлешен кертер дип уйлыйсы килә. Бу китаплар да (бүгенге көндә аның 3 томы дөнья күрде инде), себер татарларының телен саклап калуны максат итеп, ике телдә – себер татарлары диалектларында һәм русча нәшер ителгән. Моңа кадәр себер татарларының халык әдәбияты үрнәкләрен бастырып чыгару очраклары да гаять сирәк очрый иде. Антологиянең беренче томында тобол-иртыш татарлары халык әдәбияты жанрларыннан дастаннар, мөнәҗәтләр, бәетләр урын алган. Китап себер татарларының формалашу тарихын аңлаткан зур кереш мәкалә белән башланып китә. Томның зур өлешен дастаннар алып тора. Татар халкында дастаннар, башка төрки халыклар белән чагыштырганда, бик аз сакланып калган. Дастаннарны телдән сөйләү традициясе татарларда XX гасырга кадәр үк югалып бетә язган. Бу татарларда уку-язу культурасының бик борынгыдан килүе турында сөйли.

Дастаннарның телдән сөйләнә торган версияләре өлешчә себер татарларында гына сакланып калган. Ф. Йосыпов моны аларның татар халкының башка төркемнәреннән, зур юллардан ерак урнашулары, Себер туфрагында уку-язу культурасының әллә ни югары булмавы белән аңлата. Галим себер татарлары халык әдәбияты антологиясенең беренче томында һәр дастанның сакланып калган төрле вариантларын бирергә тырышкан. Ул аларны түбәндәге төркемнәргә бүлгән:

1. Каһарманнар турындагы дастаннар. Бу дастаннарның күбесендә борынгы төрки дәвердә безнең уртак бабаларыбызның тарихи яшәеше өчен хәлиткеч саналган вакыйгаларда, зур сынауларда дошманны җиңеп чыккан алыплар, батырлар, пәһлеваннар турында сөйләнә. Шундыйлардан Йөртешлек, Ак Күбек, Кара Күкел, Күр углы, Алпамыш һ. б. ны күрсәтергә мөмкин. Дастаннар халык хәтереннән җуела башлагач, аларны алыплар турындагы риваятьләр алмаштыра.

3. Татарларда тарихны шәхесләр ясый гыйбарәсе киң таралган. Бәлкем, бу дөреслеккә дә туры киләдер. Борынгы төркиләрнең мондый шәхесләрен Бүрехан, Ак Буга, Тимер Кендек һ.б.ның батырлыклары аша белә алсак, безгә Алтын Урда тарихындагы хәлиткеч тарихи вакыйгалар Туктамыш, Идегәй образлары аша килеп җиткән. Туктамыш ханның иле, халкы белән саубуллашуга багышланган әчкерсез җырлары, ничәмә гасырлар үтүгә карамастан, туңган йөрәкләрне дә утка сала.

3. Мәхәббәт дастаннары. Төрки халыкларда җиткән егет һәм кызларның саф мәхәббәтләре турында сокланып сөйли торган дастаннар киң таралган була. Мондый дастаннар гадәттә чичән сөйләвенә

табигый ялганып китә торган җыр-көй белән башкарылган. Аларга мисал итеп себер татарлары арасында да киң таралаган Таһир – Зөһрә дастанын күрсәтергә мөмкин. Төрки кавемнәрнең күпчелегендә ятып башкарылган «Сәйфелмөлек» дастанын себер татарлары XIX гасыр башларына кадәр яхшы хәтерләгәннәр. Ф. Йосыпов, төрки фольклор фәнендә беренче буларак, бу дастаннарның көен ноталары белән бирә. Бу – борынгы төрки дастаннарның яңарышын ерак тарихка кадәр исән-имин җиткерү максатында башкарыла.

Себер татарлары халык әдәбияты антологиясенең икенче томы элекке заманнарда халык арасында аеруча популяр булган йомак-масал жанрына багышлана. Бу томдагы халык әдәбияты үрнәкләре белән таныш булмаган кеше себер татарлары халык авыз иҗаты йомакларга шулкадәр бай булыр дип башына да китереп карамагандыр. Ф. Йосыпов йомакларны төркемләгәндә, рус һәм Европа фәнендә кабул ителгән принципларны кабул итми. Аларны хайваннар турындагы, тормыш-көнкүреш, тылсымлы йомакларга бүлүне бик тә формаль дип саный. Себер татарларының һәр йомагында, башка төрки халыклардагы кебек үк, кешеләрнең гадәти тормыш-көнкүрешенә нигезләнгән гайре табигый хәлләр сурәтләнә. Әмма алар тыңлаучыны яки укучыны җәлеп итә алырдай маҗараларга төрелгән була.

Бу томда шулай ук Ислам дине кыйммәтләрен пропагандалаган йомакларга зур игътибар бирелә. Аларның каһарманнары, авыр хәлләргә калганда, үзләренә ярдәм итә алачак бер генә затка – Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәләр, догалар, сүрәләр ярдәмендә бәла-казалардан котылалар, дошманны җиңеп чыгалар. Себер татарлары халык әдәбиятында Исламга бәйле йомаклар булу Хак динебез тамырларының Себердә яшәгән кан кардәшләребез арасында бик тирәнгә китүе турында сөйли.

Себер татарлары халык әдәбиятының өченче томында татар фольклористикасында моңарчы игътибар ителмәгән хикәят (халык хикәяләре) жанрына киң урын бирелгән. Килеп чыгышы буенча борынгы һинд, фарсы әдәбиятларына барып тоташкан хикәят жанры да себер татарларына Ислам дине белән бергә килеп керә. Дин әһелләре аның дидактик (нәсыйхәт) характерда булуына игътибар иткәннәр һәм дини вәгазьләрендә бик уңышлы файдаланганнар. Халык хикәятләре яратып тыңланган, алар үрнәгендә яңалары иҗат ителгән. Болар барысы да халык аңында камил мөселман үрнәген тудырырга ярдәм иткән.

Бу томда шулай ук күп төрле риваятьләргә, борынгы мәҗүсилек чорында халыкның дөньяны танып белүе барышында туган мифларга зур урын бирелгән. Алар себер татарлары рухи мәдәниятенең Ислам динендәге башка халыклар культурасы белән тыгыз бәйләнгәнлеге турында сөйли.

Себер татарлары халык авыз иҗаты антологиясенең дүртенче томы музыкаль мираска багышлана. Ул 2018 елда басылып чыга. Биредә себер татарлары музыкаль жанрларына караган 400 гә якын

әсәр нота язмалары белән тәкъдим ителә. Алар арасында инде халык хәтереннән югалып баручы дастаннарның да ноталары бар. Димәк, безнең борынга дастаннарыбыз әле эзсез югалуга дучар ителмәгән.

Ф. Йосыпов үзенең күпкырлы иҗатында классик фән мәсьәләләре белән генә шөгыльләнмәгән. Ул халык тормышындагы кайбер проблемаларны хәл итү юнәлешендә дә эшләргә мәҗбүр була. Узган гасырның 70 нче елларында Советлар Берлеге уку йортлары фәнни дәрәҗәле галимнәргә кытлык кичерә. Бу яктан Татарстан мәктәпләре өчен укытучылар әзерли торган Алабуга педагогия институты аеруча авыр шартларда кала. Татарстан хөкүмәте әле генә кандидатлык диссертациясе яклаган галимгә шушы институтның чит телләр факультетын җитәкләргә тәкъдим итә. Ф. Йосыпов 1972–1994 елларда анда чит телләр факультетының деканы вазифаларын башкара. Советлар Берлегендә чит илләрне тимер пәрдә аша да карарга рөхсәт булмаган елларда ул татар балаларының Германия, Англия уку йортларында белем алуына ирешә, татар мәктәпләрен чит телләр укытучылары белән тәэмин итүгә зур өлеш кертә.

Советлар Берлегенең соңгы еллары якынлаша. Татарстанда яшәүче руслар да татарларга, аларның телләренә түземлерәк булырга тырышалар. Татарстан мәктәпләрендә рус балаларына татар теле укытуга да элеккеге кебек үк фаҗига итеп карамыйлар. Республика җитәкчелеге ул вакытта Милли мәктәпләр институтын җитәкләгән Ф. Йосыпов алдына рус балаларын татар теле дәреслекләре белән тәэмин итү бурычын куя. Институт хезмәткәрләре татар мәктәпләренә генә түгел, бәлки рус мәктәпләре өчен дә татар теле, татар әдәбияты буенча уку программалары, дәреслекләр, методик кулланмалар әзерлиләр. Галим үзе генә дә рус телендә татар әлифбасы, I–IV сыйныфларда укучы рус балалары өчен татар теле дәреслекләре бастырып чыгара. Бу дәреслекләр халыкара китап күргәзмәләрендә бүләкләнә. Татар мәктәпләренең VI сыйныфы өчен Ф. Йосыпов тарафыннан төзелгән татар теле дәреслеге инде 30 ел буе кулланыштан төшми.

Советлар Берлеге таркалганнан соң да, татарлар өчен тимер пәрдәләр тиз генә ачылып китми. Татарлар әле еллар дәвамында үзләре чыгарга теләгән мәмләкәтләргә Россия рөхсәтеннән башка аяк та атлый алмадылар. Казакъ, кыргыз, азәрбайҗан, төрекмән балалары Төркия университетларында белем алганда, татар егетләре, кызлары аларга көнләшеп кенә карый иде. 1990 елда Төркиягә беренче сәфәре вакытында ук Ф. Йосыпов ил җитәкчелегенә бу вазгыятьне аңлатып бирә. Төркия җитәкчелеге дә, Татарстан Россия карамагында булганлыктан, татар яшьләрен рәсми рәвештә укырга кабул итә алмавын белдерә. Аңа Татарстандагы берәр рәсми булмаган җәмгыять тарафыннан татар балаларын Төрек университетларына укырга алуларын сорап мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәләр. 1992 елның августында Татарстанның 80 яшь егет һәм кызын утырткан беренче самолёт Истанбул аэропортына килеп төшә. Ф. Йосыпов үзе дә аларны озата бара, Төркиянең иң абруйлы университетларына урнашырга ярдәм итә.

Бераздан Татарстан һәм Төркия арасында рәсми килешүләр дә төзелә башлый. Хәзер Татарстан егет һәм кызларының Төркия университетларында белем алуы гадәти хәлгә әйләнде. Галим үзе дә төрки телләрнең уртак грамматикасын язу буенча халыкара проект кысаларында берничә ел Төркиядә эшләде.

Фәрит Йосыпов һәрвакыт татар халкының телен, тарихын, милли мәдәниятен башка халыклар арасында да пропагандалый торган эшләрне мөмкин кадәр күбрәк башкарырга тырыша. Без аның бу эшендә уңышлар, саулык-сәламәтлек, исәнлек-иминлек теләп калабыз.

***Эрҗан Алкая,***
*доктор, профессор, Фрат университеты (Төркия, Елазыг шәһәре)*
*Гуманитар һәм социаль фәннәр факультетының*
*Хәзерге төрки телләр һәм әдәбиятлар бүлеге мөдире*

УДК 930

***А.М. Гайнетдинов***

# ОЛУГ ТАТАР ГАЛИМЕ
## (Марсель Әхмәтҗановның 80 яшьлек юбилее уңаеннан)

Статья посвящена 80-летнему юбилею татарского учёного, доктора филологических наук, профессора М.И. Ахметзянова. В ней представлены краткое описание жизни и деятельности учёного, а также его научные достижения.

**Ключевые слова:** Марсель Ахметзянов, учёный, многочисленные труды, татарская литература, археография, эпиграфика, история татарского народа, экспедиции.

The article is devoted to the 80$^{th}$ anniversary of the Tatar scholar, Doctor of philological sciences, professor M.I. Akhmetzyanov. It presents a brief description of the life and work of a scholar, as well as his research achievements.

**Keywords:** Marsel Akhmetzyanov, scholar, numerous works, Tatar literature, archeography, epigraphy, history of the Tatar people, expeditions.

Татар фән дөньясында энциклопедик гыйлемгә ия, күп фән өлкәләрен колачлаган киң эрудицияле шәхесләр күп түгел. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында андый галимнәрнең берсе Ризаэтдин Фәхретдин булса, бүгенге көндә хаклы рәвештә Марсель Әхмәтҗанов исемен атыйбыз, чөнки ул безнең барыбызга да археограф, әдәбият галиме, лингвист, фольклорчы, текстолог, тарихчы, этнограф, эпиграфист, педагог һ. б. буларак билгеле.

Быел югарыда искә алынган ике галимнең дә олуг юбилейлары. Гыйнвар аенда Р. Фәхретдиннең тууына 160 ел тулуны билгеләп үтсәк, шушы көннәрдә мәшһүр татар галиме, филология фәннәре докторы, профессор Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗановка 80 яшь тула. Әгәр дә фәнни эшчәнлекләрен тикшерсәк, иҗат җимешләрен барласак, аларның бер-берсенә шактый охшаганлыгын күрербез...

М. Әхмәтҗанов 1939 елның 26 мартында Лениногорск районы Шөгер авылында дөньяга килгән. Ерак бабалары исә – Әтнә районы Олы Мәңгәр авылыннан. Галимнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Марсель бине Ибраһим бине Әхмәтҗан бине Гайнетдин бине Галиәсгар бине Габдрәшит бине Мөслим бине Арслан бине Әбәк бине Җәбәк.

1943 елда Әхмәтҗановлар гаиләсе Арча районы Яңа Кенәр авылына күченеп килгәнлектән, яшьлеге шунда узган. Кечкенә Марсельне, җиде яше тулгач, ата-анасы Яңа Кенәрдәге рус мәктәбенә биргән. Фәкать татарча фикерләргә өйрәнгән бала русча укытуны кабул итә алмаган, тора-бара ул бөтенләй бу мәктәптә укудан баш тарткан. Рус укытучылары да, үз эшләрен яхшы белүләренә карамастан, балада ят тел ярдәмендә фәннәргә мәхәббәт тәрбияләп булмаганны аңлаганнар булса кирәк. Ата-анасы, ялгышларын танып, икенче елны аны татар мәктәбенә күчерергә мәҗбүр булган. Шуннан соң гына ул мәктәптә

бик яхшы нәтиҗәләр күрсәткән, фәкать «5»леләр генә алып кайта башлаган, башка яшьтәшләреннән үзенең белемгә омтылуы белән аерылып торган.

1957 елда Яңа Кенәр мәктәбен тәмамлаганнан соң, булачак галимнең язмышы шунда ук фән белән бәйләнмәгән – ул башкалабызның бер заводында гади эшче булып эшләгән.

Һәм менә, ниһаять, 1963 елда М. Әхмәтҗанов Казан Дәүләт университетының кичке бүлегенә укырга кереп, тарихчы белгечлеген үзләштергән. 1968 елда бу могтәбәр уку йортын бик уңышлы тәмамлаган.

Һәрвакыт белемгә, фәнгә омтылган кешенең уку, гыйлем алу теләген югары уку йортын тәмамлау гына баса алмаган, әлбәттә. Шуңадырмы, 1972 елда М. Әхмәтҗанов ул заманнарда татар милләтенә хезмәт итүче төп фәнни оешма – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага укырга кергән һәм Фазыл Фәсиев җитәкчелегендә тел белеме буенча диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты исеменә лаек булган. Бу елларда Татарстанда диссертация яклау советы ябылып тора, шуңа күрә ул Казакъстанның Алма-Аты шәһәрендә яклый. Шәҗәрәләр буенча язылган фәнни эше («Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах: (по источникам XIX–XX вв.)») галимнәр тарафыннан югары бәяләнә. Институт галимнәре, аның тырышлыгын күреп, эшкә калырга тәкъдим иткәч, үз халкына хезмәт итү, нинди дә булса файда китерә алу мөмкинлеге бирелүгә сөенеп, ул биредә кала.

Борынгы шәҗәрәләр табу һәм өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге Марсель абыйның зур казанышларыннан саналырга хаклы, чөнки ул – бик күп шәҗәрәләрне фәнни әйләнешкә керткән кеше. Совет заманында фәндә шәҗәрәләргә игътибар кимегәннән соң, ул бу өлкәгә яңадан җан өрде, шәҗәрәләрнең гаять кыйммәтле чыганаклар булуын дәлилләде. Россиядә генә түгел, хәтта бөтен дөньяда татар шәҗәрәләрен аның кадәр яхшы белгән, җентекләп өйрәнгән кеше юк, дип әйтә алабыз. Соңгы елларда халыкта шәҗәрәләр төзү, нәсел-нәсәпне белү омтылышы көчәйде, кешеләрнең үз тамырлары белән кызыксына башлауларында М. Әхмәтҗановның да өлеше зур. Шунысы сөендерә: 2013 елда галимгә «Татар шәҗәрәләре» хезмәте өчен Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелде.

Галим М. Әхмәтҗанов бөтен гомерен татар әдәбиятын, тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышлады. Эш дәверендә ул күпсанлы фәнни экспедицияләрдә катнашып, археографик материал, ягъни борынгы кульязма һәм сирәк басма китаплар җыеп, Институт мирасханәсен тулыландырды һәм бүгенге көнгә кадәр шул эшенә һаман тугрылыклы. Фәнни эшенең темасы: «Татар әдәби мирасын өйрәнү проблемалары: әдәби чыганакларны барлау, тикшерү методы нәтиҗәләре». Анда галим борынгы татар китабының тарихын анализлаган; борынгы татар әдипләре тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрнең таралышын, яшәешен һәм система буларак чагылышын билгеләгән; археографик материал-

лар системасының аерым әсәрләрнең язылу максатларын ачуга ачкыч икәнен дәлилләгән; татар шәҗәрәләре системасының борынгы әдипләр тормышын өйрәнүдә әһәмиятле чыганаклар булуын исбатлаган; татар кулъязмаларында моңа кадәр мәгълүм булмаган яңа әдәби жанрларны ачкан; яңа чыганакларны, әдәбиятыбыз тарихында билгесез, яки аз билгеле шагыйрьләрнең мирасларын фәнни әйләнешкә керткән; кулъязмалардан алынган йөзләгән текстларны хәзерге графикага күчереп, сүзлекчәләр һәм искәрмәләр белән текстологик яктан эшләп чыккан; борынгы язма чыганак текстларын тарих белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү методикасын эшләгән; яңа әдәби ядкярләрне башка кардәш әдәбиятлардагы версияләре белән бәйләнештә һәм чагыштырып өйрәнү методикасын мисалларда күрсәткән. Диссертациясе нигезендә язылган «Татар кулъязма китабы» (2000) гуманитар өлкәдә эшләүче һәр галимнең диярлек өстәл китабына әверелде.

XVII–XIX гасырлар татар әдәбияты тарихы М. Әхмәтҗановка кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән иде. Бу озын тарихи дәверне тулырак ачу өчен, басылып чыккан әдәби ядкярләрнең текстлары гына җитми. Шунлыктан галим, борынгы кулъязма китапларның һәм документларның әдәбиятыбыз тарихын өйрәнүдәге кыйммәтен аңлап, нәкъ менә шушы өлкәдә армый-талмый эшләде, татар әдәбияты тарихын яңа фактлар, чыганаклар, әсәрләр белән баетты, тулыландырды. Мәсәлән, XVIII йөз татар әдәбиятына багышланган хрестоматияләрдә урын алган әсәрләрнең күбесе аның тарафыннан табылган. Алар текстологик яктан эшкәртелеп, укучыларга тәкъдим ителде.

М. Әхмәтҗанов борынгы халык авыз иҗаты ядкярләрен халыкка кире кайтару өлкәсендә дә бик зур эш башкарган кеше. Аның «Каһарман Катил. Дастан», «Угызнамә» (1998), «Дастаннар ватаны» (1999) исемле китаплары зур популярлык казанды – аларда әлегә фәндә билгеле булмаган әсәрләр киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Галимнең меңләгән тираж белән 1991 елда басылып чыккан «Төш юрау китабы» тиз арада халык иң яратып укый торган басмага әверелде. Үзенең «Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре» (2012) китабында М. Әхмәтҗанов борынгы кулъязмалардагы бик күп ырымнарны туплап, кабат халыкка җиткерде. Анда мәхәббәттә уңышка ирешү, бозулардан, дошманнардан, авырулардан саклану өчен укыла торган 130 дан артык XVIII–XX гасырларга караган ырым текстлары китерелгән. Моннан тыш, бу китапта төш юрау тәгъбирләре, календарь фалнамәләр, табигать сынамышлары урын алган. «Татар археографиясе. Татар халкының кулъязма тыйб хәзинәсе мирасы» (2016) хезмәтендә М. Әхмәтҗанов укучыларны медицина өлкәсенә караган бай милли мирасыбыз белән таныштырды. Шунысын әйтергә кирәк: моңарчы бу өлкә фәнни яктан тиешенчә өйрәнелмәгән иде. Яшь галимнәр белсен, өйрәнсен өчен, фәнни экспедицияләрдә табылган археографик материалларының фәнни тасвирламаларын үз эченә алган 10 га якын китабын да галим үз тырышлыгы белән бастырды.

Марсель абый татар эпиграфикасын өйрәнү өлкәсендә дә зур хезмәт куйды. Узган гасырның 70 нче елларыннан башлап күпсанлы экспедицияләргә чыгып, халкыбызның ташъязма мирасын Татарстанның бөтен районнарында диярлек, барлык чиктәш республикаларда, Санкт-Петербург, Оренбург, Чиләбе, Касыйм, Екатеринбург, Уфа, Троицк шәһәрләрендә йөреп, бөртекләп туплады. Шул рәвешле «Үлгәннәрнең каберен бел» (2000), «XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре» (2011), «Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре (2011), «Татар археографиясе. Татар эпиграфикасын өйрәнү дәверендә тупланган зират культурасы хакындагы кайбер материаллар» (2013), «Татарстандагы татар зиратлары ташбилгеләре язмалары» (2016) кебек китаплары бер-бер артлы дөнья күрде. Галимнең татар мәдәниятенең борынгы традицияләрен өйрәнүгә багышланган бу хезмәтләрендә мәдәниятебезнең күп гасырлык тарихи үсеше киң географик мәйданнарда яшәгән халкыбызның милли үзенчәлекләренә басым ясап күрсәтелгән. Зиратларда борынгы кабер ташларын өйрәнү җиңел эш түгел икәнен һәр эпиграфист белә. Билгә кадәр үскән үләннәр, ташландык каберләр иңгәннән соң барлыкка килгән чокыр-чакырлар арасында борынгы кабер ташларын эзләп йөрү олы яшьтәге галимгә генә түгел, яшьләргә дә бик кыен.

М. Әхмәтҗанов татарның тарихын һәм этнографиясен өйрәнүдә дә зур эшләр башкарды. Аның күпсанлы язма чыганаклар нигезендә Алтын Урда, Казан ханлыгы, Касыйм ханлыгы, Нугай урдасында яшәгән татарларларның этник тарихын ачкан «Меңьеллык татар нәселе» (2000), «Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы (2002, 2009) китаплары тарих фәне үсешенә зур өлеш кертте, татар этногенезы тарихын дөрес юлга салды. Шулай ук галим хәзерге Татарстандагы аерым төбәкләрне дә җентекләп өйрәнде. «Олы Мәңгәр авылы тарихы» (2000), «Ахун авылының шәҗәрә китабы» (2006) һ. б. китаплары – шул хезмәтнең җимешләре. Галимгә татар халкы тарихын өйрәнүдәге эшчәнлеге өчен Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетының Лениногорски бүлекчәсе һәм андагы «Заман сулышы» газетасы редакциясе тарафыннан гамәлгә куелган Р. Фәхретдин исемендәге премия бирелде.

Әле күпләребез М. Әхмәтҗановның оста шагыйрь икәнен белмидер. Аның шигырьләрендә, әлбәттә, милләт язмышы темасы киң яктыртылган. Аларның күбесе галимнең куен дәфтәрләрендә кульязма вариантта гына саклана. Сөембикә-ханбикә, Әмәтхан солтан, Янгура батыр турындагы шигырьләре республикабызның төрле газета-журналларында басылып та чыккан. Күргәнебезчә, аның әсәрләре дә татар халкының данлыклы, күренекле ул-кызлары хакында. 2017 елда аның «Күңел тойгылары» дип исемләнгән шигырьләр һәм проза текстлары җыентыгы дөнья күрде. Марсель абый үзенә «Марсель Мәңгәри» дигән псевдоним алган, чөнки, әйткәнебезчә, аның борынгы бабалары Олы Мәңгәр авылыннан.

Шул рәвешле, олуг галимнең бүгенге көндә иллегә якын китабы нәшер ителгән (мәкаләдә барысын да санап бетерү мөмкин түгел), меңгә якын фәнни, фәнни-популяр һәм публицистик мәкаләләре басылып чыккан. Ул – Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺСИ һәм КФУда диссертацияләр яклау Советы һәм төрле журналларда редколлегия әгъзасы, Халыкара төрки академия академигы, Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, хезмәт ветераны. М. Әхмәтҗановның фән һәм милләт үсешенә керткән өлеше шулкадәр зур ки, хәтта ул Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдиннәр белән бер дәрәҗәдә торырга лаеклы галимдер.

Форсаттан файдаланып, мөхтәрәм һәм кадерле Марсель ага Әхмәтҗановны олуг бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итәбез, аңа саулык-сәламәтлек, фәнни ачышлары белән безне һаман сөендереп торуын телибез!

***Гайнетдинов Айдар Марсиль улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының ТР халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 930

***Мәхбүбҗамал Акчурина. Савинка***

# ЗӨҺРӘ ХАНЫМ ТУГРЫСЫННАН

Данная статья является ответной на публикацию Гаяза Исхаки «Исмагил-бек, Зухра-ханум Гаспринские», которая была опубликована в газете «Ил» в 1914 году и вызвала недовольство Акчуриных. В ней выражено несогласие автора с некоторыми искажёнными моментами жизни Зухры Акчуриной-Гаспринской и отражено глубокое уважение к ней.

Статья была опубликована в 1915 году (№ 7) в журнале «Сююмбике».

**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Махбубджамал Акчурина, Зухра Гаспринская, публицистика.

This article is a response to the publication of Gayaz Iskhaki «Ismagil-bek, Zukhra-khanum Gasprinsky», which was published in the newspaper «Il'» in 1914 and caused discontent of the Akchurins. It expresses the author's disagreement with some distorted moments of Zuhra Akchurina-Gasprinskaya's life and reflects deep respect for her.

The article was published in 1915 (No. 7) in the journal «Syuyumbike».

**Keywords:** Gayaz Iskhaki, Mahbubjamal Akchurina, Zuhra Gasprinskaya, journalism.

Могтәбәр *(хөрмәтле)* «Ил» гәзитәсендә Гаяз әл-Исхакый җәнабләренең «Исмәгыйль бәк, Зөһрә ханым Гаспринскийлар» аталган фельетоны басылып чыкты. Мөхтәрәм Исмәгыйль бәк җәнабләре илә мөхтәрәмә рәфикасы *(хатыны),* мәгънәви ярдәмчесе булган каһарманә Зөһрә ханым илә милләтне таныштырды. Мәрхүмә Зөһрә ханым җәнабләренең Исмәгыйль бәк хәзрәтләренә булган саф мәхәббәте, никадәр уңайсызлыкларга очрап та, максатына ирешкәнче, сабыры, сәбаты *(ныклыгы),* җәсарәте *(кыюлыгы)* тугрысында ишеткән мәгълүматым булса да, бөтен фельетонны тәнкыйтькә керешмим. Ләкин Зөһрә ханым җәнабләренә хөрмәтем бөек булганга, 42 нче сандагы сүзләргә эндәшми калуны вөҗданым күтәрә алмый.

Мөхәммәдгаяз әфәнде Зөһрә ханымны мактауда шулкадәр кызып китә ки, хәтта мәдехе *(мактавы)* тәхкыйрьгә *(хурлауга, мыскыл итүгә)* әйләнә.

42 нче санның 3–4 нче баганасыннан гына үз имлясы илә күчерәм: «Зөһрә ханым буйга үсеп җиткәндә зифа буйлы, көләч йөзле, җазибәле *(сөйкемле)* күзле, тирә-юньдә иң матур кыз булганга, аны русларга күрсәтү шактый куркынычлы була башлый. Ул нинди генә мәҗлескә эләкмәсен, бөтен хатыннар арасыннан аны аерып, ирләр, егетләр (руслар) кадерләргә, хөрмәтләргә тотыналар. Аз гына таныштылармы, аңар мәхәббәт изһар итәргә *(аңлатырга, белдерергә)* керешәләр. Юлда-фәләндә очрадымы, томырып-томырып караудан

башлап, танышырга вә белешергә, вә аннан соң мәхәббәт сүзләре сөйләргә керешәләр.

Бервакытны анасы, тутасы белән пароходта барганда бер көн эчендә әллә ничә рус, тезләнеп-тезләнеп, мәхәббәт изһар итәләр. Аналары, туталарының котлары оча вә шундый вакыйгалардан соң Зөһрә ханымның рус обществосында булынуына чик сызыла. Шулай булса да, ул Казан кызлары кебек дүрт дивар эчендә бикләнелми, аның хөррияте шәхсиясе *(шәхси иреге)* бетерелми», – ди.

Бу сүзләрне язып, мөхәррир әфәнде иң элек үзенең тәрбияле гаиләдән улган гыйффәтле ханымнар, туташлар илә таныш түгел идекене ап-ачык әйтеп бирә дә.

Мөхтәрәмә Зөһрә ханымны ирләр алдында үзенчә тота белмәслек дәрәҗәгә төшерә. Үзен олуг тоткан тәрбияле туташка танышыр, танышмас, изһары мәхәббәт кылырга һичбер ир батырчылык кыла алмыйдыр. Хосусән *(бигрәк тә)*, Әсфәндияр бай кеби могтәбәр кешенең таныш руслары да тәрбияле гаиләләр улдыгында шөбһә итәргә урын юк. Тәрбияле рус гаиләләре мәҗлесләрдә әдәпсезлек кылган әфәнделәргә бик тиз ишеккә юл күрсәтәләр.

Кадерләү, хөрмәтләү – башка эш. Тәрбияле туташларны һәрбер милләт хөрмәтли, ригая кыла *(олылый)*. Халык алдында мәхәббәт изһар кылу әдәпсезлек санала.

Гүзәлләргә карау да гаеп эш түгел. «Күрсә, күреклеләрне *(матурларны)* сөймәк – әнбияләр *(пәйгамбәрләр)* сөннәте». Безнең мишәр картчыклары да: «Күрекле кайда, күз анда; авыру кайда, кул анда», – диләр. Гаяз әфәнде тәкъбиренчә: «Томырып-томырып түгел».

Әгәр дүрт стена эчендә үскән, тәрбия-тәгълим күрмәгән, курчак кеби кадерле чүпрәкләргә уралып, бизәнү-көйзәнү илә генә үскән бер кыз кинәттән шундый мәҗлескә очрап, үзен тота белмәсә, һичкем гаҗәпкә калмас иде. Әмма Зөһрә ханым кеби гакыллы, гыйффәтле, тәрбияле, өстәвенә җәсарәтле *(кыю)* булган туташның үз-үзен тота белмәве асла *(һич)* гакылга сыя торган эш түгел.

Пароходларда бик күп гүзәлләр йөриләр һәм шунда ирләр илә дә танышып сөйләшәләр. Ләкин бер көн эчендә танышып та йитмәгән туташ алдында хәтта анасы, тутасы хозурында тез чүгү бу көнгә кадәр күрелгәне һәм ишетелгәне юк иде. Ирләр танышыр-танышмас нинди хатын-кызларның алдына тез чүгәләр идекене Гаяз әфәнде бер дә уйламады микән? Озак вакыт таныш булып, үз мәхәббәтен изһар кылуга теләгән кеше дә анасы, тутасы алдында тез чүгеп, изһары мәхәббәт кылмыйдыр *(мәхәббәт белдермидер)*.

5 нче баганада: «Матурлык ягыннан тирә-юньнән матур булуы, гакыллылык ягыннан һәммәсеннән өстен булуы, Зөһрә ханымга каршы кызыгу-кызганудан килеп чыккан курку, шөбһәләнү уен тудыра да, хатыннар аның матурлыгыннан көнләшәләр, кызганалар. Ирләр аның матурлыгы, зифалыгына хәйран булсалар да, аның үткенлегеннән, аның үзләреннән өстә тору ихтималыннан куркалар. Ул үзе дә шул даирәдә үзенең ят икәнлеген хис итә башлый», – ди.

Үзләренең якыннары, дуст-ишләре булган ирләр, Зөһрә ханымда шул куәтнең барлыгын сизгәч, руслар аны бернигә санамыйча әдәпсезлек кылып, тез чүгәргә батырчылык кылганда, ул куәт кайда китте?

Анасы никадәр гайрәт күрсәтеп, ачуланып, аны туктатырга теләгәндә, саф мәхәббәте юлында һәрбер авырлыкларга түзгән искиткеч җәсарәтле булган туташның руслар әдәпсезлек кылганда йөзләренә чабарга көче җитмәс идеме?

Бер җөмлә икенчесенә тәмам хилаф *(каршы)* булганга, мөхтәрәм Гаяз әфәнде җәнабләре ни язганны әллә укып карамадымы, дип уйга килә.

Бу 42 нче санда Зөһрә ханымның кечкенә кызчык чагыннан алып, буй кыз булган вакытына кадәр аның кием-салымына бөек әһәмият бирелә.

Туташлар зарафәт *(тәрбиялелек)* ягына мәел итүче *(кызыксынучы)* булсалар да, мөхтәрәм язучы әфәндегә әйләнеп-тулганып, тагы шул ук кием-салым илә баш вату охшап җитми.

Безнең гәзитә укучы хатын-кызларыбызның йөзгә 25 е аңлап, 75 е бәлки «бер көн эчендә әллә ничә русларның тез чүгеп, мәхәббәт изһар кылу»ларына гыйбта да кылырлар *(көнләшерләр)*, әмма фельетонның 42 нче санын дикъкать илә укучы ханымнарның, туташларның йөзләре кызаруын да шөбһә итеп булмый.

*«Сөембикә»журналы,*
*1915, № 7, 2–3 б.*

*Текстны басмага әзерләүче:*
***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 75+821

# *«АҢ» АЛЬБОМЫ*

В 1915 г. для подписчиков журнала «Анг» вышел в свет «Альбом», подготовленный Г. Ибрагимовым и объединивший образцы мирового изобразительного искусства. В предисловии к «Альбому» нашли отражение размышления Г. Ибрагимова о литературе и искусстве. После издания «Альбома» в газете «Кояш» была опубликована предлагаемая вниманию читателей рецензия неустановленного автора. Основные замечания рецензента в адрес Г. Ибрагимова заключаются в бессистемности изложения материала, излишнем внимании к христианскому искусству в ущерб искусству мусульманского мира.

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, журнал «Анг», татарская литература, изобразительное искусство, критика.

In 1915 the Album edited by G. Ibrahimov and uniting samples of the world fine art was published for the subscribers of the magazine «Ang». In the preface to the «Album» thoughts of G. Ibragimov on literature and art are reflected. After the publication of the Album, the «Koyash» newspaper published a review by an unidentified author that was brought to the attention of readers. The reviewer's main remarks to G. Ibrahimov are in the unsystematic presentation of the material, excessive attention to Christian art to the detriment of the art of the Muslim world.

**Keywords:** G. Ibrahimov, Ang magazine, Tatar literature, visual arts, criticism.

«Аң» журналына 1914 ел өчен сәркатиблеккә Галимҗан әфәнде Ибраһимов чакырылгач, ул мәзкүр *(югарыда әйтелгән)* ел өчен мөштәриләргә *(даими укучыларга)* һәдия *(бүләк)* уларак бер «Альбом (сәнаиге нәфисә мәҗмугасы)» бирүне дә вәгъдә итеп игълан кылынган иде. Бәгъзе *(кайбер)* сәбәпләр белән Галимҗан әфәнде «Аң» журналыннан китү сәбәпле, вәгъдә ителгән бу «Альбом»ның мөштәриләргә *(абунәчеләргә)* бирелүе соңга калып, менә хәзер әле нәшер ителде[1].

Бондый нәрсәнең матбугатымызда әүвәл *(беренче)* мәртәбә чыгуы булганлыкдан, аңар беркадәр туктарга тугры киләдер: «Альбом» зур кулда (*форматта*), 32 сәхифәдә *(битле)* булып, 32 рәсем һәм Галимҗан әфәнденең озын бер мәкаләсеннән гыйбарәттер. Яхшы кәгазьгә матур итеп басылган, әлхасыйль *(нәтиҗәдә)* технический ягы белән бик тә кәнагатьләндерерлек булып чыккан. Мөндәриҗәсенә *(эчтәлегенә)* килгәч инде, мәгаттәәссеф *(кызганычка каршы),* бу сүзне әйтеп булмыйдыр: әүвәл караштан ук күренеп тора торган бер системасызлык, тәртип ителешенең бик сатхи *(сай)* мәгълүмат, аннан-моннан ишеткән вә күргән белән генә оештырылган икәнен белдертәдер. Кирәк мәкаләдә вә кирәк рәсемнәрдә, нә дә бер тәртип белән сәнаигы нәфисәнең *(матур сәнгатьнең)* классический кыйсемен *(өлешен),* вә нә дә бу көнгә килеп йиткән дәрәҗәсен күрсәтелә алмаган шикелле, үземез өчен якын булган нәрсәләр дә кирәгенчә кертелә алмаган. Галимҗан әфәнденең мәкаләсе, русча әдәбият учебникларының мөкаддимәләрен *(кереш сүзләре)* бераз тәфсирләбрәк тәрҗемә иткән дә, шуңар үземездә дә рәсемнәр вә композиторлар чыга башлау

тугрысында бер дога иярткән вә үзенең өмидсез түгел икәнен бәян иткән. Үземезгә иң якын тора торган рус галәменең *(дөньясының)* сәнгатенә даир *(караган)* йитәрлек мисаллар күрсәтер урында, Галимҗан әфәнде безне Рафаил[2] исеме вә аның тарафыннан ясалган Мадонналарның (хәзрәте Мәрьям сурәтләре) «могҗиз»леген бәян белән сыйлаган. Безнеңчә, мондый бер «Альбом»да, хосусан *(аерым алганда)* шундый шау-шулы вәгъдәләр белән тәртип ителгән бер «Альбом»да, яхуд *(яки)* классический сәнаиге нәфисә хакында ибтидаирәк *(гадирәк)* булса да, асыллы бер мәгълүмат бирүне, яхуд үземез аннан истифадә итәргә *(кулланырга)* тиешле рус сәнгате тугрысында бер аң бирүне максад итеп тоту тиеш иде. Вәлхаль *(чынлыкта),* бу «Альбом»да без бу икенең һичберсен күрмәү өстенә, гомумән, һичбер система таба алмыймыз. Галимҗан әфәнде безгә мәкаләсендә «Рафаилнең могҗиз Мадонналары дәрәҗәсенә ашды» дип Рафаилне, ул тәрсим иткән *(ясаган)* хәзрәте Мәрьям сурәтләрен бөтен сәнгате нәфисәнең тәҗәссемендән *(гәүдәләнүеннән)* гыйбарәт шикелле итеп күрсәтсә дә, ул дәгъвасын исбат өчен дә бер асыллы бәян биреп китми, бәлки бу дәвернең Мадонналарында «христианлык идеалларына гадәттән тыш бер ашкыну күрсәтү» бар иде дип кенә «могҗиза»лыгын исбат итә. Рафаилнең христиан изгеләрен тәрсим итүдә, хосусан, Мәрьям ананы ясауда дәрәҗәи кәмальгә *(камиллек дәрәҗәсенә)* ирешкәнен вә гомумән дә чиркәү рәсемләре ясауда үз заманында иң маһир бер сәнгатькяр булучылыгын, табигый, берәү дә инкяр итми. Ләкин мөселманнар өчен тәртип ителә торган мондый нәрсәләрдә христиан галәменең дөньяви нәрсәләр сугышына булган сәнгатен ихтыяр итүнең табигыйрәк булучылыгы да шөбһәсездер, хосусан, Галимҗан әфәнде сәркатиблек иткән заманда «Аң»ның үзендә дә инде хәзрәте Мәрьям сурәте ике мәртәбә чыгып өлгергән иде ки, шуңар күрә «Аң» укучылары Мадонналарны вә алардагы христианлыкка мәнсүб *(караган)* красотаны аңламый калалар дип куркырга да Галимҗан әфәндегә урын юк.

Моның өстенә Галимҗан әфәнде үзенең мәкаләсендә, фотограф сурәтләре *(фотографияләре)* белән сәнаиге нәфисә арасында һичбер төрле мөнәсәбәт юк дип дәгъва итсә дә, «сәнаигы нәфисә»се дип исем биргән «Альбом»ына 10 данә фотограф рәсемләре *(фотографияләре)* дә кертеп, бер тәнакыз *(каршылык)* ясый һәм «Альбом»ның бу кыйсемендә дә *(өлешендә дә)* гаҗәеб бер системасызлык күрсәтә. Бу системасызлыкны ачык күрсәтер өчен фотограф рәсемнәрен санап чыгу йитсә кирәк: Сахибҗамал Гыйззәтуллина, исеме язылмаган бер рус артисткасы, Мәрҗани, «Исабәт» мөхәррире *(авторы)* Г. Чыгатай, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Зәки Вәлиди, сәясиләремездән Садри Максуди һәм Г. Исхакый, Сәгыйть вә Манатовлар мәгыятендә *(компаниясендә)* алдырган Галиҗан әфәнденең үз фотографы *(фотографиясе)* дәрҗ ителгән *(кертелгән).* Дини реформаторлар эчендә Муса әфәнде Бигиев рәсеменең булмавы никдер аңлашылмаслык булса, Мөхәммәд галәйһиссәлам хакында бер тарафлы әсәр язган Г. Чыгатай әфәнде рәсеме дәрҗ ителгәч, инде шул ук Мөхәммәд галәйһис-

сәлам хакында әсәр язган вә ислам тарихында йәде тула сахибе *(киң белем иясе)* булган Ризаэддин хәзрәт рәсеменең булмавы «Альбом»ны бөтенләй берьяклы ясый. Сәясиләремездән берсенең рәсеме төшерелгәч, инде Йосыф Акчура углы, Фатих Кәрими вә җәмәгать хадимнәреннән Сәлимгәрәй Җантуриннарның рәсемләре дә булырга тиеш түгелмени? Боларның һәммәсеннән алда, вафаты мөнәсәбәте белән Гаспринскийның хәзергә кадәр матбугатка чыкмаган берәр рәсемен табарга тырышу, Каюм эн-Насыйриның профессор Катанов группасындагы рәсемен алдырып дәреҗ итү «Альбом»ны тәртип итүченең вазыйфасыннан тыш идемени? Исеме дә язылырга ярамый торган бер рус артисткасы ни мөнәсәбәт белән дәрҗ ителә? Матурга күрәме? Ул матурлыкта гына татар-төрек кабиләсенә мәнсүб *(караган)* бер кыз, бер хатын табу бик читенмени?

«Альбом»ның һәр ике тарафындагы менә шул системасызлыкны күргәч, аның технический ягы никдер мөкәммәл *(камил)* булса да, мөндәриҗәсе *(эчтәлеге*) соң дәрәҗәдә зәгыйфь вә сатхи эшләнгән дияргә мәҗбүр булынадыр. «Сәнаиге нәфисә мәҗмугасы» дигән шикелле тантаналы исем белән тәртип иткәч инде, Галимҗан әфәнде шул тугрыда чынрак мәгълүматлы берәр кешедән тәгълимат алыбрак хәрәкәт иткән булса, вазыйфашинаслык *(компетентлык)* иткән булыр иде. «Аң» идарәсе үзе нәшер иткән бу «Альбом»ның шул бер тарафлыгын хәтергә алып булырга кирәк, үз тарафыннан түбәндәге ихтирафны *(искәрмәне)* дәрҗ итүне тиеш тапкан: «Альбом»ның мөндәриҗатын башкарып чыгару «Аң» журналының элекеге сәркатибе Галимҗан әфәнде Ибраһимовка илтизам ителгәнлегеннән *(йөкләтелгәнлектән)* идарә мәсьүлиятне *(җаваплылыкны)* үз өстендән төшерәдер».

Матбугатымыз дөньясында мәктәпләр галәме белән һич мөнәсәбәтләре булмаган бәгъзе кешеләрнең яза торган нәрсәләре тугрысында иң сатхи бер мәгълүматка гына малик (*ия булган*) хәлдә «мәктәп китаплары» язуларын күрә-күрә өшеп беткән җан, акыл шушындый «сәнаигы нәфисә» исеме белән вөҗүдкә чыга торган *(дөньяга чыга торган)* нәрсәләр дә мондый газапларга һәдәф ителмәсен *(мишень ителмәсен)* иде һәрнәрсәне әһалиенә *(белгечләренә)* тапшырырга вакыт инде.

*«Кояш» газетасы,*
*1915 ел, 20 март (№ 659)*

**Искәрмәләр**

1. «Аң» журналы абунәчеләре өчен әзерләнгән һәм рәсем сәнгате үрнәкләрен үз эченә алган «Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» 1914 елда әзерләнгән булуга карамастан, техник сәбәпләр аркасында 1915 елның февралендә генә басылып чыга (*Г. Ханнанова искәрмәсе).*

2. Биредә сүз атаклы итальян рәссамы һәм архитекторы Рафаэль Санти (1483–1520) турында бара (*Г. Ханнанова искәрмәсе*).

*Текстны басмага әзерләүче, искәрмәләрне язучы:*
***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ (И.К. Фазлетдиновның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» (Уфа: Китап, 2018, 344 б.) китабына мөнәсәбәттә)

В статье автор обращается к вопросу сбора и издания фольклорного материала в регионах России. Массовые миграции на разных исторических этапах привели к увеличению мест компактного проживания татарского населения в России и мире. Расселение на больших пространствах России и этнокультурные взаимосвязи оказывали прямое воздействие на развитие и распространение народного творчества. Так на территории Башкортостана, расположенного на Предуралье и на склонах Южного Урала на сегодняшний день численность татар превышает более миллиона человек. Автор акцентирует внимание на важность изучения татарского фольклора в Республике Башкортостан местными исследователями, дает широкий анализ книги «Фольклор татар Башкортостана: предания, легенды, былички, устные рассказы» (Уфа: Китап, 2018, 344 с., на татарском языке). Составитель, автор вступительной статьи и комментариев – кандидат филологических наук, доцент БГУ Фазлутдинов Ильдус Камилович.

**Ключевые слова**: книга, татары Башкортостана, фольклор, жанр, источник, наследие, традиция.

In the article, the author considers the issue of collecting and publishing folklore material in the regions of Russia. Mass migrations at different historical stages led to an increase in places of compact residence of the Tatar population in Russia and the world. Settlement on large spaces of Russia and ethnocultural relationships had a direct impact on the development and dissemination of folk art. So on the territory of Bashkortostan, located on the Urals and on the slopes of the Southern Urals, the number of Tatars exceeds more than a million people. The author emphasizes the importance of studying Tatar folklore in the Republic of Bashkortostan by local researchers, gives a broad analysis of the book «Folklore of Bashkortostan Tatars: tales, legends, mythology, oral stories» (Ufa: Kitap, 2018, 344 p., in the Tatar language). The compiler, author of the introductory article and comments is Candidate of Philology, associate professor of BSU Fazlutdinov Ildus Kamilovich.

**Key words:** book, Tatars of Bashkortostan, folklore, genre, source, heritage, tradition.

Татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яшәве яхшы мәгълүм. Дүрттән өч өлеше Россиянең һәм дөньяның төрле почмакларына сибелгән. 2010 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, күрше Башкортстанда гына да милләттәшләребезнең саны 1 миллионнан артык. Аларның рухи мирасын өйрәнү – гаять әһәмиятле бурыч. Бу өлкәдә Казан фәнни үзәкләре, аерым алганда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать

институты галимнәре зур эш алып бара. Әйтик, 2017 елда Институт тарафыннан Башкортстанның Стәрлебаш районына комплекслы фәнни экспедиция оештырылу һәм бүгенге көндә шушы экспедиция нәтиҗәләренең «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясендә махсус китап итеп басмага әзерләнүе – шушы омтылышның ачык мисалы.

Казан белгечләреннән тыш җирле галимнәр дә үз төбәкләрендәге татар әдәбиятын, милли фольклорыбызны өйрәнүгә мул өлеш керттеләр. Бу җәһәттән Риф Мөхәммәтҗановның исемен телгә алу бик урынлы булыр. Ул – Башкортстан татарларының халык авыз иҗатын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эшен башлап җибәргән беренче галим. Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы каршында ачылган фольклор фонды Р. Мөхәммәтҗановның фән өлкәсендәге иң зур казанышын тәшкил итә. XX йөзнең 60 нчы еллары уртасыннан алып ул Башкортстан Республикасының татарлар күпләп яшәгән районнарына өч дистәгә якын фольклор экспедициясе оештыра, студентлар белән бергә 150 дән артык авылда булып, информантлар белән аралаша. Әлеге экспедицияләрдә җыелган фольклор материалларының тиз арада фәнни әйләнешкә кереп киткәнлеге мәгълүм. Узган гасыр азагында дөнья күргән «Татар халык иҗаты» академик күптомлыгының һәр томында диярлек Риф ага тарафыннан тупланган фольклор үрнәкләре урын алган, аеруча «Йола һәм уен җырлары» томында Р. Мөхәммәтҗанов Башкортстанда язып алган текстлар күп.

Татар милли-мәдәни мирасын барлауның тагын бер матур үрнәге – күптән түгел З. Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында дөнья күргән «Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» дип аталган китап. Төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы – филология фәннәре кандидаты, доцент, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты Илдус Камил улы Фазлетдинов. Ул 1996 елда шушы ук уку йортының татар-рус филологиясе бүлеген тәмамлаган һәм фольклор, татар әдәбияты укытырга калдырылган, 2005 елда Казанда, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының диссертацияләр яклау советында «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идея-эстетик функцияләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклаган. Фәнни җитәкчесе – күренекле башкорт фольклорчысы, филология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Мөхәммәтвәли улы Сөләйманов.

Башкортстанда яшәүче татарларның әкияти характерда булмаган халык прозасын җыю һәм анализлау эше белән И. Фазлетдинов узган гасыр ахырында шөгыльләнә башлый. Студентлар белән төрле районнарга экспедицияләргә чыга, фольклор темасына диплом эшләре яздыра. «Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» җыентыгы – шушы эшчәнлекнең җимеше. Ул БДУның татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы

каршындагы фольклор фонды материалларына таянып төзелгән. Җиде йөздән артык халык иҗаты текстын үз эченә алган бу китап – Башкортстан татарларыннан җыелган беренче фольклор тупланмасы. 600 гә якын текст фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә. Томга кергән материаллар арасында иң зур күпчелекне риваятьләр алып тора (630 текст). Алар авыл тарихлары, тарихи риваятьләр, топонимик риваятьләр, көнкүреш риваятьләре, легендар риваятьләр дигән төрләргә бүлеп бирелгән. Легендар риваятьләр автор тарафыннан фәндә беренче тапкыр аерып чыгарылган. Галим фикеренчә, аңа жанр сыйфатлары ягыннан риваятьләр һәм легендалар арасында торган әүлиялар, алып кешеләр, кулга кермәс сихерле хәзинәләр турындагы үрнәкләр карый. Боларда риваятьләргә хас тарихилык та, легендаларга хас фантастика да урын алган.

Хәзерге Башкортстан җирләренә татарлар кайчан һәм кайдан килеп утырганнар, ни рәвешле нигез корып, тормыш башлап җибәргәннәр? Аларның биредә яшәүче халыклар белән мөнәсәбәтләре нинди булган? Яңа авылларга ни рәвешле һәм нәрсәгә таянып исем бирелгән? Җирле урын атамалары ничек барлыкка килгән? Шушы һәм шуңа охшаш сорауларга җавап эзләгәндә, легендалар, риваятьләр һәм аларның аерылгысыз өлешен тәшкил иткән авыл тарихлары кайвакыт тарихи чыганак ролен үти, аларда шактый күп мәгълүмат табарга мөмкин. Халыкта мондый әсәрләрне еш кына «тарих» дип йөртәләр, ә фольклористикада аларны «тарихи проза» дип атау гадәткә кергән. Халыкның үз башыннан кичкән хәлләре бәян ителгән, мондый төр истәлекләр әдәби кыйммәткә дә, тарихи әһәмияткә дә ия. Күренекле фольклорчы Ф.И. Урманчеев сүзләре белән әйтсәк, «риваятьләр, легендалар, мифлар теләсә кайсы халыкның иң борынгы һәм борынгы тарихын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсе булып торалар» [Урманчеев, с. 86]. Аларда элгәреге буыннарның тормыш фәлсәфәсе, тәҗрибәсе чагылыш таба.

Риваятьләр составындагы авыл тарихлары – бик үзенчәлекле төркем. Алар, гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утырган кешеләр, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында мәгълүмат бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә топонимик риваятьләргә хас күренеш. Казан татарлары фольклорыннан аермалы буларак, Башкортстанда И. Фазлетдинов тап булган һәм туплаган тарихларда Болгар, Алтын Урда һ. б. ханлыклар белән бәйле вакыйгалар чагылыш тапканнары очрамый. Аларда сурәтләнгән иң борынгы тарихи вакыйга – XVI гасыр уртасында Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы һәм шуннан соң татарларга карата башланган милли һәм дини геноцид сәясәте. Күп кенә риваятьләрдә нәкъ шушы факт татар халкының көнчыгышка таба күченүе һәм авыллар корып утыруның төп сәбәбе итеп күрсәтелә.

Мәсәлән, укытучы Байсар Иманголовтан язып алынган Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылы тарихын алып карыйк. *«Элгәре Иван Грозный исемле бик явыз патша була. Ул башта мордва халкын басып ала, аннан чират чуваш, марыйларга да җитә. Моннан соң Иван патша Урта Идел буенда яшәүче болгарларны да басып алмакчы була һәм Казанга һөҗүм итә. Ул Казанны ала алмый һәм ачуыннан тирә-яктагы авылларны туздыра. Шундый авылларның берсе – безнең ата-бабаларыбыз яшәгән Байлар Сердәге исемле авыл була.*

*Бу авылда Гобәй исемле мулла яшәгән. Ул бик акыллы булган һәм халык аны нык ихтирам иткән. Урыс гаскәрләре килә башлагач, ул авыл халкын, өлкән улы җитәкчелегендә, Уралга озата. Тик үзе туган төягеннән китми, берничә авыл карты белән шунда кала. Сатлыкҗаннар аны урыс гаскәрләренә тотып бирәләр. Урыслар казанда сумала кайнатып, шунда Гобәйне салып үтерәләр. Калган картларны коллыкка озаталар.*

*Мулланың өлкән улы Алдаргол авыл халкын башкорт җирләренә алып бара. Алар Өсән елгасының аръягында тукталалар һәм әлеге Алдар тавында төпләнәләр. Яңа авылга Гобәй мулла исемен кушалар. Авылның тирә-ягын карама урманы әйләндереп алганлыктан, тиздән ул Карамалы-Гобәй дип атала башлый...»*

Биредә Явыз Иван гаскәрләренең үзләренә баш бирмәгән карт кешене коточкыч җәзалап үтерү, тирә-яктагы авылларны җир белән тигезләү, картларны коллыкка озату күренешләре аша хөкүмәт тарафыннан бернинди мораль-әхлак кануннарын да санга сукмыйча алып барылган колониаль сәясәтнең масштаблары ачыла.

Риваятьтә анахронизм чагылышын да тоемларга мөмкин. Мәсәлән, Явыз Иванның Казанны яулап ала алмавы турындагы хәбәр тарихи дөреслеккә туры килми. Күрәсең, бу Байлар Сердәге авылында яшәүче татарларның үзләрен җиңелүче сыйфатында кабул итәргә теләмәүләре белән аңлатыладыр. Ягъни халыкның азатлык турындагы хыялы, риватькә күчеп, образлы чагылыш таба. Ирек өчен көрәш юлында һәлак булган геройның исеме авылдашлары яңа урында нигезләгән авыл атамасында мәңгеләштерелә. Бу шулай ук татарларның Иван IV изүенә буйсынырга теләмәүләре, яңадан милли-азатлык көрәшенә күтәрелергә әзер булулары турында сөйли.

Шунысы мөһим: әлеге риваятьнең Фазлый Камалиев истәлекләреннән күчереп алынган икенче вариантында Урал буенда татарларның хуҗалык итү рәвеше һәм, иң мөһиме, җирле халык белән мөнәсәбәтләре бик ачык итеп тасвирлана. Монда Казан ягыннан күчеп килүчеләрнең «*кеше үтеп керә алмаслык зур сазлык*» янына килеп утырулары, «*вакыт үтеп, күчеп килүчеләр саны артып, авыл зурайгач кына*» сазлыкны киптереп, яңа иген басулары барлыкка китерүләре тасвирлана.

*«Шулай берчакны, монда авыл барлыгын белеп, Карамалы-Гобәйгә иярләнгән атларга атланган башкорт картлары килеп чыккан. Алар бу җирләргә элек-электән башкортлар хуҗа булганлыгын*

*аңлатканнар. Безнең авыл картлары, киңәшләшкәч, аларны яхшы сыйлап, озак кунак иткәннәр һәм шул ук вакытта үзара килешү төзегәннәр.*

*Кунак булгач, башкорт картлары, безнең авыл бабайларын ияртеп, Өсән елгасы аша чыкканнар. Алар биек тау башына менеп, атларыннан да төшмичә: «Ана, ана, шуннан!» – дип, Өсән елгасының Бәләбәй ягын күрсәткәннәр. Аннан икенче якка борылып: «Ана, ана, шуннан», – дип, Өсән елгасының Собхангул авылы яныннан аккан урынын күрсәткәннәр. Шулай итеп, алар татарларга бирелгән җирләрнең чикләрен билгеләгәннәр...»*

Риваятьтән күренүенчә, биредә борын-борыннан яшәгән җирле халык Казан ягыннан күчеп килгән татарларның яңа авыл төзүләре турында соңлап кына белә. Килеп туган хәлне җир хуҗалары ике төрле: я татарларны үз биләмәләреннән куып җибәреп, я булмаса, аларның хәленә кереп, яңа урында төпләнеп яшәргә рөхсәт биреп хәл итә алыр иде. Җирле халык икенче юлны сайлый: килүчеләргә сүздә генә түгел, гамәлдә дә теләктәшлек күрсәтә.

Җир биргәндә җирле төркиләр аны үлчәп тә тормый, биек тау башына менеп, атларыннан да төшмичә, «Ана, ана, шуннан!» – дип, Өсән елгасының башта Бәләбәй ягын, аннан икенче якка борылып, «Ана, ана, шуннан!» – дип, елганың Собхангул авылы яныннан аккан урынын күрсәтәләр. Риваятьтәге «Ана, ана, шуннан!» репликасы – дала җирләренең иркенлеген дә, биредә борын-борыннан төпләнеп яшәүчеләрнең күңеле киңлеген дә ачып бирә торган деталь. Казан ягыннан күчеп килгән татарлар Урал итәгендәге Карамалы-Гобәй авылына гына түгел, Тукай һәм Кәлшәле авылларына да нигез салалар. Фольклор әсәрләрендә җир бүлешү әнә шул рәвешле чагылыш таба.

Тарихчылар фикеренчә, Башкортстан җирләре Алтын Урда чорыннан ук (хәтта аннан алдарак та!) татарлар өчен тарихи ватан булган. Бу тирәләрдә яшәгән татарлар турында иң беренче мәгълүматлар XI гасырга ук карый. Фарсы галиме Әл-Гардизи, мәсәлән, Көньяк Урал территориясенең, шул исәптән бүгенге Башкортстанга караган кайбер җирләрнең Урта гасырлар төрки дәүләтләренең берсе булган Кимак каганлыгына керүе хакында язып калдырган. Кимак каганлыгы составында җиде кардәш кабилә булып, икесе Татар һәм Кыпчак кабиләләре исеме белән билгеле. Татарлар каганлыкта идарә итүче йорт исәбендә торганнар [Исхаков, с. 17]. XIV йөз тарихчысы Ибне Халдун кыпчаклар арасында татарларның аерым этногенетик тармак тәшкил итүләре турында яза. Бүгенге Башкортстан җирендә татар мәдәнияте эзләре, элгәрләребез тормышының Урта гасырлар катламына ук карый торган ядкярләре һичшиксез бар. Алтын Урда таркалгач, Уралдан төньякка таба Себер ханлыгы, көньякта Нугай Урдасы барлыкка килә [Долгих, с. 62]. Урал итәгендәге иркен далаларның, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, көнчыгышка таба качып китәргә мәҗбүр булган кардәшләребез барып сыенган урын икәнлеге дә мәгълүм.

Фольклорда нәкъ менә шушы чорга кагылышлы, ягъни Казан ханлыгы яулап алынганнан соң татарларның хәзерге Башкортстан территориясенә күчеп утыруларына бәйле ядкярләрнең аеруча күп сакланганлыгы тарих турында берьяклы нәтиҗәләр ясарга нигез булмый, әлбәттә. Монда эпик характердагы фаҗигале вакыйгаларның халык хәтеренә нык сеңеп, озак вакытлар онытылмавын да истән чыгарырга ярамый. Казан ягыннан килгән татарларның Урал итәгендәге җирләргә урнашуы бу төбәккә татар кавеменең беренче кат аяк басуы турында сөйләми.

XVIII гасыр – Казан ягыннан килгән татарларның бирегә тагын күпләп күчеп утыру чоры. Казан һәм касыйм татарларының көнчыгышка хәрәкәте XVIII гасырның беренче яртысында һәм уртасында аеруча интенсив төс ала. Күченүчеләрнең төп ташкыны Урал алды җирләренә юнәлә һәм татарлар төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш Башкортстан территориясендә төпләнәләр. Идел буе татарларының Урал алдына күпләп күчеп утырган чор 1719–1744 елларга туры килә. Бу хәл Башкортстан татарларының риваять һәм легендаларына да килеп кергән. Аларның күпчелегендә XVII гасыр – XX гасыр башларында булып узган вакыйгалар өстенлек итә. Бу дәвернең тарихи вакыйгалары халык хәтерендә әлегәчә яши. Киеренкелеге, драматизмы белән аларга тиңләшерлек хәлләр борынгы тарихта бәлки булмагандыр да. XVII–XVIII гасырларда халыкның милли-колониаль, сыйнфый изүгә каршы бер-бер артлы баш күтәрүләре, Россия хөкүмәтенең төрле мәкерле юллар белән башкорт җирләрен үзләштерүе, татар халкының Урта Идел буйларыннан көнчыгышка күчеп утыруына бәйле вакыйгалар, гражданнар сугышы, сыйнфый көрәш фаҗигаләре, аңлашыла ки, кеше аңында һәм күңелендә җанлы тарихның чагылышы булган риваятьләргә үтеп кергән.

Күчеп килүчеләрнең җирле халык белән мөнәсәбәтләрен тасвирлаган риваятьләрдә үзәктә, чыннан да, җир биләү мәсьәләсе тора. Әлеге мәсьәләгә бәйле рәвештә, риваятьләрдә төрле милләт, сословие вәкилләре арасында җир өчен конфликтаркасында туган низаглар турында сөйләгән күпсанлы мотивлар урын ала. Казан татарлары фольклорыннан аермалы буларак, күчмә кабиләләр арасында күршеләренең малын, җирен тартып алу өчен барган феодаль сугышлар – карымта-барымта яулары турындагы риваятьләр Башкортстан татарлары репертуарында зур урын тота. Тарихтан билгеле булганча, XVI–XVIII гасырларда башкорт-казакъ ырулары арасында мөнәсәбәтләр катлаулы булган. Халык авыз иҗатында үзара үчләшүгә, дошманлашуга китергән феодаль чапкыннар, барымта һәм карымта күренешләре чагылыш тапкан. Көньяк, көньяк-көнчыгыш башкортларның авыз-тел иҗатында казакъ белән башкорт барымталары хакында байтак кына риваять һәм легендалар очрый [Нәдершина, б. 18–34].

Моңа кадәр әлеге төр әсәрләр, мөстәкыйль тематик төркем буларак, бары тик башкорт риваятьләре составында гына аерымлана иде. И. Фазлетдинов исә карымта-барымта яулары белән бәйле

мотивларның башкорт фольклорында гына түгел, Башкортстан татарларының риваятьләрендә дә мөһим урын тотуын ачыклый һәм аларны мөстәкыйль тематик цикл итеп бирә. Аның фикеренчә, «карымта-барымта яулары белән бәйле сюжетлар, беренчедән, яңа урыннарга соңрак килеп төпләнгән татарлар репертуарына бирелгәге урын атамаларының аңлатмалары буларак, бу җирләрнең борынгы хуҗалары – асаба башкортлардан күчкән булырга тиеш. Икенчедән, карымта-барымта яуларының татарлар бирегә күчкәч тә дәвам итүе мөмкин». Шулай ук татар халкының хәзерге Башкортстан җирләрендә борын-борыннан яшәп, бу сугышларда турыдан-туры катнашканлыгы турында фикер йөртергә дә урын бар. Ничек кенә булмасын, карымта-барымта сугышлары турындагы мотивлар Башкортстан татарлары риваять-легендаларының уникальлеген, кабатланмаслыгын раслаучы бер билге булып тора.

Мәсәлән, Авыргазы районы Нугазак авылында язып алынган «Каравыл тау» һәм «Кырлау үзәне» исемле риваятьләр әлеге атамаларның барлыкка килүен нәкъ шушы карымта-барымта сугышларына кайтарып калдыра. Ике риваять тә этимологик мотивка – атамаларның барлыкка килүен аңлатуга нигезләнгән. «Кырлау үзәне» дигән риваятьтә *«күчеп йөрүче башкортлар белән Урта Азия якларыннан килгән баскынчылар арасында зур сугыш булып, бик күп кеше кырыла»,* атаманың килеп чыгышы шуның белән аңлатыла, «Кырлауда кырылдык» дигән сүзләрнең хәзер дә халык телендә еш кулланылуы турында хәбәр ителә.

«Каравыл тавы» дигән үрнәктә исә төрле ыру-кабиләләр арасында теләктәшлек, авыр вакытта бер-берсенә ярдәмгә килергә һәрчак әзер тору кебек асыл сыйфатлар чагылыш таба. Алар «*тау башында каравылда торып, куркыныч янаса, зур учаклар ягып, төтен ярдәмендә*» бу хакта берсенә берсе хәбәр итәләр. *«Хәбәрне алгач, башкортлар бер-берсенә ярдәмгә килеп, барымтачыларның һөҗүмнәрен кире кага, мөмкин булмаса, урман-тау арасына кача торган булганнар»,* – диелгән риваятьтә. Шул рәвешле, урынга атама үтәгән вазифасыннан чыгып бирелә торган булган. Шуны да әйтик, «Каравыл тавы» оронимының Башкортстанда таралу географиясе шактый киң. Бу атаманың килеп чыгышын аңлатучы риваятьләр Ярмәкәй районының Сөярмәт һәм Учалы районының Ахун авылларында да очрый. Бу үрнәкләрдә дә ул әлеге тауларда «сакчыларның тирә-якны күзәтеп, авылны каравыллап» торуларына кайтарып калдырыла. Димәк, барымта-карымта кебек күренешләр борынгы Башкортстанның һәр төбәге өчен типик булган, дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Кайбер риваятьләрдә явыз җирбасар-барымтачыларга каршы сугышта илен саклап һәлак булган батыр егет яки кызның җаны шушы җирлеккә күчеп, тау яки сазлыкның яу белән килүчеләрнең юлында үтәлмәслек киртәгә әверелү мотивын да күрергә мөмкин. Моңа мисал итеп, Нуриман районы Кызыл Яр авылындагы «Каратау», Әлшәй районы Гайниямал авылындагы «Гамбәр сазлыгы», Балтач районы

Иске Балтач авылындагы «Такыя тавы», Борай районы Кәшкәләү авылындагы «Үрәзикәй чишмәсе», Эстәрлебаш районы Эстәрлебаш авылындагы «Котып чокыры» риваятьләрен китерергә була. Бу үрнәкләрдә сугыш картиналары аеруча драматик тасвирланган, илен саклаучы батырларга халык илаһи сыйфатлар биреп, хәтта җансыз табигатьне дә аларга теләктәш итеп күрсәткән.

Башкорт халкы белән күп гасырларга сузылган рухи һәм географик янәшәлек Башкортстан татарларының риваятьләрендәге аерым мотивлар, образлар күчемлелеге сыйфатында да гәүдәләнә. Мәсәлән, әкияти характерда булмаган халык прозасы составында җен-пәриләргә, шайтаннарга бәйле этногенетик риваятьләр үзе аерым цикл тәшкил итә. Халыкның мифологик карашларын чагылдырган бу мотивның татар һәм башкорт фольклорында күпләп очравы – ике халык арасында гасырлар дәвамында барган рухи-мәдәни алмашулар нәтиҗәсе. Башкорт риваятьләренең аерым зур катламын тәшкил иткән карымта-барымта яулары, җир сату яисә аны халыкны алдау юлы белән тартып алу кебек вакыйгаларга бәйле рәвештә туган фольклор мотивларының да биредәге татарлар репертуарында зур урын тотуын И. Фазлетдинов нәкъ шуның белән аңлата.

Гомумән, Башкортстан татарларының риваять һәм легендаларында тугандаш башкорт халык авыз иҗатының гына түгел, ә гомумдөнья фольклорының йогынтысын да күрергә мөмкин. Халык башыннан үткән тарихи вакыйгаларны фольклорда сурәтләгәндә, күчеп йөрүче интернациональ сюжет һәм мотивлар да еш файдаланылган. Аларны Җир шарының барлык кыйтгалары өчен уртак дөньякүләм мотивлар дип атарга да мөмкин. Болар исәбенә алып чабатасыннан коелган туфрактан тау хасил булу, пугачёвчылар түбәтәйләренә салып ташыган комнан калкулык барлыкка килү, үгез тиресе кадәрле җир сатып алу, «кулга кермәс» алтын хәзинәнең кешеләргә бәрән, яисә утлы шар кыяфәтендә күренүе һ.б. Аларның күпчелегендә борынгыларның антропоморфик, анимистик һәм тотемистик карашлары чагылыш таба һәм шуңа күрә дә бу мотивларны бик ерак мәҗүсилек чорларында барлыкка килгән дип исәпләргә кирәк.

Әлеге мотивлар һәм сюжетлар, формасы белән интернациональ булсалар да, һәр халык аларга, үз тормыш тәҗрибәсеннән, менталитетыннан, тарихыннан чыгып, яңа эчтәлек сала. Традицион мотивларга корылган риваять һәм легендалардан халыкның үткәнен, аның аһ-зарларын, сызлануларын ачык тоемларга мөмкин.

Урын атамаларының килеп чыгышын зур тарихи вакыйгаларга бәйләп аңлата торган топонимик риваятьләр реаль вакыйгалар турында сөйләсәләр дә, алар тарихи документларны алыштыра алмыйлар, чөнки телдән телгә, урыннан урынга, буыннан буынга күчү процессында аларның конкрет документальлек билгеләре тоныклана, анахронизм көчәя, тора-бара тарихилык гомумиләштерелгән төс ала, ирекле уй йөртү, фараз итү, фантазия өстенлек итә башлый. Моның ачык мисалын Салават Юлаев һәм Емельян Пугачёв

җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы турындагы риваятьләрнең хәтта әлеге яу үтмәгән төбәкләрдә дә киң таралуында күрергә мөмкин. Гадәттә, уйдырма эчтәлекле әлеге әсәрләр, теге яки бу урын атамасына берегеп, аның аңлатмасы ролен үти башлыйлар, «тарихилашып» китәләр, хикәяләүче тарафыннан чыннан да булган вакыйга сыйфатында бәян ителәләр. Моны хәтта яу кырыннан читтә яшәгән, восстаниедә катнашмаган крестьяннарның да күңелләре белән баш күтәрүчеләр ягында булулары, азатлыкка омтылыш утында янулары белән аңлатырга мөмкин. С. Юлаев, Е. Пугачёв һ.б. тарихи шәхесләрнең риваятьләрдәге образлары да – гасырлар буена халык күңелендә йөргән азатлык идеяләренең көрәшкә чыгуы, кешеләр аңында гаделлек һәм ирек идеалларын гәүдәләндерүләренең нәтиҗәсе, әмма эпик геройлар дәрәҗәсенә күтәрелгән бу шәхесләр фольклор контаминациясе кичергәннәр. Аларга мифик алыпларга, әкият батырларына хас сыйфатлар күчерелгән. И. Фазлетдинов әлеге үзенчәлекне үз китабында анык мисаллар белән дәлилли.

Мәсәлән, алыплар кебек үк, С. Юлаев һәм Е. Пугачёв та риваятьләрдә ярымтау-ярымкеше буларак чыгыш ясыйлар; алар күтәргән восстание дә тауда башлана һәм соңыннан баш күтәрүчеләр тау куышларына кереп югалалар; аларның гайре табигый көчен күрсәтер өчен, мифик персонажларга хас алым кулланыла – батыр атының тояк эзе ташларга уелып кала, Салават җитмеш потлы ташны, бер кулы белән генә күтәреп, дошманнарга ыргыта һ.б. Болар һәммәсе дә әлеге реаль шәхесләрнең фольклорлашу нәтиҗәсе булып тора.

Тарихи документ ролен үти алмаслар да, риваятьләр һәм легендалар борынгы бабаларыбызның көнкүреше, яшәү рәвеше, ышанулары, гореф-гадәтләре хакында тирән мәгълүмат бирәләр, мөһим этнографик чыганак ролен үтиләр. Риваятьләр аша биредәге халыкның төп шөгылен, яшәү рәвешен ачыклый алабыз. Башкортстан татарларының риваятьләрендә, теге я бу урынга бәя аның иген игү өчен уңайлы булу-булмавына карап бирелә. Бу исә җирле халыкның элек-электән төп шөгыле игенчелек икәнлеген раслый. Риваятьләрдәге барлык мотивлар да, нигездә, җир мәсьәләсенә берегеп килә. Топонимик риваять һәм легендаларда, аларның бер төрен тәшкил иткән авыл тарихларында халык вакыйгаларны гомумиләштергән, анда катнашкан билгеле шәхесләрнең образларын типиклаштырган, тыңлаучыларның риваятьне, легенданы эмоциональ кабул итүенә ирешү өчен, әкиятләр, бәетләр һәм хәтта мәзәкләргә хас мотивларны да кулланган. Шуңа күрә риваятьләр һәм легендалар реаль чынбарлык күренешләре белән халкыбызның мифологик карашларын, иҗади фантазиясен бергә берләштерәләр һәм, фольклорның башка жанрлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, кабатланмас күренеш тудыралар.

И. Фазлетдинов төзегән китап дүрт жанрны колачлый. Югарыда каралган жанрлардан тыш, биредә сөйләкләргә караган үрнәкләр дә туплап бирелгән. Автор-төзүче бу мәсьәләдә үзенчәлекле карашта тора, сөйләкләрне мәзәк һәм риваятьләргә хас сыйфатларны бер-

ләштергән жанр буларак тикшерә. Аның фикеренчә, «сөйләк үзенең жанр үзенчәлекләре буенча риваять һәм мәзәк арасында тора. Риваятьләр кебек үк, сөйләкләргә дә тарихлылык хас, ягъни алар чыннан да тормышта булган вакыйга турында сөйлиләр. Ләкин риваятьләр, гадәттә җитди характерда булып, халык тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларны бәян итәләр. Сөйләкләрдә исә җитдилек бик аз. Мәзәкләргә якынлык ике жанрның да үткен сатира, яисә нечкә юмор белән сугарылганлыгында чагыла. Әмма мәзәкләрдә тарихилык юк, аларда сурәтләнгән кеше образы гадәттә абстракт характерда була, ягъни аның кайда яшәгәнлеге, әйләнә-тирә мохите, вакыйганың урын һәм вакыты турында бер мәгълүмат та җиткерелми. Мәзәкнең төп максаты – кешенең ниндидер бер җитешсезлеген сатирик рәвештә яктырту, сөйләк исә конкрет җирлекле; ул локаль характерда – теге яки бу төбәктә генә таралган; анда сурәтләнгән кешеләр дә арабызда яшәгән; аларның холык-сыйфатлары, вакыйганың урын һәм вакыты да төгәл билгеле». Ничек кенә булмасын, фәндә мондый караш та яшәргә хаклы.

И. Фазлетдинов җыентыгына кертелгән фольклор үрнәкләре бүгенге көндә төзелә торган «Татар халык иҗаты»ның академик 25 томлыгы өчен шактый күп яңа материал бирә алуы белән аеруча әһәмиятле, чөнки моңа кадәр бастырылган фольклор җыентыкларында Башкортстан татарларыннан язып алынган эпик мирас тиешле дәрәҗәдә яктыртылмаган иде. Татар фольклорының яңа томнарын төзегәндә, теге яки бу фольклор текстының барлык билгеле вариантларын истә тоту, һич югы шуларның берсен я берничәсен биреп, калганнары хакында искәрмә-комментарийларда сөйләү, бу текстлар турында мәгълүмат бирә торган, жанрга, аның төрләренә, милли спецификасына, бүленеш-классификация мәсьәләләренә җентекле аңлатмадан торган тәфсилле кереш язу, камил фәнни аппарат булдыру шарт. И. Фазлетдинов төзегән җыентык, академик томнарны заман таләпләренә туры китереп эшләгәндә, бүгенге көнгәчә фольклорчы галимнәр күзеннән читтә кала килгән жанрларны барлау, фольклор үрнәкләренең кайсы төбәккә хас булуын ачыклау, таралыш даирәсен, тарихи-мәдәни бәйләнешләрне күрсәтү җәһәтеннән бик мөһим чыганак ролен үти. Фольклор материалларына XXI гасыр күзлегеннән яңача караш таләп ителгән безнең чорда тиешле фәнни югарылыкны саклап төзелгән «Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» җыентыгына тупланган үрнәкләр – фольклор фәнен үстерүдә һәм халыкныкын кабат халыкка кайтаруда – уңышлы адым. И. Фазлетдинов китабы 1000 данә тираж белән нәшер ителгән. Бүгенге көн өчен бу яхшы күрсәткеч. Гомумән алганда, әлеге китапның гыйльми-теоретик һәм гамәли әһәмияте зур. Ул, бер яктан, фольклористикада татар риваятьләре, легендалар, мифологик хикәятләрнең урынын билгеләүгә йогынты ясый, әлеге жанр әсәрләрен күзаллау мөмкинлеген киңәйтә, икенче яктан, Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезнең

тарихын, фәлсәфәсен һәм тормыш тәҗрибәсен халык күзлегеннән ачып сала.

## Әдәбият

*Долгих Б.О.* Родовой и племенной состав народов Сибири в XVII веке. М.: АН СССР, 1960, 624.

*Исхаков Д.М., Измайлов И.Л.* Этнополитическая история татар в VI – первой четверти XV века. Казань: Иман, 2000. 136 с.

*Нәдершина Ф.А.* Риүәйәт һәм легендалар – халык тарихы // Башкорт халык ижады. Т. 2. Риүәйәттәр, легендалар. Өфе: Китап, 1997. Б. 18–34.

*Урманчеев Ф.И.* Проблемы национальной истории // Академик Мирфатых Закиев. К семидесятилетию. М.: Инсан, 1998. С. 85–89.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре*

УДК 81'374.82

# «ТАТАРЧА-РУСЧА ХӘРБИ ЛЕКСИКА СҮЗЛЕГЕ» ТУРЫНДА (төзүче Р.Т. Сәфәров))

Һәрбер телнең борынгыдан килгән лексик катламы бар. Бу катламга кергән сүзләрнең еш кулланылганнары бүген дә аңлатуга мохтаҗ түгел, ә менә көнкүрештән төшеп калган реалияләрне белдергән берәмлекләрне аңлау еллар узу белән кыенлаша бара. Еш кына борынгы һәм Урта гасырларга караган лексиканы матур әдәбиятта һәм фәнни хезмәтләрдә кулланганда, берникадәр буталчыклык, хәтта ялгышлар да күзәтелә. Шуңа күрә аерым тармакккa караган сүзләрне, терминнарны берләштереп төзелгән сүзлек әлеге лексиканы системага салуда яңа бер этап дип саналырга хаклы.

Шушы күзлектән караганда, Р.Т. Сәфәровның хәрби өлкәгә нисбәтле сүзләрне үз эченә алган «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» кебек белешмәлеккә күптәннән ихтыяҗ бар иде. Чөнки хәрби тематикага бәйле махсус лексикографик чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Берсе – 1926 елда нәшер ителгән «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы», икенчесе – Р.А. Мөгыйновның 2000 елда нәшер ителгән «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге». Русчадан татарчага тәрҗемә сүзлекләр исә моңарчы бөтенләй юк иде. Р.Т. Сәфәров мәгълүматына караганда, 1926 елгы сүзлек – хәрби лексиканы тәртипкә салу, системалап бирү юнәлешендә тәүге тәҗрибә. XX гасырның беренче чирегендә татар хәрбиләренең рус телен начар белүләре, уставны һәм хәрби документларны татарчага тәрҗемә итүдәге төрлелек, шактый гына хәрби газеталар нәшер ителү һәм башка шундый факторлар үзләре үк аны төзүгә этәргән. Сүзлекнең кыйммәте шунда, анда татар теле нигезендә терминнар ясау өлкәсендә бүген дә игътибар итәрлек мисаллар теркәлгән.

Р.А. Мөгыйновның «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге» исә татар теленең хәрби лексикасын системалаштыруда иң җитди хезмәтләрнең берсен тәшкил итә. Сигез меңгә якын лексик берәмлекне эченә алган сүзлектә автор, русча терминнарга аларның татарча тәңгәлләрен тәкъдим итү белән генә чикләнмичә, аңлатмалы сүзлектәге кебек, байтак кына сүзләрнең мәгънәләрен дә биргән.

Бәяләнә торган сүзлектә татар теле беренче планга чыгарылган. Шуның белән дә бу белешмәлекнең әһәмияте зур. Автор анда Урта гасырлар әдәбиятында, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи романнарда чагылыш тапкан хәрби сүзләрне туплап бирүне максат итеп куйган, шул сәбәпле, рус теле аша кереп, хәзерге татар телендә нигездә үзгәрешсез кулланылган хәрби терминнар бик аз теркәлгән. Р.А. Мөгыйнов «төп игътибар борынгы, искергән һәм кулланыштан чыгып бара торган лексик берәмлекләргә юнәлтелгәнлектән, белешмәлек хәрби терминнарның тулы ике телле сүзлеге булуга дәгъва кылмый», дип белдерә, ләкин телибезме без, теләмибезме, русизмнар һәм европеизмнар

көннән-көн телебездә арта гына бара. Алар матур әдәбиятта да, дәреслекләрдә дә үз урыннарын ала килә. Шул сәбәпле әлеге сүзләрне игътибардан читтә калдыруны бик үк дөрес гамәл дип санамыйбыз.

Сүзлектәге берәмлекләрнең тематикасына килгәндә, анда сугыш кораллары һәм корал төрләренең атамалары, аларның аерым өлешләрен, детальләрен, саклау савытларын белдергән сүзләр; саклану киемнәре һәм аларның аерым өлешләрен тәгъбирләгән берәмлекләр; төрле хәрби берләшмәләр, сугышчыларның исемнәре; гаскәр башлыкларының атамалары; сугыш мәйданының аерым эпизодларын, хәрби символларны белдергән берәмлекләр; әсирләрне тасвирлауга бәйле лексика һәм хәрби өлкәгә караган башка сүзләр алынган.

Сүзлекнең төзелеше кабул ителгән традицион модельдә. Тәрҗемә ителә торган баш сүзләр, үзләренә караган материал белән бергә, сүзлек мәкаләсен тәшкил итә. Баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылган һәм түбәндәге өлешләрдән тора:

1) калын хәрефләр белән тәрҗемә ителә торган баш сүз бирелгән;

2) вокабуладагы сүз берничә сүз төркеменә кергән очракта сүз төркеме тамгасы күрсәтелгән;

3) баш сүзнең русчага тәрҗемәсе тәкъдим ителгән;

4) кулланылыштагы үзенчәлекләрен күрсәтеп, мәгънәсен тулырак һәм төгәлрәк ачу максаты белән, һәр сүзгә диярлек мөмкин булган яки җитәрлек күләмдә иллюстратив материал бирелгән;

5) компонентлары аерым язылган кушма яки тезмә сүзләр, сирәгрәк – тотрыклы гыйбарәләр һәм аларның русчага тәрҗемәләре; мондый сүзләр берничә булган очракта, алар алфавит тәртибендә теркәлгән;

6) мисаллар.

**СОЛЫ́Х** мир, перемирие. *Солых белән силах бергә җыелмый.* Мәкаль. – *Ермак сиңа солых тәкъдим итә! – диде Мөхәммәткол солтан.* Ф.Бәйрәмова

**солых төзү** заключить мир. *Көтелмәгән бу хәлдән мәскәүлеләр сәясәтне кинәт борырга ниятлиләр һәм Польша короле белән солых төзеп Казан ханлыгын акылга утыртырга җыеналар.* М.Хәбибуллин

Бер меңнән артык лексик берәмлекне эченә алган сүзлек 112 битлек китап рәвешендә бастырылган. Фәнни редакторлары: филология фәннәре докторы А.Ә. Тимерханов, филология фәннәре кандидаты Ф.Ф. Гаффарова; бәяләүчеләр филология фәннәре докторы Г.Х. Гыйләҗетдинова, филология фәннәре кандидаты И.Җ. Едиханов. Сүзлек тел белгечләренә, тарихчыларга, музей хезмәткәрләренә, тәрҗемәчеләргә, журналистларга файдалы белешмәлек була ала дип фаразлана.

Р.Т. Сәфәровның «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» дә уңай бәяләнергә хаклы. Анда бик күптән формалашып, һәр дәвердә яңа

берәмлекләргә байый-байый, хәзерге татар телендә хәрби тематикага бәйле лексик системаны тәшкил иткән бай материал, аеруча искергән һәм искереп бара торган берәмлекләр барланган һәм анализлап тәртипкә салынган. Әлеге белешмәлек киләчәктә тагын да тулыландырып дөнья күрәчәк яңа басмаларга ышанычлы чыганак булып хезмәт итә алачак.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2019 елның 11 гыйнварыннан 10 февраленә кадәр** Мәскәүдә А.А. Бахрушин исемендәге Дәүләт Үзәк театр музеенда «Марсель Сәлимҗанов театры» дип аталган күргәзмә эшләде. Ул режиссёр, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗановның тууына 85 ел тулу уңаеннан Россиядә Театр елын билгеләп үтү чаралары планы кысаларында оештырылды. Күргәзмәдә М. Сәлимҗанов сәхнәләштергән спектакльләрдән видеоязмалар һәм фотосурәтләр, реквизитлар һәм костюмнар, декорация һәм костюм эскизлары, режиссёрның шәхси архивыннан фотолар, аның катнашындагы фильмнардан өзекләр тәкъдим ителде.

Ачылу тантанасында Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Милләтләр эше комитеты рәисе И.И. Гыйльметдинов, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендә Тулы вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары И.Т. Мөхәммәдъяров, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры Ф.Р. Бикчәнтәев һ. б. катнашты. Күргәзмәнең кураторы һәм концепциясе авторы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова чарада катнашучыларны күргәзмәнең эчтәлеге белән таныштырды.

**2019 елның 24–25 гыйнварында** Болгар ислам академиясендә «Ислам гыйлеме һәм хәзерге мәгариф системасында ислам теологиясе» дип исемләнгән халыкара конференция оештырылды. Конференциягә Германия, Франция, Бөекбритания, Пакыстан, Иордания, Мисыр, Сүрия һәм башка илләрдән, Россиянең төрле төбәкләреннән 100 дән артык галим, дин әһеле, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре чакырылган иде. Конференциядә катнашучылар исламның интенсив үсеш факторы булган мәгариф, фән һәм мәгариф бәйләнешләре турында фикер алыштылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

**2019 елның 19–26 гыйнварында** Казан шәһәренең Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында Нәҗип Җиһанов исемендәге IV «Мирас» татар музыкасы фестивале узды. Быелгы фестиваль Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге оешуга 80 ел тулуга багышланган иде. Аны Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры оештырды.

Фестивальнең ябылу концертында С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Л. Хәмиди, Н. Җиһанов, Р. Яхин һ. б. күренекле композиторларның классик әсәрләре белән беррәтттән, бүгенге көн композиторлары Р. Кәлимуллин, Р. Ахиярова, Л. Любовский, И. Байтирәк, Э. Галимова һ. б. ларның да әсәрләре яңгырады.

**2019 елның 8 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Россия фәне көне уңаеннан тантаналы утырыш үткәрелде. Анда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президиумы әгъзалары, Фәннәр академиясе институтлары хезмәткәрләре, Казан югары уку йортла-

ры һәм шәһәр фәнни җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашты.

Утырышта катнашучыларны бәйрәм белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникова, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыева, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Р.Т. Борһанов, Казан федераль университеты ректоры И.Р. Гафуров котлады.

Тантана фәнни хезмәткәрләргә дәүләт һәм ведомство бүләкләрен тапшыру, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең яшь галимнәрен һәм исемле стипендия лауреатларын бүләкләү белән тәмамланды.

**2019 елның 12–14 февралендә** Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музееның Заманча сәнгать галереясында танылган этнограф Р.Г. Мөхәммәтованың 95 яшьлек юбилее уңаеннан «Идел буе халыкларының традицион мәдәнияте» темасына V Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Бу чарага Казакъстаннан, Азәрбайҗаннан, Мәскәүдән, Башкортостан, Чувашия, Марий-Эл республикаларыннан, Ульян өлкәсеннән галимнәр чакырылган иде. Конференция материаллары җыентык форматында дөнья күрде һәм фәнни җәмәгатьчелеккә җиткерелде.

**2019 елның 15 февралендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 113 ел тулуга багышланган мәдәни чара үтте. Аның кысаларында Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре истәлегенә багышлап эшләнгән «Үлемгә һәм үлемсезлеккә 114 адым» спектакле күрсәтелде, аннан соң фикер алышу оештырылды. Чарага Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, сценарий авторы шагыйрә Луиза Янсуар, сәнгать белгече Рауза Солтанова чакырылган иде.

**2019 елның 21 февралендә** – Халыкара туган тел көнендә – Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен саклау һәм өйрәнү фонды рәсми рәвештә гамәлгә куелды. Бу турыдагы Указны Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин 2018 елның октябрендә имзалаган иде.

Фондны оештыручылар – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык. Фондның төп бурычы – Россия Федерациясе территориясендә туган телләрне өйрәнүгә булышлык күрсәтү, дәреслекләр һәм сүзлекләр булдыру, укытучылар әзерләүдә ярдәм итү.

**2019 елның 21 февралендә** Үзбәкстанның Бохара шәһәрендә татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанигә мемориаль такта ачылды. Тантанада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев, Бохара хакиме Кәрим Камолов, өлкә хакиме Уктам Барноев, Үзбәкстан Министрлар Кабинеты каршындагы дин эшләре буенча комитет рәисе урынбасары

Мозаффар Камилов, Үзбәкстан мөфтие Усманхан хәзрәт Әлимов, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Нотфуллин һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре катнашты.

«Мир Араб» мәдрәсәсе мәйданында урнаштырылган мемориаль тактада «1845–1849 елларда «Мир Араб» мәдрәсәсендә мәшһүр татар дин белгече, галим һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән һәм укыган» дигән мәгълүмат латин графикасында өч телдә – русча, үзбәкчә, татарча язылган.

Истәлек такталары шулай ук мәдрәсәнең Ш. Мәрҗани укыган сыйныфларына һәм галим яшәгән бүлмәгә куелды.

**2019 елның 21 февралендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» дигән темага X Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Аның эшендә Япония, Төркия, Кытай, Кыргызстан, Казакъстан, Россия Федерациясе төбәкләре – Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Удмуртия, Саха (Якутия) республикалары, Төмән өлкәсе – уку йортларыннан ике йөзгә якын студент, аспирант һәм галим катнашты.

Конференция чаралары Татарстанның халык язучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Галиевнең фотокүргәзмәсен ачу белән башланып китте, соңрак язучының «Рух» китабы тәкъдир ителде. Ачылыш тантанасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Татарстан Республикасы халыклары мәдәниятен һәм телләрен үстерү идарәсенең Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү секторы мөдире Р.Ф. Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкара хезмәттәшлек секторының әйдәп баручы киңәшчесе Г.Ф. Мусина катнашучыларны Халыкара туган көн теле белән котлады һәм сәламләү сүзләрен җиткерде.

Секция утырышларында төрки лингвокультурологиянең мөһим мәсьәләләре, аерым алганда, телнең җәмгыять һәм мәдәният белән бәйләнеше, тәрҗемә һәм мәдәниятара багланышлар, мәдәни-тарихи мирас һәм традицияләр, төрки-татар тел белеменең фәнни һәм гамәли проблемалары, әдәби-эстетик эзләнүләр турында фикер алышу оештырылды.

**2019 елның 21 февралендә** Казанда Габдулла Тукайның әдәби музеенда «И туган тел!» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Чара кысаларында «Туган тел» шигыренең 110 еллыгына багышланган интерактив күргәзмә ачылды, Татарстан рәссамнарының бөек шагыйрь образына багышланган картиналары, аудиоязмалар һәм Г. Тукай әсәренә бәйле видеоматериаллар тәкъдим ителде.

Әлеге кичәдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил

Вәлиев, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме хезмәткәре, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев, әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов, музыка һәм театр бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Эльмира Галимова һ. б. Габдулла Тукайның «Туган тел»е язылуга 110 ел тулу уңаеннан үз фикерләре белән уртаклашып, шигырьнең татар әдәбияты һәм сәнгате өчен әһәмиятен билгеләп үттеләр.

**2019 елның 26 февралендә** Татарстан Фәннәр академиясенең Кече залында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2018 ел нәтиҗәләре буенча йомгаклау утырышы булып узды.

Институт директоры К.М. Миңнуллин үзенең хисап докладында коллективның нәтиҗәле эшен билгеләп үтте: 2018 елда галимнәр тарафыннан 54 китап әзерләнгән һәм нәшер ителгән, гомумән алганда, соңгы елларда саллы хезмәтләр чыгару саны арту тенденциясе күзәтелә. Ул институт бүлекләренең эш нәтиҗәләренә кыскача тукталды, алга таба бурычлар куйды. Хисап докладлары белән бүлек җитәкчеләре дә чыгыш ясады.

Конференция эшендә Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина катнашты. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының телләрне, этномәдәни традицияләрне өйрәнү һәм татар халкының милли үзтәңгәллеген саклаудагы ролен билгеләп үтте, фундаменталь тикшеренүләрне, төрки дөнья белән бәйләнешләрне киңәйтү, соңгы вакытта республикада бик актив барган «Татар халкының үсеш стратегиясе»н эшләүдә актив катнашу зарурлыгын ассызыклады.

**2019 елның 28 февраленнән 1 мартына кадәр** Казанда Россия субъектларының мәгариф өлкәсендә идарә итүче башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, мәгариф системасының танылган Россия һәм чит ил эшлеклеләре, шулай ук заманча белем бирү технологияләре белән кызыксынган барлык кешеләр катнашында «Россия мәгарифе» – EDU Russia халыкара форумы узды. Чара Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәге тарафыннан оештырылды. EDU Russia форумының максаты сыйфатлы контентны тормышка ашыру һәм заманча ил мәгарифе трендлары турында фикер алышу, борчыган мәсьәләләрне һәм кызыклы чишелешләрне ачыклау иде.

Форумга барлыгы өч меңнән артык вәкил – төбәк һәм муниципаль белем бирү идарәсе органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, барлык дәрәҗәдәге белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм педагоглары, кече һәм урта бизнес вәкилләре, эре компанияләрнең HR-директорлары, укыту-методик комплектларын эшләүчеләр һ. б. чакырылган иде. 11 эшлекле мәйданчыкта йөздән артык чит ил һәм Россия спикерлары чыгыш ясады. Шулай ук Worldskills-2019 алдыннан эшче һөнәрләр перспективалары турында фикер алышу оештырылды.

**2019 елның 5 мартында** Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музеенда Алтын Урда дәүләте төзелүнең 750 еллыгына һәм Россия академик археологиясенең 100 еллыгына багышланган «Алтын тәхет эзләгәндә» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Күргәзмәне оештыруда Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге китапханәсе катнашты. Экспозициядә беренче тапкыр археолог һәм Көнчыгыш сәнгате белгече Франц Баллода коллекциясе, халыкара Алтын Урда форумнарыннан фотографияләр һәм материаллар тәкъдим ителде.

**2019 елның 7 мартында** Казанда ЮНЕСКО генераль директоры Одри Азуле, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Попечительлек советы рәисе, мәдәниятара диалог буенча ЮНЕСКОның махсус илчесе Минтимер Шәймиев катнашында Дүртенче Бөтенроссия ЮНЕСКО кафедралары конгрессының пленар утырышы булып узды.

Утырышта шулай ук ЮНЕСКО эшләре буенча Россия Федерациясе комиссиясенең җаваплы секретаре Григорий Орджоникидзе, Россия Федерациясенең ЮНЕСКО каршындагы даими вәкиле Александр Кузнецов, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас үзәге директоры Мехтильд Рёсслер, ЮНЕСКО Генераль директоры кабинеты директоры Николя Кассианидес, ЮНЕСКОның милли комиссияләр һәм гражданнар җәмгыяте эшләре буенча секция башлыгы Генс Сеити, Россия Федерациясе Президенты каршындагы гражданнар җәмгыяте һәм кеше хокукларын үстерү советы рәисе Михаил Федотов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Яңарыш» республика фондының башкарма директоры Татьяна Ларионова, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов катнашты.

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе М.Ш. Шәймиев конгресста катнашучыларны «Яңарыш» фондының мәгариф өлкәсендәге яңа планнары, шул исәптән гомуми белем бирүче полилингваль комплекс проекты белән таныштырды.

**2019 елның март аенда** М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреатларының исемнәре игълан ителде. 2018 – 2019 елгы бәйге нәтиҗәләре буенча әлеге мәртәбәле бүләккә «Һөнәр» Бөтенроссия яшь режиссёрлар фестивален оештырган һәм Татарстан Республикасы театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Якупов Илфир Илшат улы һәм театрның әдәби бүлек мөдире Игъламов Нияз Рәүф улы; Муса Җәлил иҗатын өйрәнү һәм пропагандалауга зур өлеш керткән, дәреслекләр, укыту программалары, укыту-методик әсбаплар төзегән өчен – шагыйрь, прозаик, публицист, педагог, җәлилче-галим

Бадыйков Канәфи Габделбәр улы; «Әлиф» хореография спектакльләрендәге артист хезмәте өчен – Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры балетмейстеры Батуллин Нурбәк Роберт улы; югары һөнәри осталыгы, милли музыка сәнгатен актив пропагандалаганы, концерт эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы «Созвездие – Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасының сәнгать җитәкчесе Сөләйманов Айдар Данил улы лаек булды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2019. № 1

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 03.04.2019. Басылды: 17.04.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,75. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ, К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла